АРЧА ТӨБӘГЕ ТАРИХЫ

ИСТОРИЯ АРСКОГО КРАЯ



АРСК, XVI в.


АРЧА, XVI г.

КОНТРОЛЬНЫЙ ЛИСТОК
СРОКОВ ВОЗВРАТА

КНИГА ДОЛЖНА БЫТЬ
ВОЗВРАЩЕНА НЕ ПОЗЖЕ
УКАЗАННОГО ЗДЕСЬ СРОКА

Колич. пред. выдач

3 ТМО Т. 2250000 3. 828—90

Администрация Арского района Республики Татарстан

ИСТОРИЯ АРСКОГО КРАЯ

КАЗАНЬ
ТАТАРСКОЕ КНИЖНОЕ ИЗДАТЕЛЬСТВО
1996

Татарстан Республикасының Арча районы хакимияте

АРЧА
ТӨБӘГЕ
ТАРИХЫ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1996

ББК 63.3 (Р-Тат.)
А 74

Китап Арча районы хакимиятенең матди ярдәме белән нәшер ителде

Книга издана на средства администрации Арского района

Төзүчеләр: **Камил Низаметдинов, Илшат Хәлиуллин**

Составители: **Камиль Низаметдинов, Ильшат Халиуллин**

Фәнни мөхәррире **Илшат Хәлиуллин**

Научный редактор **Ильшат Халиуллин**

Рәссамы **Рушан Шәмсетдинов**

Художник **Рушан Шамсутдинов**

А 74 Арча төбәге тарихы (История Арского края).— Казан: Татарстан кит. нәшрияты, 1996.— 256 бит.

ISBN 5—298—00681—7

Китап Арча төбәге тарихын яктырта. Киң катлау укучыларга тәкъдим ителә.

А $\frac{0503020900-031}{М\ 132(03)-96}$ зак.— 96 ББК 63.3 (Р-Тат.)

ISBN 5—298—00681—7

© Татарстан китап нәшрияты, 1996
© Арча районы хакимияте, 1996

ТӨЗҮЧЕЛӘРДӘН

Арча төбәге — күп кенә атаклы мәдәният эшлеклеләребезнең туган ягы, үзенең хезмәт сөючән халкы белән шөһрәт казанган икмәкле җир. Аның бай тарихы, әлеге җирлектә туган һәм буыннан буынга туплана килгән рухи мирас бар. Ошбу китапны әзерләгәндә без әлеге хәзинәнең кечкенә генә булса да бер өлешен хәзерге буынга җиткерергә омтылдык. Әйе, өлешен. Чөнки бер китапта (җыентыкта) гына барлык «ак тапларны» да колачлау мөмкин түгел. Арча төбәгенең тарихы (аерым алганда, авыллар тарихы гына да) күп томнарны иңләрлек. Аларны дөньяга чыгару өчен еллар, зур матди чыгымнар таләп ителә. Ә хәзергә, безнең болгавыр чорда, әлеге җыентык белән канәгатьләнәбез. Әзме-күпме, укучыларга ирешә торсын.

Арча ягының XX гасыр тарихына караган мәсьәләләр фәнни-популяр һәм публицистик басмаларда яктыртылды. Шул сәбәпле, биредә бәян ителгән вакыйгаларның хронологик кысалары XIX гасыр белән чикләнә.

Китап нигездә тарихчы галимнәрнең һәм мәдәният эшлеклеләренең махсус язылган мәкаләләреннән, шулай ук элегрәк дөнья күргән кайбер язмалардан тупланды. Авторлар (эчтәлек буенча хронологик тәртиптә): Камил Низаметдинов (Арча төбәге тарихы), Марсель Әхмәтҗанов (Арча төбәгенең эпиграфик истәлекләре. Яңа Кенәр. Яхъя бине Сәфәргали (1758—1838) иҗаты. Габденнасыйр Курсави (1776—1812). Шиһабетдин Мәрҗани — якташыбыз. Мәгърифәтче Шәмсетдин Күлтәси хакында яңа мәгълүматлар), Рәшит Галләмов (Арча ягы авыллары XVI гасырдан XVII гасыр башына кадәрге дәвердә. Күлтәс авылы. Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларының барлыкка килүе һәм үсеше), Радик Салихов һәм Рамил Хәйретдинов (Тарихи һәм мәдәни истәлекләр), Мөхәммәт Мәһдиев (Шагыйрьнең бишеге). Район хакимиятенең теләген искә алып, басманы ике телдә дөньяга чыгаруны хуплыйбыз. Китапның ахырында Арча төбәге тарихы буенча өстәмә әдәбият исемлеге тәкъдим ителә.

ОТ СОСТАВИТЕЛЕЙ

Арский район — родина многих выдающихся деятелей национальной культуры. Он славится своим хлебом и трудолюбивыми людьми, имеет богатую историю. Составляя эту книгу, мы хотели довести нынешнему поколению хотя бы часть того наследия, которое накопилось в течение столетий. Правда, одна лишь книга не сможет охватить все прошлое Арского района, которое заслуживает серию томов.

Вопросы истории Арского края XX в. нашли свое освещение во многих научно-популярных и иных публикациях, солидных изданиях. Поэтому хронологические рамки содержания данного сборника ограничиваются XIX в. Авторы: Камиль Низаметдинов (История Арского края), Марсель Ахметзянов (Эпиграфические памятники Арского района. Новый Кинер. О творчестве Яхъи ибн Сафаргали (1758—1838). Габденнасыр Курсави (1776—1812). Шигабутдин Марджани (1818—1889). Новые сведения о просветителе Шамсутдине Культеси), Рашит Галлямов (Селения Арской стороны в XVI — начале XVII вв. Из прошлого деревни Культесь. Верхний, Средний, Нижний Пшалым: история возникновения и становления), Радик Салихов и Рамиль Хайрутдинов (Памятники истории и культуры), Мухаммат Магдеев (Колыбель поэта). Издается на татарском и русском языках. В конце книги предлагается список дополнительной литературы по истории Арского района.

Ак юл!

Һәр төбәкнең үзенә генә хас йөзе, тарихи традицияләре бар. Безнең Арча төбәгенең төп горурлыгы — үзләренең акыл сәләте, хезмәт сөючәнлеге белән рухи һәм матди байлыклар тудырган кешеләр. Әйе, кешеләр. Чөнки аларның сокландыргыч эшчәнлеге нәтиҗәсендә генә искиткеч бай мирас тупланган, Арча җире элек-электән милли мәдәният үзәге, икмәкле төбәк буларак шөһрәт казанган. Бүгенге көндә бабаларының изге гамәлләрен оныклары дәвам итә. Шуңа күрә дә зыялылык һәм тырыш хезмәт чыганагының саекмавына янәдән инанабыз, киләчәккә өмет белән карыйбыз.

Төбәгебез татарның атаклы шәхесләрен күпләп биргән. Без моның белән горурланабыз. Әлеге чынбарлыкның тамырлары тирәннән килә, чөнки турыдан-туры дәүләтчелек, зыялылык белән бәйле тарихи, мәдәни, сәяси һәм икътисади традицияләр безнең җирлектә гасырлар дәвамында ныгый барган. Болгар, Алтын Урда, һәм бигрәк тә Казан ханлыгы дәверләрендә Арча милли дәүләтчелекнең төп терәкләреннән берсе булган. Төбәгебез хәзерге чорда да (ул ничек кенә катлаулы, болгавыр булмасын) үзенең лаеклы урынын саклый. Моңа ышану өчен кайбер күрсәткечләргә күз салу да җитә.

Арча районы — Татарстанда иң зур районнарның берсе. Ул җөмһүриятебезнең төньяк-көнбатышында урнашкан һәм Мари республикасы, Биектау, Питрәч, Балтач, Саба, Әтнә районнары белән чикләшә. Анда зур тимер юл станциясе бар, башкалабыз Казанга кадәр үзәктән 60 чакрым.

Арча районының барлык мәйданы — 1843 км^2. Халкы — 50 мең кеше; шуларның 91 проценты — татарлар, 8 проценты — руслар, калган өлеше башка милләт вәкилләренә туры килә. Район үзәге булган Арча эшчеләр поселогында 15 мең кеше яши, күпчелекне татарлар һәм руслар тәшкил итә.

Район территориясендә 1 поселок һәм 29 авыл советы бар, алар 130 авылны берләштерә. 50 колхоз һәм совхозга 129,4 мең гектар җир беркетелгән. Җирле промышленность ширкәтләре, мәктәпләр эшли, соңгыларының саны арта

бара; төзүчеләр һәм механизаторлар әзерли торган училище-лицейлар, педагогик колледж, мәдәният йортлары һәм клублар, кинотеатр, шифаханәләр һ. б. үзләренең эшчәнлекләрен заман таләпләренә туры китереп коралар. Милли бизәлешле аяк киемнәре җитештерүче предприятиебезнең исеме дөньяда мәгълүм. Безнең яктан татарның атаклы галимнәре Габденнасыйр Курсави, Шиһабетдин Мәрҗани, Шәмсетдин Күлтәси һәм башкалар үсеп чыккан. Атаклы шагыйрь һәм язучылар Габдулла Тукай, Мәхмүт Галәү, Гомәр Бәширов, Мостафа Ногман, Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Рафаил Төхвәтуллин һәм башка бик күпләрнең исемнәре яхшы мәгълүм. Сәнгать осталары Нәгыймә Тажд[а]рова, Зөләйха Богданова, Габдрахман Сәлимов, Шамил Әхмәтҗанов, Рәбига Сибгатуллина, Айдар Фәйзрахманов, Гөлзада Сафиуллина, Люция Хәсәнова — безнең якташларыбыз.

Советлар Союзы Геройлары Валентин Ежков, Гани Сафиуллин, Гатаулла Салихов, Нәкыйп Сафин һәм шулай ук Социалистик Хезмәт Геройлары Мирбат Хәстиев, Стелла Габдрахманова, Дания Галимова, Шәрифулла Сәгъдуллин, Галимулла Әсхәдуллин, Илсур Шәйхетдинов, Дәүләт премияләре лауреатлары Әгъзам Хәсбиуллин, Гарифулла Хәйруллин, Эдуард Абульханов — районыбыз горурлыгы.

Атаклы драматург Галиәсгар Камалның балачагы безнең районда узган. Барыбызга да мәгълүм җырчы Федор Шаляпин 1895 елда Арчада училищеда укыган.

Арча төбәге — күренекле фән эшлеклеләре Рүзәл Йосыпов (Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Казан дәүләт педагогия университеты ректоры), Илтазар Терегулов (Татарстан Фәннәр академиясе академигы, Казан төзелеш-архитектура академиясенең кафедра мөдире), Рифат Корбанов (ветеринария фәннәре докторы), Җәүдәт Фәйзрахманов (техник фәннәр докторы, профессор, Казан дәүләт ветеринария институтының кафедра мөдире) һәм Николай Барышевның (техник фәннәр докторы) туган ягы.

«Уңдырышлы Арча туфрагы». Туры һәм күчерелмә мәгънәдә без шулай дибез.

Казанышлар һәм югалтулар белән сыналган хакыйкать: үткәнне белмичә торып киләчәкне корып булмый. Без халкыбыз туплаган бай мирасны һәм тәҗрибәне тирәнтен өйрәнгәндә генә асылыбызга кайта алачакбыз. Алдагы гомеребез өметле, киләчәк буын ышанычлы булып үссен дисәк, без әлеге байлыкны халкыбызга кайтарырга, балаларыбыз-

га һәм оныкларыбызга җиткерергә тиешбез. Менә шушы заруриятган чыгып, без ошбу китапны һичшиксез булдырырга һәм халкыбызга ирештерергә кирәк дигән карарга килдек. Әлбәттә, бер китап кына Арча төбәге тарихын сыйдырып та бетерә алмас, әмма «беренче карлыгач» (районыбыз тарихы китабы буларак) үзенең укучыларына барып җитсен, һәм барлык изге гамәлләребезгә рухландыручы, аз гына булса да билгесезлек томанын яктыртучы булсын иде. Хәерле сәгатьтә, ак юл сиңа, «беренче карлыгач»!

Вәгыйз Миңһаҗев,
Арча районы хакимияте башлыгы,
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты

В добрый путь!

Каждая земля, каждый район имеет свои исторические традиции. Главная гордость Арского района — это люди. Люди, которые своей мудростью, знаниями, трудолюбием создали духовное и материальное богатства. Благодаря их плодотворной деятельности и таланту накопилось огромное наследие, Арская земля испокон веков славилась как центр национальной культуры, хлебообильный край. Благородные дела и начинания предков продолжаются их внуками, правнуками. Поэтому мы уверены, что источники мудрости, учености и трудолюбия не иссякли, и смотрим в будущее с надеждой.

Наш район — родина многих выдающихся личностей — сынов и дочерей татарского народа. Мы гордимся этим. Исторические, культурные, политические и экономические традиции, впрямую связанные с государственностью и образованностью, на нашей Арской земле развивались и укреплялись в течение столетий. В эпохах Булгарского царства, Золотой Орды и особенно Казанского ханства Арск являлся одной из главных опор национальной государственности. И в наше время (хотя оно сложное и смутное) наш район сохраняет свое достойное место в развитии экономики и культуры Республики Татарстан. Нетрудно в этом убедиться, если взглянуть на некоторые современные показатели.

Арский район, один из крупнейших районов Республики Татарстан, расположен в центре северной стороны западного Предкамья и граничит с Республикой Мари-Эл, Высокогорским, Сабинским, Балтасинским, Пестречинским и Атнинским районами. Общая площадь составляет 1843 км², население — 50 тысяч человек (татар — 91, русских — 8 процентов). Районный центр — рабочий поселок Арск; находится в 60 км от столицы Татарстана — города Казани, связан железнодорожным сообщением, в нем проживают 15 тысяч человек (в основном татары и русские).

В районе 29 сельских и 1 поселковый советы народных депутатов, 130 населенных пунктов, 50 колхозов и совхозов, занимают 129,4 тысячи гектаров пашни. Работают предпри-

ятия местной промышленности, постепенно растет количество школ. Педагогический колледж, агротехнический лицей и профтехучилища, дома и дворцы культуры, кинотеатр, больницы и библиотеки перестраивают свою работу, деятельность в соответствии с требованием сегодняшнего дня. Единственное в мире предприятие, выпускающее обувь с национальным орнаментом — Арское производственное объединение национальной обуви удостоено золотой медали на ярмарке в Лейпциге в 1978 г.

Арская земля взрастила таких выдающихся татарских ученых, как Габденнасыр Курсави, Шигабутдин Марджани, Шамсутдин Культеси и др. Каждому известны имена выдающихся поэтов и писателей Габдуллы Тукая, Махмута Галяу, Гумера Баширова, Мустафы Нугмана, Гарифа Ахунова, Мухаммата Магдеева, Рафаила Тухватуллина и многих других. Хорошо известны в республике имена замечательных мастеров искусства, заслуженных и народных артистов Нагимы Таждаровой, Зулейхи Богдановой, Габдрахмана Салимова, Шамиля Ахметзянова, Рабиги Сибгатуллиной, Айдара Файзрахманова, Гульзады Сафиуллиной, Люции Хасановой и других.

Арчане гордятся своими земляками Героями Советского Союза Валентином Ежковым, Гани Сафиуллиным, Гатауллой Салиховым, Накипом Сафиным, также Героями Социалистического Труда Мирбатом Хастиевым, Стеллой Габдрахмановой, Данией Галимовой, Шарифуллой Сагдуллиным, Галимуллой Асхадуллиным, Ильсуром Шайхутдиновым, лауреатами Государственной премии Агзамом Хасбиуллиным, Гарифуллой Хайруллиным, Эдуардом Абульхановым.

Детство выдающегося драматурга Галиасгара Камала прошло в нашем районе. Великий Федор Шаляпин в 1895 г. учился в Арском училище.

Выходцами из нашего района являются видные деятели науки Рузяль Юсупов (академик АН Татарстана, ректор Казанского государственного педагогического университета), Ильтазар Терегулов (академик АН Татарстана, заведующий кафедрой Казанской строительно-архитектурной академии), Рифат Курбанов (доктор ветеринарных наук), Джавдат Файзрахманов (доктор технических наук, профессор, заведующий кафедрой Казанского государственного ветеринарного института) и Николай Барышев (доктор технических наук).

«Плодотворная Арская почва». Так мы говорим как в прямом, так и в переносном смысле.

Истина испытанная, доказанная достижениями и потерями: нельзя строить будущее, не зная прошлого. Только лишь в результате глубокого изучения богатого наследия и опыта, накопленных нашим народом, мы сохраним свое национальное лицо. Если мы стремимся к светлому будущему, хотим иметь достойную и надежную смену, то мы обязаны вернуть это богатство народу, довести его до наших детей и внуков. Исходя именно из этой исторической необходимости мы приняли твердое решение — способствовать рождению и изданию этой книги — «первой ласточки» (как книги по истории нашего района). Конечно, она не сможет охватить прошлое Арского района целиком, тем не менее нам очень хотелось, чтобы она увидела свет, дошла до читателей и приоткрыла занавес истории района.

В добрый путь, наша «первая ласточка»!

Вагиз Мингазов,
глава администрации Арского района,
депутат Государственного Совета
Республики Татарстан.

МӨХТӘРӘМ УКУЧЫ!

Ошбу китапның беренче битен ачу белән үк син чал тарих дөньясына чумарсың. Татар халкының үткәне данлы да, гыйбрәтле дә. Бу тарих халкыбызның бөеклегенә дә һәм шул ук вакытта аның изелеп яшәү чорына да шаһит, ул милләтебезнең үлемсезлеген, гыйззәтлелеген раслый. Татар язмышын Татарстан хәл иткән кебек, гомум рәвештә милләтнең киләчәге дә һәрвакыт Казан белән бәйле булган. Казан бәйсезлеген саклаган тәкъдирдә милләт азат булган, Казан яулап алынгач, татарлар изелүгә дучар ителгән.

Арча исә Казан язмышында мөһим урын тоткан. Шул сәбәпле әлеге тарихка багышланган китапның дөнья күрүе зур бер вакыйга буларак бәяләнергә хаклы. Арча җирлегендә югары үсешкә ирешкән мәдәният, авыл хуҗалыгы, һөнәрчелек һәм сәүдәгәрлек традицияләре милли яшәешнең көзгесе булып килгән. XVI гасыр башында мәскәүлеләр тарафыннан «оҗмах җире» буларак тасвирланган төбәктә Казан арты халкы бакчалар үстергән, байлыклар булдыра алган. Болар барысы да тырышлык һәм сәләт җимешләре, халкыбызның азат яшәве нәтиҗәләре. Арча халкы әлеге тормышны дошманнан саклаучыларның алгы сафында булган, Казан язмышындагы хәлиткеч вакыйгалар Арча җирендә башланган яки шунда тәмамланган. Укучы игътибарына тәкъдим ителүче китап нәкъ менә шуны раслый. Аның һәр бите безне теге яки бу дәвер белән кавыштыра, күңелгә Тукай моңнарын, бөек шагыйрьнең милләт өчен борчылу-кайгыруларын да иңдерә. Моның асылы — хезмәтнең тиешле профессиональ дәрәҗәдә язылуында, мөмкин булган барлык чыганакларны да үзендә туплавында, авторларның Арча ягына, халкыбызга бөек Тукайны биргән җиргә гашыйк булуларында.

Әлегәчә татар тарихы Казанны яулаучылар күзлегеннән чыгып кына күрсәтелә килде. Төп чыганаклар сыйфатында башлыча рус елъязмалары файдаланылды. Шунлыктан безгә чынбарлыктан аерылган, каһәрләнгән тарих тәкъдим иттеләр. Хәер, моны кемнәрнеңдер мәкерле сәясәте итеп кенә кабул итү бөтенләе белән үк дөреслеккә туры килеп бетмәс. Октябрь инкыйлабына кадәр яшәгән Н. М. Карамзин, С. М. Соловьев, В. О. Ключевский, совет чорында иҗат иткән М. Г. Худяков, Л. Н. Гумилев һәм кайбер башка тарихчылар татар тарихын мөмкин булган дәрәҗәдә объектив күрсәтергә тырышканнар. Әмма эш анда гына түгел, ә татар чыганакларының сакланмавында. 1552 елда Казан алынгач дәүләт архивы һәм милли китапханә юкка

чыга. Казан ханлыгының документлары бик аз сакланган, алары да Казанның үзендә түгел. Күптән түгел Төркия дәүләт архивларының генераль директоры Исмәт Бинарк Казанның беренче ханы Олуг Мөхәммәтнең Төркия солтаны Баязитка язган хатының оригиналга охшатып эшләнгән, тартмага салынган күчермәсен бүләк итте, һәм ул төрдәге документларның Төркия архивларында шактый икәнлеге хакында белдерде. Әлбәттә, эзләнүләр чит мәмләкәтләрдә генә түгел, Татарстанның үзендә дә, Россия архивларында һәм китапханәләрендә дә алып барылырга тиеш. Үз тарихыбызга үтеп керү өчен без археологик тикшеренүләрне дә киңрәк җәелдерергә тиешбез. Сиңа тәкъдим ителүче китап, мөхтәрәм укучы, шундый эзләнүләрнең беренче нәтиҗәләре буларак кабул ителсен. Бу — данлы тарихыбызны кире кайтаруның юл башы гына әле. Киләчәктә уңышлар мулрак булыр дип ышанабыз.

Казан арты халкы соңгы сиксән елда зур авырлыкларга дучар булды. Ул үзенең дистәләрчә мәчет-мәдрәсәләреннән мәхрүм ителде, йөзләрчә зыялыларын югалтты, колхозлар төзү елларында күп кенә гаиләләр, кулак мөһере тамгаланып, юкка чыгарылды. Әлегәчә без Бөек Ватан сугышы елларында Татарстан фронтларда 97 мең кешесен югалтты, дип килдек. Хәзер исә бу санның 330 меңнән артканлыгын беләбез. Барлык халкы өч миллионга да тулмаган Татарстан өчен моның ни кадәр олы югалту икәнлеген аңлау кыен түгел. Халкыбыз барлык авырлыкларны җиңеп, яңадан аякка басты. Арча ягы да яңадан мул уңышлар үстерә башлады. Аның халкы зур талантлар тудыру сыйфатын югалтмады. Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев һәм башкалар — моның ачык дәлиле.

Бүген халкыбызның киләчәге хәл ителә. Казан арты, аерым алганда, Арча районы моңа үзеннән зур өлеш кертә. Мөстәкыйльлек юлына басуыбыз милли яңарышка көчле этәргеч бирә. Юкка гына түгел, халкыбызның җиргә булган ихтирамы, аны эшкәртә белүе, башкаларны таң калдырырдай уңышлар алуы башлап Казан артында, шул исәптән Арча төбәгендә мөмкин булды.

Хәер, кыенлыклар да бар әле. Китапка бәя биргәндә аның укучыда тарихыбызга тирән ихтирам, туган төбәккә карата мәхәббәт уяту мөмкинлегеннән чыгып эш итәргә кирәк. Әгәр китап укучыны уйга сала, үткәннәребезгә карата ихтирам уята, киләчәгебезгә зур ышаныч тудыра ала икән, авторлар үз максатларына ирешкән дип саный алабыз.

Индус Таһиров,
Татарстан Дәүләт Советы депутаты, академик.

УВАЖАЕМЫЙ ЧИТАТЕЛЬ!

Открывая страницы этой книги, ты окажешься в мире седой истории. Многовековая история татарского народа имеет много славных страниц, но в ней немало периодов горечи и страданий. Во все времена будущее нации было связано с судьбой Казани, независимость которой означала независимость и величие, а ее завоевание—трагедию татарского народа.

В судьбе Казани, татарской государственности Арск имеет очень важное значение. Поэтому появление книги, посвященной его истории, следует воспринимать как большое событие. Высокоразвитые культура, сельское хозяйство, ремесленные производства и традиции торговли являлись как бы зеркалом национальной жизни. В регионе, который русские в XVI в. называли «подрайской землицей», население Заказанья развело прекрасные сады, накопило много материальных и духовных богатств. Это все—плоды трудолюбия и таланта народа, живущего на этой земле. Они были в первых рядах защитников независимости и свободы. Военно-политические события, связанные с судьбой Казани—столицы государства, очень часто начинались и завершались на Арской земле. В книге им уделено большое внимание. Каждая страница этого труда возвращает нас к минувшим столетиям, внедряет в наши сердца дух поэзии великого Тукая.

До этого история татарского народа преподносилась лишь с позиций завоевателей Казани, в качестве основных источников в основном использовались русские летописи. В итоге мы получили историю, далекую от реальности и справедливости. Правда, в этом нельзя усматривать только чью-то коварную политику. Известно, что в дооктябрьский и советский периоды были созданы исследования более объективного характера. Это—труды Н. М. Карамзина, С. М. Соловьева, В. О. Ключевского, М. Г. Худякова, Л. Н. Гумилева и др. Но дело не только в этом. Суть заключается в отсутствии комплекса татарских исторических источников. После завоевания Казани в 1552 г. были уничтожены почти все татарские рукописи, исчезли (или погибли) государственный архив и библиотека казанских ханов, от этого богатства сохранились лишь крупицы, и то не в самой Казани. Совсем недавно генеральный директор государственных архивов Турции Исмат Бинарк преподнес подарок—точный муляж письма-послания казанского хана Улуг Мухаммета султану Турции Баязиту. Господин Би-

нарк также сообщил, что в архивах Турции хранятся немало подобных документов. Несомненно, поиски с целью возврата исторических реликвий должны вестись не только за границей, но и в самом Татарстане и России. Чтобы наиболее полно представить прошлое своего народа, мы должны изучать исторические проблемы с привлечением целого комплекса самых разнообразных по форме содержания материалов и источников. Данная книга — один из первых опытов на этом пути.

За последние восемьдесят лет население Заказанья, как и весь татарский народ, пережил большие испытания и трудности. Были закрыты десятки мечетей, медресе, репрессированы многие ученые, деятели культуры. Многие семьи были раскулачены. До этого мы неустанно твердили, что на фронтах Великой Отечественной Татарстан потерял 97 тысяч своих сыновей и дочерей. Теперь уже знаем, что эти потери превышают 330 тысяч человек. Своим самоотверженным трудом наш народ снова встал на ноги. Арская земля превратилась теперь в хлебницу Татарстана, вырастила многих выдающихся деятелей науки и культуры, таких как Гариф Ахунов, Мухаммат Магдеев и др.

Сегодня решается вопрос будущего нашего народа. Заказанье, в частности, Арский район, вносит свою весомую лепту в экономику. Суверенитет и самостоятельное развитие дают мощный толчок национальному возрождению.

Правда, есть и трудности. Только в дружном труде и единстве мы сможем их преодолеть. Эту книгу надо оценивать с той точки зрения, что она должна способствовать росту интереса к прошлому, возрождать любовь к родной земле и народу, укреплять надежду на будущее. Если она действительно явится таковой, тогда можно будет сказать, что авторы достигли своей цели.

Индус Тагиров,
депутат Государственного Совета
Республики Татарстан, академик.

АРЧА
ТӨБӘГЕ
ТАРИХЫ

I. Чал тарих авазы

АРЧА ТӨБӘГЕ ТАРИХЫ

Арчаның барлыкка килүе һәм исеме

Идел һәм Нократ елгалары арасы — илебезнең күпмилләтле төбәкләреннән берсе. Биредә телләрнең өч олы группасына кергән — төрки, фин-угор һәм славян халыкларының вәкилләре яши. Алар таралыш алган, тормыш сөргән җирләрнең чикләре тарихи үсеш дәверләрендә үзгәреп торды. Бу күренешнең сәбәпләре җитештерү көчләренең һәм икътисади мөнәсәбәтләренең үсеше, күчү-күченү процесслары һәм эре сәяси берләшмәләрнең (дәүләтләрнең) барлыкка килүе белән аңлатыла. Әлеге халыкларның бу төбәккә килеп чыгулары һәм анда урнашып калулары — барысы да аерым бер тарихи вакыт аралыгында барды.

Безнең эраның III—IV гасырларыннан 1 меңьеллык ахырына кадәрге чорда Чулман—Нократ аралыгына күп мәртәбәләр төрки кабиләләр үтеп керәләр. IX—X гасырлар чигендә бу территориядә беренче дәүләт — Идел Болгарстаны барлыкка килә. Тора-бара ул үзенең чикләрен төньяк-көнчыгыш һәм төньяк-көнбатыш тарафларда киңәйтә.

Кайчандыр Чүриле, Урта Сәрдә, Сосновка, Өмбә авыллары урыннарында болгарлар яшәгәннәр. Археологик һәм нумизматик табылдыкларны өйрәнү нәтиҗәсендә, Р. Г. Фәхретдинов һәм А. Х. Халиков Казансу бассейны XII—XIII гасырларда ук болгарлар тарафыннан үзләштерелгән дигән фикергә килделәр[1].

Арча хакындагы беренче хәбәрләр рус чыганакларында — XVII гасырның соңгы чиреге елъязмасында һәм «Патша шәҗәрәсе китабы»нда сакланган[2]. Аларда 6804 (1296) елда Урда ханының Смоленск һәм Ярославль кенәзе Федор

---

[1] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория.— Казань, 1975.— С. 48; Халиков А. Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков.— Казань, 1976.— С. 3—9.

[2] Полное собрание русских летописей (далее — ПСРЛ): т. 31 — М.: Наука, 1968.— С. 79; т. 21.— СПб., 1908.— С. 309.

Чермныйга үзенең кызын никахлавы, бирнә сыйфатында Көнчыгыш Европаның 36 шәһәрен һәм шул исәптән Арчаны бирүе хакында бәян ителә.

Тарихи чыганакларда «Арча җире» хакында да телдә алына. Мәсәлән, гарәп сәяхәтчесе Әбу Хәмид әл-Гарнатиның XII гасыр уртасына караган хәбәрендә түбәндәге юлларны укыйбыз: «Болгарларның хакимияте аларга ясак түләүче кайбер өлкәләргә тарала... Бу өлкәләрнең берсе Вису (Ису), икенчесе Арв дип атала. Анда кондыз, ас, тиен аулыйлар»[1]. Археолог А. Л. Монгайт әлеге Арв өлкәсен рус елъязмаларында искә алынган «Арча җире» («Арская земля»)[2] дип уйлый.

Арча атамасының килеп чыгышы, аны нигезләүчеләр мәсьәләсендә берничә төрле фикер бар. Кайбер галимнәр Арчаны арлар (ягъни, удмуртлар) нигезләгән дип исәплиләр. Алар фикеренчә, Арча урынында кайчандыр арлар авылы булган, ә болгарлар аны, предметның һәм сыйфатның үзенчәлекләрен азрак дәрәҗәдә чагылдырган *-ча* аффиксы өстәп, «Арча» дип атаганнар[3].

Икенче бер караш буенча «Арча» топонимының нигезендә борынгы болгар-татар сүзе *«ур»* ята, дип уйланыла[4]. Соңгысы төрки халыкларда түбәндәге мәгънәләргә ия булган: 1. Озын чокыр, тирән сусыз чокыр, чокыр. 2. Нығытмалы чокыр, туфрак (балчык) өеме. 3. Кальга нығытмасы. Әгәр дә Арча кальгасы урнашкан җирнең физик-географик үзенчәлекләренә игътибар итсәк, әлеге мәсьәләдә бу мәгънәләрнең туры килүенә төшенү кыен түгел. Аерым алганда, 1900 елда «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре»ндә басылган «Казан губернасының Арча шәһәрендәге борынгы манара» дип аталган мәкаләсендә В. Л. Борисов Арча кальгасының отышлы стратегик халәте, аның гаять нығытылган булуы хакында яза[5].

Өченче фикер буенча «Арча» атамасының килеп чыгышы артыш агачы үсүенә нисбәтле рәвештә карала. Борынгы

---

[1] Монгайт А. Л. Абу Хамид аль-Гарнати и его путешествие в Русские земли 1150—1153 гг. //История СССР.—1959.—№ 1.—С. 171.

[2] Кара: ПСРЛ: т. 8—СПб., 1859.—С. 3; т. 25.—М.—Л., 1949.—С. 201; т. 24.—Пг., 1921.—С. 143; т. 18.—СПб., 1913.—С. 129; т. 15.—М., 1965.—С. 138; т. 11.—М. 1965.—С. 45.

[3] Кельмаков В. К. Происхождение и первые упоминания этнонима «ар» // Этнонимы.—М.: Наука, 1970.

[4] Саттаров Г. Ф. Арча атамасының килеп чыгышы // Совет мәктәбе.—1984.—№ 1.—21—24 б.

[5] Кара: Борисов В. Л. Древняя башня в г. Арске Казанской губернии // ИОАИЭ.—Казань, 1900.—Т. 16.—Вып. 3.—С. 295.

төрки телдә *артыш* сүзе «арча» рәвешендә йөргән. Әлеге фикер тарафдарлары «Арча» атамасын агач исеме (артыш — арча) белән бәйлиләр[1].

Дүртенче фикерне яклаучылар «Арча» атамасының килеп чыгышын чирмеш (мари) сүзе *«арча»* (кечкенә лар, тартмачык, шкатулка) белән нисбәтле рәвештә аңлатырга тырышалар, кальгага исемне, янәсе, ул тартмачыкка охшау сәбәпле, марилар кушкан дип уйлыйлар[2].

Бишенче фикер тарафдарлары «Арча» атамасын «аргы як» сүзтезмәсенә бәйләп карыйлар. Казан университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсенең сирәк очрый торган китаплар, кулъязмалар бүлегендә 3256 т саклау берәмлеге белән Арчадан ерак булмаган Бәрәзә авылы елъязмасы саклана. Әлеге чыганакның авторы (елъязмачы) Арча ягын билгеләү өчен еш кына «аргы як» сүзтезмәсеннән файдаланган.

Арчаның төзелү чоры мәсьәләсе буенча берничә фикер бар.

Кайчандыр Арча урынында удмурт (ар) авылы булган дип уйлаучылар Арчаның нигезләнүен Идел Болгарстаны оешканчыга кадәрге дәвер белән бәйлиләр.

Икенче бер караш буенча Арчаның төзелүе татар-монгол (Алтын Урда) чоры белән билгеләнә.

Әлеге мәсьәлә белән кызыксынучыларның өченче төркеме Арча Казан алынганнан соң төзелгән дип исәпли.

Дүртенче фикер ияләре Арчаның корылуын Петр I дәверенә кадәр «кичектерәләр». Хәер, бу карашның фәнни нигезе юк. Чөнки, беренчедән, бу гамәлнең зарурлыгы булмаса (Петр I нең Арчадан әһәмиятлерәк булган эшләре дә чиктән ашкан бит!), икенчедән, сакланып калган тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар әлеге карашның ихтималлыгын бөтенләй юкка чыгаралар.

Безнең уйлавыбызча, Арча, болгарларның чик буендагы кальгасы буларак, XIII гасыр башында төзелгән. 1205 елда Казансу тамагында урнашкан Казан тар-мар ителгән, таланган. Нәтиҗәдә, җирле халык Казансу буйлап югары күтәрелергә һәм аңарчы чик буе кальгасы булган Иске Казан урынында төпләнергә мәҗбүр булган. Кенәзлек башкала-

---

[1] Кара: Гәрәй Йосыф. Сүз җыярга килегез // Казан утлары.—1969.— № 10.—150—161 б; Фәхретдинов Р. Г. Ташлар моңы / Археолог язмалары — Казан, 1978.—163—169 б.; Сафин Ш. К истории Арска // К коммунизму (Арск).—1984.— № 84.

[2] Троицкий В. П. Черемисско-русский словарь // ИОАИЭ.—Казань, 1893.— Т. II.— Вып. 2.— С. 1—24.

сын яңа урынга күчерү белән төньяк-көнчыгыш чикләрне өстәмә рәвештә ныгытуда ихтыяҗ туган. Арча шулай барлыкка килгән.

Арча кенәзлеге[1] — Казан ханлыгының бер өлкәсе

200 елдан артык хөкем сөрү дәвереннән соң Алтын Урда таркала башлый. Сәяси вакыйгалар Арча төбәгендә яшәгән халык тормышында да тирән эз калдырган. Феодалларның үзара ызгыш-сугышлары, Урдадан килгән һәм башка кенәзләрнең һөҗүмнәре элгәреге болгар мәдәнияте таралган өлкәләрдә (Болгар, Сувар, Җүкәтау, Биләр төбәкләрендә) җитештерү көчләренең таркалуына китергән. Халыкның Кама алдындагы төбәкләргә күчү процессы тизләнгән.

XV гасыр башында әлеге җирләрдә, яңартылган икътисади нигездә, җирле (традицион) дәүләтчелек торгызыла. Таркалган феодаль кенәзлекләр (биләмәләр) көчле сәяси организмга — Казан ханлыгына берләшәләр. Соңгысының төп җирләре, нигездә, хәзерге Татарстанның Кама алды төбәкләрен — бай феодаль биләмәләр булган өлкәләрне колачлаган. Казан — дәүләтнең сәяси һәм икътисади үзәге булган.

Казан ханлыгы хәрби-административ нисбәттә Галич, Алат, Арча, Җөри һәм Нугай даругаларына (юлларына) бүленгән. Үз чиратында һәр даруга (юл) йомышлы һәм ясаклы «йөзләр»дән торган. Традицион рәвештә даругалар XVIII гасырга кадәр (кертеп) сакланган[2]. Арча — шул исемдәге даруганың (юлның) үзәге булган. Казан ханлыгы оешудан башлап Арча даругасы әлеге дәүләтнең составына кергән. Тарихи үсеш-үзгәреш барышында аларның язмышы уртак булган. Мәскәү дәүләте һәм Казан ханлыгы арасындагы көрәш белән бәйле вакыйгаларда да бу хәл ачык күренә. Арчада гадәттә кайбер гаскәрләр тупланган, анда еш кына җиңелгән казанлылар җыелганнар, яңа көрәшләргә, сугыш хәрәкәтләренә әзерләнгәннәр.

Территориясе һәм халкы. Арча кенәзлеге Казан ханлыгының төньяк-көнчыгыш өлешен биләгән. Көнчыгыш чик Нократ (Вятка) елгасына кадәр диярлек барып җиткән.

---

[1] Кенәзлек — бу очракта аерым бер сәяси-административ берәмлеккә карата шартлы рәвештә кулланылган билгеләмә, чөнки татарларда кенәзләр дип аталучы катлау булмаган һәм ул кенәзлек дип тә исемләнмәгән. Соңгысы артында әмирлек, билек күздә тотыла.

[2] История Татарской АССР.— Казань, 1968.— С. 84—85; шулай ук кара: Очерки истории Марийской АССР.— Йошкар-Ола, 1965.— С. 65.

Төньяк чикләр исә төгәл генә ачыкланмаган. Әлеге төбәккә чиктәш булып яшәгән марилар һәм удмуртлар өлешчә Казан ханлыгына, ә аларның төньяк өлкәләре Руська буйсынган. Ул чордагы елъязмалардагы мәгълүматлардан күренгәнчә, Арча юлы (даругасы, ягъни өлкәсе) үз карамагына Ашыт, Илләт һәм Уржум елгалары буйларындагы җирләрне колачлаган. Шулай итеп, Арча кенәзлегендә төрле халыклар — удмуртлар (арлар), марилар (чирмешләр) һәм төп халык булган татарлар яшәгәнлегенә шик калмый. Даруга (юл) — башында татар аксөяге яки башка феодаллар торган олысларга һәм йөзләргә бүленгән.

Хуҗалык тәртибе. Идел буе халыкларының сәяси тормышында зур үзгәрешләр булып узса да, аларның хуҗалык халәте үзгәрешсез калган. Халыкның хуҗалык эшчәнлегенең төп тармагы — бөртеклеләр үстерүгә корылган игенчелек булган. Кешеләр яңа җирләр үзләштергәннәр, үз хуҗалыкларын нигезләгәннәр. Элек (Болгар дәүләте чорында) далалы кара туфраклы җирләрне үзләштерү өстенлек итсә, хәзер инде игътибар урман туфрагына юнәлдерелгән.

Шул ук вакытта кайчандыр болгарлар тарафыннан хуҗалыкка кертелгән авыл хуҗалыгы техникасы файдаланылган. Туфракны элгәреге эшкәртү өчен мәгъдән (металл) төрәнле сабан, йомшак туфраклы җирләрне сөрү өчен җиңел сука файдаланылган. Болгар дәүләте чорыннан калган өч басу системасы һәм төп культуралар (бодай, арпа, арыш, карабодай, борай, тары, борчак, ясмык) сакланган. Уңышны җыю өчен кулланылган ураклар һәм чалгылар болгарларның шундый ук хезмәт коралларыннан аерылмаганнар.

Терлекчелек мал-туарны аранда асраудан гыйбарәт булган. Җәен печән әзерләнгән. Йорт хайваннарыннан вак һәм эре мөгезле терлек, шулай ук кош-корт үрчетелгән. Авыл халкы, хуҗалыкның төп тармакларыннан тыш, умартачылык, аучылык һәм балыкчылык белән шөгыльләнгәннәр.

XV гасырда — XVI гасырның беренче яртысында һөнәрчелек алга китә. Авыл халкы һөнәрчеләр өчен чимал һәм азык-төлек әзерләп, үз чиратында алмашка көнкүреш кирәк-яраклары һәм башка төрле әйберләр алган. Һөнәрчелекнең үсүе, беренче чиратта, XIII гасырның икенче яртысыннан башлап күп кенә һөнәрчеләрнең — осталарның Кама аръягыннан күчеп килүе белән бәйләнгән. Һөнәрчеләрнең ишәюенә авыл халкы да өлеш керткән. Мәгъдәнчеләр (металлурглар) һәм тимерчеләр эшчәнлеге икътисади үсештә зур әһәмияткә ия булган. Алар чуен койганнар, тимер эреткәннәр, хезмәт һәм сугыш кораллары җитештергәннәр. Һөнәрчелекнең кулланма төрләре дә алга киткән. Затлы метал-

лар эшкәртүдә болгар традицияләрен дәвам итеп һәм еш кына катлаулы алымнар белән ювелирлар төрле-төрле бизәнү әйберләре ясаганнар. Традицион һөнәрләрдән тире иләү һәм күн эшкәртү өлкәсендә дә зур казанышларга ирешелгән. Күннән тегелгән аяк киемнәрен Казан ханлыгы чикләреннән еракларда да бик теләп алганнар. Хәзерге вакытта да Арча милли аяк киемнәре производство берләшмәсенең продукциясе даими рәвештә югары бәяләнә, аңа ихтыяҗ зур.

Һөнәрчелек һәм авыл хуҗалыгы җитештергән продуктлар эчке һәм тышкы базарларда сатылган. Төрле илләрдән килгән сәүдәгәрләр яшәгән Казан ханлык эчендә генә түгел, бәлки бөтен Идел-Кама (Чулман) буйларындагы иң эре сәүдә үзәкләренең берсе була. Араның якын булуы сәбәпле Арча һөнәрчеләре әлеге үзәктән, сәүдәдән зур файда күргәннәр. Ханлыкның башка шәһәрләрендәге кебек Арчаның да үз базары булган[1].

Җәмгыять строе. Ш. Ф. Мөхәммәдъяров, Казан ханлыгындагы җир хокукы мәсьәләләрен өйрәнеп, «борынгы игенчелек мәдәнияте Казан ханлыгы оешканчы ук аның җирлегендә феодаль мөнәсәбәтләр үсеше өчен нигез булган» дигән фикергә килде[2]. Казан ханлыгы оешу (XV гасырның 30—40 нчы еллары) алдындагы дәвердә Урта Идел буйларында феодаль строй чәчәк ату чоры кичерә. Феодаллар төрле төркемнәргә [ханнар, әмирләр, морзалар, оланнар (угланнар), казаклар, дин әһелләре] бүленәләр.

Арча кенәзлеге шундый ук җәмгыять строенда яшәгән дәүләтнең бер өлеше (өлкәсе) була. Андагы феодалларның югары катлавы әмирләрдән (бәкләрдән, кенәзләрдән) торган. Соңгылары исә бер үк вакытта үз өлкәләреннән туплангган гаскәрләрнең хәрби җитәкчеләре дә булганнар. Әмирләрдән кала икенче, ишлерәк булган феодаль төркемгә морзалар (дворяннар) кергән. Казан ханлыгындагы кебек үк, Арча кенәзлегендә дә әмирләр һәм морзалар төп (иң эре) җир биләүчеләр булганнар[3].

Хәрби башлыклар булган оланнар (уланнар, угланнар) — йомышлы хезмәттәге феодаллар.

---

[1] Кара: Артемьев А. Арск // Казанские губернские ведомости.— 1874. —№ 9.— С. 122; Очерки истории Марийской АССР.— Йошкар-Ола, 1965.— С. 76.

[2] Мухаммедьяров Ш. Ф. Земельные правоотношения в Казанском ханстве.— Казань, 1958.— С. 3.

[3] Кара: История Татарской АССР.— Казань, 1968.— С. 81; История Татарии в материалах и документах.— М., 1937.— С. 129.

Иң түбәнге феодаль төркем — хан гаскәрләренең даими үзәген төзегән казаклар. Аларга, Ш. Ф. Мөхәммәдьяров фикеренчә, хәрби яки башка төрле хезмәтләре өчен бүләк рәвешендә һәм вакытлыча файдалануга крестьяннар тарафыннан эшкәртелгән дәүләт җире бирелгән.

Дин (мөселман) әһелләре — феодал сыйныф эчендәге аерым бер төркем.

XV гасыр ахыры — XVI гасырның беренче яртысындагы сәяси вакыйгалар. 1487 елда Казан дәүләте өстеннән Рус дәүләте протектораты (Мәскәүгә бәйлелек) урнаша. Тәхеткә Мәскәү өчен кулай булган хан — Мөхәммәдәмин утыртыла. Беренче унъеллык тыныч уза. Әмма 90 нчы еллар уртасында көнчыгыш фиркасе ханга каршы чыга һәм тәхеткә Себер ханзадәсе Мамукны чакыра. Мамук, Казан ханы булып алгач та, фәкать үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта башлый, Казан аксөякләрен төрмәгә яба, «кунакларны һәм халыкны талый»[1]. Талаулар, җәберләүләр һәм башбаштаклыклар нәтиҗәсендә ул халыкта нәфрәт уята. Берничә айдан соң Арча кешеләре аңа каршы баш күтәрә. Мамук аларны бастырырга дип «Арча шәһәрчеге астына гаскәр белән килә». Арча кенәзләре үз шәһәрләрен саклап калу өчен ханга каршы аяусыз көрәшкә керәләр. Шул ук вакытта хан белән килгән Казан кенәзләре Мамукны калдырып кайтып китәләр, Казанны ныгыталар. «Мамук патшаны шәһәргә кертмиләр, аларның кенәзләренә каршы барганы, кунакларны һәм халыкны талаганы өчен аны гаеплиләр». Бу хәлдән соң Мамук «Казаннан китә һәм юлда үлә».

XVI гасыр башында Казанда Мәскәүгә каршы булган фирка көчәя. Бу исә 1505 елда булып узган вакыйгаларда да чагыла. Ул чакта рус сәүдәгәрләре талана, рус илчесе Михаил Кляпин кулга алына. Казанлылар зур күләмдәге байлыкларга, мөлкәткә ия булалар. Казанның 60 мең кешелек гаскәре, шул исәптән 20 меңләп нугай, Түбән Новгород янына килә. Әмма аның явы кире кагыла. Моңа җавап йөзеннән рус хөкүмәте 100 мең кешелек гаскәр туплый. 1505 елда бөек кенәз Василийның бертуганы кенәз Дмитрий Иванович җитәкчелегендәге рус гаскәрләре Казан янына килә. Бу вакытта казанлылар «уяу булмыйлар, Арча кырында бәйрәм итәләр»[2]. Бәйрәм барганда руслар кинәттән һөҗүм-

---

[1] Кара: ПСРЛ: т. 6.— СПб., 1853.— С. 41; т. 78.— СПб., 1859.— С. 231—232; т. 20, ч. 2.— СПб., 1914.— С. 364; т. 24.— Пг., 1921.— С. 242; т. 28.— М.— Л.: Наука, 1963.— С. 328; т. 33.— Л.: Наука, 1977.— С. 131.

[2] ПСРЛ: т. 19.— СПб., 1903.— Гл. IX.— Столб. 26.

гә ташланалар һәм җиңүгә ирешәләр. Казанлыларның бер өлеше шәһәргә, якындагы урманнарга һәм Арчага кереп качарга өлгерә. Җиңел генә җиңүдән кәефләре күтәрелгән руслар тантана итәләр, бәйрәм ясыйлар. Өч көн уза. Шул вакыт эчендә казанлылар коралланалар һәм ярым йокылы русларга һөҗүм итәләр. Елъязмада тасвирланганча «Арча кыры һәм падишаһ болыны мәетләр белән тула, канга батырыла... Йөз меңнән җиде мең рус сугышчысы кала...»

Вологда-Пермь елъязмасындагы хәбәрләрдән күренгәнчә, 1530 елда «бөек кенәз үзенең воеводаларын Казанга, хыянәте сәбәпле, имансыз («безбожный») патша Сафа-Гәрәйгә каршы җибәрә»[1]. Күп санлы рус гаскәре Казан янына килә һәм «Болак артындагы кирмәнне ала..., патша Казаннан чыгып Арча шәһәрчегенә китә». Кенәз Оболенский гаскәрләрнең бер өлешен алып Арча шәһәренә таба кузгала, ә кенәзләр И. Ф. Бельский, М. В. Горбатый, һәм М. Л. Глинский Казан янында калалар. «Шул чакта казанлы чирмешләр киләләр, Оболенскийны һәм башка кенәзләрне үтерәләр. Моңа ачуы килгән Бельский «Казанга һөҗүм итә, шәһәрне аттыра башлый һәм күп кенә кешеләрне кыра». Казанлылар Мәскәү воеводаларыннан һөҗүмне туктатуларын үтенәләр. Бельский үтенечне канәгатьләндерә. Казан илчеләре бөек кенәз Василий янына киләләр һәм элек үзләрендә хан булган Шаһгалине янә тәхеткә утыртуны сорыйлар. Сөйләшүләр барышында алар әлеге кандидатурага казанлыларның гына түгел, Арча кенәзләренең һәм шулай ук «барлык чирмешләрнең дә риза булуын белдерәләр».

1548 елның февраленнән Рус дәүләте берничә мәртәбә Казанга яулар оештыра, соңгылары 1552 елда ханлык башкаласын алу белән тәгәлләнә.

Әлеге яулар вакытында авыллар талана, юкка чыгарыла, икътисад бөлгенлеккә төшә. Казан ханлыгының бер өлкәсе буларак, Арча кенәзлеге Мәскәүгә каршы сугышта актив катнаша. Ул Казанга гаскәр, сугыш кирәк-яраклары җибәрә, 1552 елның җәендә (хәрби-сәяси хәл катлаулангач) кенәзләр (әмирләр) Япанчы һәм Явуш җитәкчелегендә сугыш хәрәкәтләре оештыра. Соңгылары исә Казан янында торган рус гаскәрләренә җитди һөҗүмнәр ясыйлар[2]. Рус гаскәрләре, арчалыларның Казанга ярдәмгә килүен тоткар-

---

[1] ПСРЛ: т. 26.—М.—Л.: Наука, 1959.—С. 314.

[2] Кара: ПСРЛ: т. 13.—М.: Наука, 1965.—С. 206—211; т. 20, ч. 2.—СПб., 1914.—С. 520—523; т. 29.—М.: Наука, 1965.—С. 99, 101 196—197.

лау өчен, Арча кырында махсус манаралар корырга булалар. 1552 елның 30 августында дошман, Япанчы һәм Явуш гаскәрләрен алдап, андуга (засадага) кертә һәм «татарларны кыралар...» Бу вакыйгадан соң да Арча кенәзлеге гаскәрләре руслар тылында сугыш хәрәкәтләрен туктатмыйлар. 6 нчы сентябрьдә «падишаһ (государь) Арча ягына һәм [шундагы] кирмәнгә үзенең воеводалары белән өч полк җибәрә». Әлеге яу вакытында Казан артында күп кенә ныгытылган кальгаларның булуы ачыклана. «Воеводалар кузгалды, воеводаларның полклары алдыннан җәяүле стрелецлар һәм казаклар барды. Биек тау өстендәге кирмән янына килделәр. Аларның кирмәннәре бурадан салынган, туфрак өеме өстендә утыра, күп кенә урыннарда саклану сызыклары (засеки), ә алар арасында үтеп булмаслык сазлыклар бар»,—диелә елъязмаларда.

Зур сугыш була. Кирмәнне батырларча саклыйлар. Шул ук вакытта А. Б. Горбатый һәм З. П. Яковля башка юл белән китәләр һәм кальга каршына килеп чыгалар. Биредә дә «зур кирмәннәр төзелгән, урман бик куе» була. Бу кальга да тиз генә бирелми, көчле каршылык күрсәтә. Аны алганда «күп кенә татарларны кыралар». Р. Г. Фәхретдинов бу кальганы кайчандыр Биектау һәм Арча арасында торган Иске Казан дип исәпли[1]. Әлеге кальгалардан башка тагын берничә кирмән булган. Аларның берсе Троицкое авылына каршы җирдә урнашкан. «Генераль бүлү актлары»нда бу хакта: «Ике яклап туфрак өеме рәвешендә ясалган борынгы балчык ныгытма»,—диелә[2].

Рус гаскәрләре «сугышлар белән һәм авылларны яндырып Арча шәһәрлегенә баралар, һәм, Арча шәһәрлегенә килеп, боярлар һәм воеводалар патша полкы башлыгын җибәрәләр, үзләре, шәһәрлек янында ике көн торганнан соң, икенче юлдан Казан янына киттеләр»—елъязмада әлеге вакыйга шул рәвешле тасвирлана.

1552 елгы дәһшәтле вакыйгаларның шаһиты, Иван IV нең гаскәр башлыгы кенәз Андрей Курбскийның хатирәләрендә түбәндәге юллар бар: «Рус гаскәрләре Казаннан унике миль ераклыктагы Арча шәһәренә барып житәләр. Аның диварлары янына килгәч басурманнар нык сугыштылар;... ут яудырып һәм кул сугышында безнекеләр аларны җиңделәр;

---

[1] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория.—Казань, 1975.—С. 81.

[2] Порфирьев С. Древности Казанского края в актах генерального межевания // ИОАИЭ.—Казань, 1904.—т. 20.—Вып. 1—6.—С. 11.

басурманнар качты, безнекеләр аларны куа бардылар»[1].

Арчаны яулау хакында исеме мәгълүм булмаган автор 1565—1566 елларда түбәндәге юлларны язган:

«Взято множество всякой рухляди,
И скота взято много домашнего.
Не имели потерь наши воины,
Даже малых при взятии крепости:
Отворили им ворота жители
И впускали к себе победителей.
Не пустив в них стрел ни единые,
Даже камни не бросивши малого
У острога они только первого
Трое суток стояли осадою,
Но убитых и тут у них не было.
Этот первый острог Арским звавшийся,
Был подобен во всем граду твёрдому,
Имел башни и стены с бойницами,
И людей проживало в нём множество.
И его берегли так старательно,
Что никто не мог взять этой крепости
С дня его основания самого;
От Казани она расположена
Во шестидесяти верстах к северу,
В местах крепких и трудных для воинов,
В лесных дебрях с болотами многими
И ведет к ним один путь единственный.
Семион князь с его воеводами,
Видя крепость-острога имевшего
До пятнадцати тысяч защитников,
Подвезли туда пушки с пещалями
И по Арску бить начали ядрами»[2].

Арча төбәге Рус дәүләте составында

1552 елның 2 октябрендә Явыз Иван гаскәрләренең озакка сузылган һөҗүмнәре, канкойгыч сугышлар нәтиҗәсендә Казан яулап алына. Күпчелек халык Казан артындагы авылларга барып урнаша.

---

[1] Курбский А. М. и царь Иван IV Васильевич Грозный. / Издание Глазунова И.—СПб., 1902.—С. 20; К 350-летию покорения Казани. 1552—1902. Подлинная о Казанском походе запись Царственной книги 1552 г. и сказание князя Курбского о покорении Казани.—М., 1902.—С. 128—129.

[2] Цит.: Сафин Ш. К истории Арска // К коммунизму (Арск).—1984.— № 92.

Казан дәүләтен яулауның беренче көннәреннән үк патша хөкүмәтенең Урта Идел буйларында яшәгән рус булмаган халыкларга карата сәясәтендә төп урынны тулысынча христианлаштыру, руслаштыру гамәлләре били. Хәер, биредә җитди уңышларга ирешелмәсә дә, сакланып калган тарихи чыганакларда Алат һәм Җөри юлларында (даругаларында) яшәгән халыкның шактый өлеше чукындырылуы хакында бәян ителә[1]. Ихтимал, моның сәбәпләре әлеге төбәкләрдә яшәгән җирле аксөякләрнең XVI гасырның икенче яртысында Россиягә буйсынуга каршы аяусыз көрәш җәелдерүеннән дә киләдер. Мәскәү хөкүмәте үткәргән җәзалау чаралары нәтиҗәсендә җирле феодаллар өлешчә юк ителә, өлешчә сөрелә, аларның җирләре патша хөкүмәтенә хезмәткә күчкән, чукынган кешеләргә бирелә. Шул рәвешчә үзәк властьның төбәктә төп таянычы булган йомышлы кешеләр катлавы барлыкка килә.

Ясаклы халык нигезендә чукынуны кабул итми. Әмма патша хөкүмәте тарафыннан үткәрелгән изү сәясәте еш кына көчләп руслаштыруга һәм христианлаштыруга дучар итә, колониаль өлкәләрдә ике катлы (сыйнфый һәм милли) изү урнашуга китерә.

Шул ук вакытта рус хөкүмәте Арча төбәгендә яшәгән халыкны төрле урыннарга сөрү, күчерү сәясәтен дә гамәлгә кертә. Аерым алганда, Оренбург губернасына кергән Нагайбәк авылы кешеләре үзләренең бабалары итеп Явыз Иван дәверендә чукындырылган арчалыларны исәпләгәннәр[2].

1648 елда Сембер сызыгын (чиген) төзү башлана. Аның эчке ягында берничә бистә нигезләнә, аларга төрле җирләрдән сугышчылар китерелә. Арчадан 50 атлы казак җибәрелә. Аларга җир бирелә. Сала үзе Арча бистәсе дип атала башлый[3].

1703 елда Кама аръягында Сергиевск шәһәре төзелә. 1704 елда Мәскәүдән аны сүтеп Терек елгасы буена күчереп салырга кушылган фәрман килә. Әлеге эшләргә Казан губернасы халкы тартыла, ул шәһәрдә яшәүчеләр арасында Арча кешеләре дә була[4].

---

[1] Писцовая книга Казанского уезда 1602—1603 гг.— Казань, 1978.— С 12.

[2] Витебский В. Н. Сказки, загадки и песни нагайбаков Верхне-Уральского уезда Оренбургской губернии // Труды IV Археологического съезда.— Казань, 1871.— Т. 2.— С. 258.

[3] Кара: Мартынов П. Остатки старины, сохранившиеся в Симбирском уезде.— Симбирск, 1896.— С. 1—3.

[4] Рычков П. И. Топография Оренбургской губернии.— Оренбург, 1887.— С. 315.

Елъязмаларда күрсәтелгәнчә, Явыз Иван Казан ханлыгында хөкем сөргән идарә системасын үзгәртмәскә булган. Шул максат белән ул «барлык олыслардагы кара халыкка, ясаклыларга бернидән дә курыкмыйча падишаһка (государьга) килсеннәр өчен жалованный грамоталар юллаган». Аларда патша «элгәреге Казан падишаһларына түләгәнчә үк ясак түләүне» таләп иткән. Җавап йөзеннән арчалылар «казаклар Шимайны һәм Күбешне» җибәргәннәр. Алар үзләрен рус карамагына (подданство) алуны һәм «патшаның ярлыкау сүзен җиткерергә, куркудан таралышкан халыкны җыярга тиешле» патша вәкилен җибәрүне сораганнар[1].

Арчалылар янына бояр улы Никита Казаринов һәм Камай морза җибәрелә. Соңгылары 10 октябрьдә күп кенә арчалылар белән кире әйләнеп кайталар. Ясак җыю эшләре белән җитәкчелек итү патша тарафыннан кенәз А. Б. Горбатыйга йөкләнә. Әмма Иван IV нең Мәскәүгә кайтып китүеннән ике ай да үтми — яуланган җирләрдә баш күтәрүләр башлана. А. Б. Горбатый Арча ягына гаскәр белән Камай морзаны һәм бояр улы Казариновны җибәрә. Соңгылары Арча ягында сугыш хәрәкәтләре җәелдерәләр, баш күтәрүчеләрне тар-мар итәләр. Кулга алынган 38 кеше Казанга китерелә һәм «хыянәтләре өчен» дарга асыла.

1552 елның декабрендә бөтен Арча ягын иңләгән баш күтәрүләрнең беренче этабы җиңелү белән тәмамлана.

Аны бастырудагы рәхимсезлек хәрәкәтнең яңа күтәрелешенә китерә. Воеводаларның берни белән дә исәпләшмичә ясак җыярга омтылуы элеккеге Казан ханлыгы аксөякләренең исән калган өлешенең Россиягә кушылуга каршы өндәүләре өчен уңай шартлар тудырган.

1553 елның мартыннан баш күтәрүләрнең яңа этабы башланган. Арча ягы хәрәкәтнең үзәге буларак күтәрелгән. Баш күтәрүчеләр элек уңышларга ирешәләр, җиңүләр яулыйлар, Мишә елгасы буенда ныгытылган кирмән төзиләр. Хәрәкәтнең җитәкчеләреннән, ихтимал, элеккеге Казан ханлыгы аксөякләренең югары катлавы вәкилләре булган Тугай морза уллары мәгълүм.

Мәскәүдән яңа хәрби көчләр җибәрелә. 1554—1555 елларда алар җәелдергән сугыш хәрәкәтләре, төбәкнең шактый зур өлешен биләсә дә, гел уңышлардан гына тормаган. Бу чорда патша хөкүмәтенең баш күтәрүчеләр арасында ызгышлар, таркаулык тудыру, аларны бер-берсенә каршы кую максаты белән «Казан кешеләре»нә каршы шул ук казанлылар кулы белән көрәшү сәясәте бик ачык чагыла.

---

[1] Кара: ПСРЛ: т. 13.— М.: Наука, 1965.— С. 221; т. 20, ч. 2.— СПб., 1914.— С. 532; т. 29.— М.: Наука, 1965.— С. 110, 205.

Елъязмаларда «Болын ягы халкының Арча ягына сугыш белән баруы» һәм, киресенчә, «Тау ягы халкының Болын ягының баш күтәрүчеләренә каршы як чабулары» хакында хәбәрләр күп. Милли-азатлык хәрәкәтенең үзәге һәрвакытта да Арча ягында булган, ә Болын ягы бу хәрәкәтнең һәр этабында да актив катнашып килгән. Тау ягы исә, Россиягә тугрылык саклап, Иделнең сулъяк ярында җәелгән каршылык хәрәкәтен бастыруда терәк булган[1]. Аерым алганда, 1556 елның язында, баш күтәрүләр яңа көч белән кабынганда, Тау ягы кешеләре хәйлә белән Арча төбәгендә барган азатлык көрәше җитәкчесе Мамич-Бердене кулга төшергәннәр — хәрәкәтне бастыруны тизләткәннәр[2].

1556 елның маенда рус гаскәрләре Арча ягына юнәлә. Мишә елгасы буенда көчле сугыш була. Баш күтәрүчеләрнең Дәүләк морза (Кулай морзаның бертуганы) җитәкчелегендәге төп көчләре патша гаскәрләре белән очрашалар һәм җиңәләр.

Әлеге вакыйгадан соң ун көн дәвамында воевода П. М. Морозов баш күтәрүчеләргә каршы җәзалау чаралары үткәрә: «Бөтен Арча җирләрен яулый, күп кешеләрне кыра һәм әсирлеккә ала». Июнь аенда русларның Шуйский җитәкчелегендә берләштерелгән гаскәрләре «Арча, Ашыт һәм Уржум аркылы Вяткага кадәр яу белән бара. Алар күп сугышалар, хатын-кызларны һәм балаларны әсирлеккә алалар, ирләрнең барысын да кыралар». 1556 ел азагында азатлык хәрәкәте учакларының барысы да диярлек бастырыла, баш күтәрүчеләрнең күбесе һәлак ителә. Исән калучылар Себергә качалар, кайберәүләр Казанга киләләр һәм «үзләренең гаепләре өчен кичерү сорыйлар». Әмма азатлык хәрәкәтенең ялкыны 1557 ел уртасына кадәр сүнми.

1552—1557 еллардагы вакыйгалар барышында патша хөкүмәте яңа ныгытмалар, даими гаскәрләрне урнаштырырлык кальгалар төземичә, яулаган Казан ханлыгы җирләрен Мәскәү хакимиятендә саклап калып булмаячагын ачык аңлый. Шул сәбәпле яуланган төбәкләрдә яңа кирмәннәр корыла башлый. Арча урынында бина кылынган яңа кальганың төзелү вакыты хакында каршылыклы фикерләр сакланган. Кайбер тикшеренүчеләр Арча урынында рус кальгасы 1554 елда салынган дип уйлыйлар[3].

---

[1] Ермолаев И. П. Среднее Поволжье во второй половине XVI—XVII вв. (Управление Казанским краем).— Казань, 1982.— С. 17—18.

[2] Кара: ПСРЛ: т. 13.— М.— Наука, 1965.— С. 266; т. 20, ч. 2.— СПб., 1914.— С. 560; т. 29.— М.: Наука, 1965.— С. 245.

[3] История Татарской АССР.— Казань, 1968.— С. 102.

Елъязмалардагы мәгълүматларга игътибар итик. Аерым алганда, «Летопись начала царства царя и великого князя Ивана Васильевича» елъязмасы Лаеш кирмәненең 1557 елда «Арча кешеләре» тарафыннан төзелүе хакындагы хәбәрне китерә[1]. Арча һәм Лаеш кальгаларының охшашлыгын[2] искә алып, аларның бер чордарак корылуы хакында фараз кыла алабыз.

Россия халыкларының социаль-икътисади үсеше, шулай ук патша хөкүмәтенең һәм урыннардагы властьларның сәясәте XVI гасыр ахырына социаль һәм сыйнфый каршылыкларның кискенләшүенә китерә. XVI гасырның икенче яртысында барган сугышлар һәм опричнина сәясәте нәтиҗәсендә хуҗалыгы бөлдерелгән һәм икътисады хәлсезләнгән илдә аңарчы күрелмәгән-булмаган күләмдә сыйнфый көрәш давылы өлгереп килә. Соңгысы XVII гасыр башында булып уза, ул үзенең барышында крестьяннар сугышы рәвешенә керә.

1603 елда башланган крестьяннар сугышы 1606 елда Урта Идел буйларына килеп җитә. Баш күтәрүчеләрнең хәрәкәте көчәя бара. Көз алдыннан инде сугыш ялкыны бөтен төбәкне чолгап ала, ел ахырына ул Вятка төбәгенә дә күчә. 1608 елда Тау ягы хәрәкәтнең үзәгенә әверелә, әмма Арча һәм аның тирәсендә яшәүче халык хөкүмәткә тугры булып кала. Бу хакта Вятка воеводасы М. Ф. Ухтомскийга җибәрелгән хәбәрдә бәян ителә[3]. Шулай итеп, XVI гасырның икенче яртысында милли-азатлык хәрәкәтенең үзәге булган Арча төбәге XVII гасыр башында хөкүмәткә тугры өлкәгә әверелә. Ихтимал, югарыда телгә алынган җәзалау чараларының да йогынтысы зур булган.

Степан Разин җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы (1670) башланыр алдыннан да, сәяси көчләр нисбәтендә шундый ук хәл саклана. Әлеге сугыш барышында Казан төбәгенең көньяк, көнбатыш һәм төньяк-көнбатыш өлешләрендә күтәрелешләр башлана. Тарихи чыганаклардагы мәгълүматлар шул хакта сөйлиләр. Мәсәлән, Зөянең йомышлы татары Янтулла Бикбулатов, «болганчык чор узганын» көтеп, бер ел чамасы (1670 елның җәеннән 1671 елның июленә кадәр) гаиләсе белән үзенең туганында, Казан өязе-

---

[1] ПСРЛ.—Т. 29.—М.: Наука, 1965.—С. 255.

[2] Борисов В. Город Лаишев в XVI—XVII вв. // ИОАИЭ.—1899.—Т. 15.—Вып. 3.—С. 344—349.

[3] Никольский Н. В. Сборник исторических материалов о народностях Поволжья.—Казань, 1919.—С. 443; История Татарии в документах и материалах.—М., 1937.—С. 369.

нең Уратлы авылында качып ята[1]. 1670 елның 15 декабрендә язылган патша грамотасы игътибарга лаек. Анда Казанда һәм өяздә яшәгән «йомышлы һәм башка рус кешеләренә, морзаларга, татарларга, чуашларга, чирмешләргә һәм вотякларга» баш күтәрүләргә кушылмаска өндәмә урнаштырылган[2].

Е. Пугачев җитәкчелегендәге өченче Крестьяннар сугышы чорында исә бөтенләй башка хәл күзәтелә. Әлеге хәрәкәтнең җитәкчеләреннән берсе Мәсәгуд (Мәсгуд) Гомәров — Казан өязе Арча даругасы Пычак авылының (Татарстанның хәзерге Кукмара районына керә) Туктамыш йөзлеге (сотня) кешесе[3]. Ул талантлы оештыручы, крестьяннарның гайрәтле юлбашчысы буларак дан казана. М. Гомәровның актив эшчәнлеге нәтиҗәсендә Арча төбәге һәм Казан өязенең төньяк-көнчыгыш өлеше тулысынча диярлек 1773 ел ахырында крестьяннар сугышына кушыла. Авылларда үз җыеннарында да Пугачев фәрманын таләп итеп, аның янына вәкилләр җибәрү хакында карарлар кабул итәләр. Аерым алганда, Казан өязе Арча даругасы авылларының берсеннән булган Рәхим Әсвиев авылдашлары тарафыннан, «Император галиҗәнапларына хезмәт итү өчен фәрман алырга» дип, Пугачев тарафына җибәрелгән. Шундый ук илчеләр Гомәров янында да булганнар. Пугачев полковнигы булганнан соң, Гомәров старшиналар билгеләгән, аларны, теләүчеләрне отрядларга туплау һәм Петр III гә ант иттерү өчен, авылларга җибәргән. Аерым алганда, Казанның өченче батальоны солдаты (ул хөкүмәт гаскәрләреннән качкан була) Габдерәшит Бикәев аның тарафыннан указлар уку һәм халыкны җыю, кешеләр туплау өчен вотяк авылларына җибәрелгән. Шундый ук вазифаларны Казан өязенең Салавыч авылы кешесе йөзбашы (сотник) Гәбдуш Уразаев та башкарган. Нәтиҗәдә, 1774 ел башында М. Гомәров отрядлары Казаннан Малмыжга һәм Мамадышка кадәрге җирләрдә хәрәкәт иткәннәр. Бу төбәкләрдә патша чиновниклары һәм алпавытлар кулга алынып, алар хөкемгә тартылган, аларның җирләрен крестьяннар үзара бүлешкәннәр.

---

[1] Акты исторические и юридические и другие царские грамоты Казанской и других соседственных губерний. Собран С. Мельниковым.— Казань, 1859.— Т. 1.— № 29.— С. 53—54.

[2] Ермолаев И. П. Среднее Поволжье во второй половине XVI—XVII вв.— Казань, 1982.— С. 159.

[3] Кара: Алишев С. Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании.— Казань, 1973.— С. 106.

Арча төбәгендә сыйнфый көрәш ялкыны дөрләсә дә, Арча үзе хөкүмәткә тугры булып кала биргән. Гомәров Казанга яу белән барырга һәм Арчаны алырга әзерләнгән, әмма, Минзәлә һәм Уфа янына өстәмә гаскәрләр кирәклеге хакында фәрман алганнан соң, ул үзенең ниятен гамәлгә ашыруны кичектерергә булган.

М. Гомәровның күпсанлы отрядыннан тыш, 1773—1774 елларда Арча төбәгендә шулай ук Мәсгуд Нәзиров, Гәбдерәшит Бикәев (Арча—Балтач юнәлешендә), Гәбдүш Уразаев (Арча—Питрәч), Субай Солтанов һәм Киләй Смайлов (Балтач—Арча—Казан), Гәбделфаикъ Усманов һәм Гомәр Ибраев (Арча—Казан), Семен Иванов (Кукмара—Малмыж), Әхмәр, Нигъмәтулла Бакиров отрядлары хәрәкәт иткән.

1774 ел башында Казан төбәгендә баш күтәргән крестьяннарны җәзалау экспедицияләре оештырыла. Аерым алганда, генерал-аншеф А. И. Бибиков тарафыннан Казаннан 4 гыйнварда Кама алды төбәгенә гаскәр белән капитан Кардашевский җибәрелә. Ул, Арча һәм Җөри юллары буйлап хәрәкәт итеп, Арча—Мамадыш—Алабуга—Зәй юнәлешендә сугыш хәрәкәтләре җәелдерергә һәм андагы җирләрне баш күтәрүчеләрдән чистартырга тиеш була. Бу вакытта Мамадыш һәм Арча төбәкләренең баш күтәргән крестьяннарыннан торган көчләр старшиналар җитәкчелегендә Алабуга тирәсендә туплана. Шәһәрнең язмышы санаулы көннәр эчендә хәл ителергә тиеш була.

Әмма капитан Карташевский отряды баш күтәрүчеләрнең ниятләре тормышка ашыру юлында комачаулык тудыра. Җәзалаучылар авылларны бөлдерәләр. Крестьяннар көрәшне туктатмыйлар, әмма эре отрядлар булмый инде.

1774 елның җәй башларында Пугачевның төп көчләре Әгерҗе һәм Алабуга янына килә. Казан өязе халыклары аңа теләктәшлек белдерә, аның янына илчеләр, вәкилләр җибәрә, ярдәм вәгъдә итә. Илчеләр киңәше буенча Пугачев Казанга Арча ягыннан һөҗүм итәргә карар кыла һәм 6 июльдә Мамадыштан чыга. 9 июльдә кичен Арчага өч ярдәмчесе белән Пугачев атаманы килеп төшә. Ул «государьне» каршы алырга әзерләнергә куша. Берәр сәгатьтән соң Пугачев шәһәргә якынлаша. Халык урамнарга чыга. Барысы да тезләнәләр, чаң кагалар. Әмма Пугачев тукталып тормый, Арчадан өч чакрымлык арада урнашкан алпавыт авылына төн кунарга китә.

Пугачев гаскәре белән Арчадан 10 июльдә кузгала. Арча төбәгенең күп кенә халкы аңа кушыла. Казаннан җибәрелгән хөкүмәт гаскәрләре (аларны полковник Толстой җитәк-

ли) белән баш күтәрүчеләр Ямаширмә (Татарстанның хәзерге Биектау районына керә) авылы янында очрашалар. Солдатлар халык ягына чыга, офицерлар юк ителә.

Казан өчен сугышлар барган чорда төбәк тулысынча сыйнфый көрәш ялкыны эчендә кала. Крестьяннарның күбесе Пугачев властен таный. Халык алпавытларны кыра, аларның мал-мөлкәтен бүлешә, монастырьларны һәм чиркәүләрне бөлдерә.

Казан янында 15 июльдә (1774 ел) җиңелгәннән соң Пугачев Иделнең уң ягына чигенә. Әмма җирле халыкның көрәше тукталмый, ул 1775 елга кадәр дәвам итә.

Төбәкнең административ төзелеше

XVI гасырның икенче яртысында беркадәр эзлеклелек белән өч дистә елдан артык дәвер дәвам иткән азатлык хәрәкәте җирле администрация органнарын булдыру процессында кыенлыклар тудырган. 1552 елда Казанны яулап алганнан соң элеккеге дәүләт җирләре шул чорларның замандашлары тарафыннан берничә өлешкә бүленеп аталган. Шул өлешләрнең берсе — Арча ягы. Ул Казаннан төньяк-көнчыгыш юнәлештә Казансу елгасы буйлап Нократның (Вятканың) урта агымына кадәрге җирләрне биләгән. Шул ук вакытта, ягъни «ирекле» («стихияле») рәвештә бүленү белән беррәттән төбәк рәсми рәвештә ике өлешкә — Казан һәм Зөя өязләренә бүленгән.

Урта Идел буйларындагы өязләренең эчке бүленешендә вакыт нисбәтендә төрлелек күзәтелә. XVI гасыр ахырында — XVII гасыр башында административ-территориаль бүленеш ахыргача башкарылмаган, ягъни төгәлләнмәгән. Элеккеге дәверләрдә кулланылган даругаларның административ төшенчәсе файдаланылган. Аерым алганда, «Казан өязенең 1602—1603 еллардагы исәп алу кенәгәсе» («Писцовая книга Казанского уезда 1602—1603 годов») Казан өязендәге Арча, Җөри, Нугай, Алат һәм Галич даругаларын билгеләп үтә.

XVI гасырның икенче яртысыннан Арча Казанның шәһәр алды бистәсе (пригород) буларак искә алына башлый[1]. Чыганаклардагы мәгълүматлар Казан төбәгендә бу чорда воеводалык системасының оешуы хакында фараз кылырга мөмкинлек бирә. Арчага воеводалар билгеләү турындагы

---

[1] Ермолаев И. П. Среднее Поволжье во второй половине XVI—XVII вв.— Казань, 1982.— С. 57.

хәбәрләр башлап 1576 елдан очрый. Арчаның беренче воеводасы — Василий Телицын[1].

XVII гасырда җирле администрация органнарында әлләни үзгәрешләр күзәтелмәсә дә, кайбер эчке төгәллекләр һәм төгәенлекләр сизелә.

XVIII гасыр башында, губерналар оештырылганда, Арча Казан карамагына языла[2]. XVIII гасырның уртасында Арча төбәге искечә — Арча даругасы буларак тасвирлана. 1771—1773 елларда анда Себер тракты буйлап урнашкан 54 торак пункт исәпләнгән[3].

1781 елда, Казан наместниклыгы оешуы турындагы указлар белән, Арча шәһәр итеп үзгәртелә һәм өяз үзәге итеп билгеләнә[4]. Әлеге вакыйгалардан соң 20 көнләп вакыт узгач Казан наместниклыгының герблары раслана. Герблар мөмкин кадәр җирле үзенчәлекләрдән чыгып эшләнә. Арча шәһәренең гербы да әлеге кагыйдәдән чыгарма булмый: «Хәзерге вакытта шәһәрдә сакланган, имән бүрәнәләрдән салынган, өч манаралы, көмеш кырдагы кирмән»[5].

1796 елда Арча штаттагы шәһәр (заштатный город) буларак үзгәртелә[6]. 1802 елда Сенат, Спасс, Тәтеш һәм Арча шәһәрләрен өяз калаларына әверелдерү мәсьәләсен куя, ә Цивильскны өяз каласы дәрәҗәсеннән гади шәһәр статусына күчерү күздә тотыла. Әмма император Александр I әлеге тәкъдимгә каршы килә, нәтиҗәдә Арча штаттагы шәһәр булып кала[7].

Арчаның планы 1837 елның 23 июнендә раслана. Шәһәрдә хуҗалык, җәмәгать һәм хөкем эшләрен башкару өчен Ратуша, Ятимнәр суды һәм башкалар булдырыла. XIX гасыр уртасында Арчада Е. И. Гайдуковның — бургомистр, И. С. Горшенев һәм Е. Я. Горшеневның — ратманнар, титуляр киңәшче М. В. Просвирникның секретарь бу-

---

[1] Городские поселения в Российской империи.— СПб., 1861.— Т. 2.— С. 333.

[2] Полное Собрание Законов Российской Империи с 1649 года.— СПб., 1830.— Т. 4.— С. 436—437.— № 2218.

[3] Кара: Корсаков Д. А. Сборник материалов по истории Казанского края в XVIII веке // ИОАИЭ.— Казань, 1908.— Т. 18.— Вып. 4—6.— Отд. 1.— С. 38; Список селений Казанской провинции за 1771—1773 гг. // ИОАИЭ.— Казань, 1908.— Т. 18.— Вып. 4—6.— С. 40—56.

[4] Полное Собрание Законов Российской Империи, т. 21.— С. 276.— № 15241; С. 277, № 15243.

[5] Полное Собрание Законов Российской Империи, т. 21.— С. 290.

[6] Шунда ук, т. 24.— С. 269.— № 17702.

[7] Городские поселения в Российской империи.— СПб., 1861.— Т. 2.— С. 332.

лып эшләүләре мәгълүм[1].

1860 елда Арчадан аерылып чыккан крестьяннар Арча (Арская слобода), Покроу (Покровская слобода, Яңа Арча) бистәсен нигезлиләр[2]. Бистәдә таш чиркәү саклана.

Социаль-икътисади хәл. Казан ханлыгының яулануы һәм озак елларга сузылган азатлык сугышлары авыр нәтиҗәләргә китерә. Икътисад бөлдерелә, халыкның бер өлеше, җөмләдән элеккеге ханлыкның хакимлек кылган югары катлавы юк ителә. Аерым алганда, «Казан өязенең 1602—1603 еллардагы исәп алу кенәгәсе»ндә бәян ителгәнчә, кенәз (морза) Бакшанды Нурушевның биләмәсе (Арча даругасындагы Үрсәк авылы) Федор Козлининның Микитасы (ихтимал, бояр улы) милкенә күчерелгән[3].

Мәскәү хөкүмәте сәясәте белән төбәк халкы ике төп төркемгә — йомышлы һәм ясаклы кешеләргә бүленгән. Йомышлы халыкның хокуклары кайбер мәсьәләләр буенча рус йомышлы катлавының хокукларына якын торган.

Рус хөкүмәтенә карата күндәм мөнәсәбәттә булган татар феодаллары үзләренең җирләрендә калдырылган. Аларны морзалар һәм йомышлы татарлар дип атаганнар.

Арча төбәгендә йомышлы татарлар күп булган. Аларның берсе — Казанны штурмлау алдыннан (1552 елның 22 августында) Иван IV ягына чыккан Камай морза Хусанов. Тугры хезмәте өчен аңа җир биләмәләре бирелә. Ул — 1602—1603 еллардагы исәп кенәгәсендә иң эре җир биләмәләре (600,5 дис.) хуҗасы буларак телгә алынган Камай Смиленевның бабасы.

Элеккеге Казан ханлыгының югары катлау аксөякләреннән тыш, патша хөкүмәте татарларның югары катлавын да хезмәткә тартырга омтылган, аларга җирләр бүлеп биргән. Мәсәлән, югарыда искә алынган чыганакта XVI гасырның 60 нчы елларында алты йомышлы татарга Борнаш авылында җир бирелүе хакында бәян ителә. Йомышлы һәм чукындырылган татарларга җир биләмәләре бирү алга таба да дәвам итә[4].

Ясаклы халык төп хезмәтче көч була. Ул икеләтә изүгә (җирле феодаллар һәм рус дворяннары ягыннан) дучар ителә. Ясаклы кешеләргә дә, йомышлы халыкның түбән кат-

---

[1] Список должностных лиц Казанской губернии на 1859 год.— Казань, 1859.— С. 53—54.

[2] Арская волость.— Казань, 1885.— С. 2.

[3] Писцовая книга Казанского уезда 1602—1603 гг.— Казань, 1978.— С. 116.

[4] Ермолаев И. П. Казанский край во второй половине XVI—XVII вв.— Казань, 1980.— №№ 223, 234, 235, 290, 291.

лавына бүленгән дәрәҗәдә, җир бирелгән.

Казанны яулап алгач та Мәскәү хөкүмәте колонизаторлык сәясәте үткәрә башлый. Урта Идел буйларын колонизацияләү — хәрби-феодаль колонизациянең типик формасы. Халык төрле изүләргә, кыерсытуларга дучар ителгән. Урта Идел буйларындагы җирләр төрле феодалларга һәм шулай ук чиркәүләргә, руханиларга бирелгән[1]. 1710 елда халык исәбен алу нәтиҗәләре, мәгълүматлары буенча Арча даругасындагы 264 хуҗалыкның Казан архиерее йортына беркетелүе мәгълүм.

XVI гасыр ахырында Арча үзе дә эре җир биләүче була. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Арча тирәсендәге авылларның җирләре кайбер очракларда Арча шәһәре өчен алынган. Аерым алганда, 1593—1594 елларда Чокырча авылы кешеләренең, ә 1595 елда Көбәк авылының җирләре Арча карамагына күчүе хакында хәбәрләр бар[2].

Арча төбәгенең XVI гасырның икенче яртысында — XVII гасыр башындагы социаль-икътисади һәм мәдәни үсеш темплары тулаем XVII гасыр өчен дә хас. XVII гасырның икенче яртысында шәхси җир биләмәләрнең саны һәм күләме арта. Арча, Нугай, Җөри һәм Алат даругаларында патша сарае һәм шәхси милеккә караган җирләрнең күләме шактый зур булган[3]. Аерым алганда, С. Волынскийның исәп кенәгәсендә (1649—1659 еллар) Арча юлындагы күп кенә авылларның (30,3%) патша сарае милкендә булуы хакында әйтелә. Арча юлындагы җирләрнең 12,5 процентын феодалларның шәхси биләмәләре тәшкил иткән.

XVIII гасырда, феодаль тәртипләр хөкем сөргән шартларда, капиталистик мөнәсәбәтләр туа башлый, товар-сәүдә һәм базар элементләре үсә.

Игенчелек, элеккеге дәверләрдәге кебек үк, төп шөгыль булып кала. Икенче урынны терлекчелек били. Төбәктә арыш, солы, бодай, арпа, карабодай, борчак игелә. Киндер һәм җитен күпкә азрак күләмдә үстерелә. Хезмәт коралларының җитәрлек дәрәҗәдә камил булмавы сәбәпле вак крестьян хуҗалыклары әлләни зур уңышларга ирешә ал-

---

[1] Ермолаев И. П. Понятие термина «колонизация» и его применимость к региону Среднего Поволжья // Вопросы социально-экономической и политической истории Среднего Поволжья и Прикамья периода феодализма.— Чебоксары, 1973.— С. 34.

[2] Ермолаев И. П. Казанский край во второй половине XVI—XVII вв.— Казань, 1980.— С. 41, № 235; шунда ук, с. 42, № 243.

[3] Мустафина Д. А. Социальное положение крестьян Казанского уезда во второй половине XVII века // Исследования по истории крестьянства Татарии дооктябрьского периода.— Казань, 1984.— С. 35.

мый. XVIII гасырда җир биләүнең ике төре — йомышлыларга бирелгән җирләр һәм ясаклы халыкның община җире табигый күренеш булган. Йомышлы рәвештә җир бирү XVIII гасыр башында зур үзгәрешләр кичерә. 1713 һәм 1715 елларда Петр I нең йомышлы татарларны көчләп чукындыру хакындагы указлары чыга. Әлеге фәрманнарга каршы килүчеләрнең крепостной крестьяннары тартып алынган һәм патша милкенә язылган. Кайбер морзалар, үзләренең биләмәләрен саклап калу өчен, җирләрен арендага яки алынган уңышның күпмедер өлешенә бирергә мәҗбүр булганнар. Күбесе үз биләмәләренең зур өлешен сата.

Шул ук вакытта йомышлы татарларның община җирләрен тартып алулары ешая. Нәтиҗәдә XVIII гасырның икенче яртысында татар авылларында социаль катлауларга бүленү тизләнә, крестьяннарның җитештерү чараларыннан, хезмәт коралларыннан читләшү күренеше көчәя бара. Алар үзләренең «байлары»на, алпавытларга, сәүдәгәрләргә, фабрика һәм завод хуҗаларына кабалага эләгәләр.

Икенче яктан, бу процесс барышында авыл хуҗалыгыннан шәһәрләргә күчкән, базарларга йөз тоткан һөнәрчеләр тернәкләнә баралар, байлык туплыйлар. Мәсәлән, Кибәхуҗа авылы кешесе Әмин Айбәковның татар хатын-кызлары өчен көмештән бизәнү әйберләре ясавы һәм шактый гына күләмдә мөлкәт туплавы мәгълүм. Остаханәләр күбәя, XVIII гасыр уртасында мануфактуралар барлыкка килә. Кайбер һөнәрчеләр һәм сәүдәгәрләр «завод хуҗалары»на һәм «фабрикант»ларга әвереләләр.

Арча төбәгендә дә күп кенә мануфактуралар була, аларның хуҗалары арасында (аракы заводларыннан башка) татар фамилияләре еш очрый. Бәрәскәдә, мәсәлән, Корбан Борнашевның, ә Орнашбашта Хәмза һәм Рәхим Мәмәшевләрнең комач фабрикалары була. Аларга 1775—1778 елларда нигез салына. XVIII гасырның 80 нче еллары уртасында Арча өязендә тукымалар җитештерү буенча ике мануфактура оеша. Аларга чимал (җепләр һ. б.) Оренбург аша Бохарадан кайтарыла. Игеннәрне урып-җыю чорларында гадәттә алар эшләрен туктатып торганнар.

XVIII гасыр ахырында (15 ел дәвамында) Арча өяз шәһәре була. Арча өязендәге халыкның 74,92 процентын татарлар тәшкил иткән. Анда барлыгы 232 авыл булып, 23464 «ревизия җаны» (балаларны кертмичә) яшәгән. Арчаның үзендә ул чорда 290 кеше, шул исәптән 75 мещан һәм 215 игенче-солдат яшәве мәгълүм.

XIX гасырның беренче яртысында Россиядә феодализмнан капитализмга күчеш дәвам итә. Икътисади үсеш юлын-

да киртә булган феодаль тәртипләр таркала бара. Авыл хуҗалыгына, бигрәк тә промышленностька капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керә, сәүдә үсә. Нәтиҗәдә алпавыт мануфактуралары таркала, яллы хезмәтнең кулланылу даирәсе кискен киңәя. Арча төбәгендә (Әтнәдә, Мәндәлдә, Бәрәздә һәм башка авылларда) шулай ук һөнәрчелек чәчәк ата, аның яңа төрләре барлыкка килә. Һөнәрчеләр җитештергән товарлар күпләп базарга чыгарыла. Казан арты, барлык Россия кебек үк, крепостнойлыкны бетерү аша капитализм дәверенә аяк баса.

АРЧА ТӨБӘГЕНЕҢ ЭПИГРАФИК ИСТӘЛЕКЛӘРЕ

(каберташлар)

Арча төбәге борынгы эпиграфик истәлекләргә байлыгы белән дә атаклы. Ул ерак гасырларда ук Урта Идел зонасында мөһим икътисади һәм мәдәни үзәк буларак танылган.

Әлеге региондагы борынгы кабер ташлары бу якларның мәдәниятен (шул исәптән динен, телен), икътисадын, тарихын һәм социаль катлауларга бүленү мәсьәләләрен өйрәнү өчен әһәмиятле язма җирле чыганаклар буларак хезмәт итәләр.

Төбәкнең эпиграфик истәлекләре чагыштырмача яхшы өйрәнелгән. Бу хакта Шиһабетдин Мәрҗани, Гали Рәхим, Һарун Йосыпов кебек галимнәрнең бәя биреп бетергесез хезмәтләре бар. Ләкин, шул ук вакытта, ул хезмәтләрдә XIV—XVII гасырларга караган каберташ язмалары тикшерелсә дә, Казан ханлыгы дәвереннән калган борынгы зиратлар искә алынмый. Ә инде XVIII—XX гасырларга караган эпиграфик истәлекләр бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән.

Арча төбәгендә сакланган каберташ язмалары тарихи-хронологик нисбәттә түбәндәге бүленешләргә карыйлар:

1. Алтын Урда дәверендәге болгар-татар каберташ язмалары (XIV гасыр).

2. Казан ханлыгы дәверендәге татар каберташ язмалары (XV—XVI гасырлар).

3. XVII гасыр татар каберташ язмалары.

4. XVIII—XX гасырлардагы татар каберташ язмалары.

Әлеге бүленешне без 1970—1994 еллар дәвамындагы археографик экспедицияләр барышында Арча төбәгенең татар зиратлары материалларын өйрәнү нигезендә төзедек. Эпиграфик язмалар халыкның тарихы һәм рухи мәдәнияте белән бәйле булганлыктан, һәр дәвергә кыскача гына тари-

хи белешмә кирәклеге дә сизелеп тора. Шунлыктан берничә җөмлә белән генә булса да тарихи мохитне күрсәтүне кирәк таптык.

Ташлардагы һәр текстның яртысыннан артыграк өлеше Коръән аятьләреннән тора, алар нигездә кабатланып киләләр. Язмабызның популяр рәвештә булырга тиешлеген күз алдында тотып, каберташ язмалардагы текстларның тарихи якларын гына күрсәтү кулай булыр дигән фикергә килдек.

АЛТЫН УРДА ДӘВЕРЕ

Болгар дәүләте 1236 елдан соң Алтын Урда дәүләтенең бер үзәк өлешенә әверелеп, «Болгар олысы» буларак атала башлый. Олыс башына җирле аксөякләр һәм татар ханнарының кардәшләре булган бикләр (бәкләр), солтаннар куела. XIII гасырда Болгар олысында Бураш бик, ә XIV гасырда Булат Тимер бик, Хәсән солтан, Мөхәммәт солтан, Габдулла хан кебек шәхесләрнең идарә иткәнлекләре мәгълүм.

Болгар дәүләте Алтын Урдага корал көче белән кертелгән булса да, әлеге вакыйганың нәтиҗәсе соңыннан шактый уңай якка үзгәрә. XIII гасырның 70—80 нче елларына Болгарның икътисады аякка баса. Урта Идел буйларында шәһәрләр күтәрелә, акча, ювелир хәзинәләре туплана, чын сәнгать үрнәкләре булган каберташлар куела башлый.

Бату хан гаскәре белән Болгар җирен яулап алса да, андагы болгарлар кырылып бетмәгән, монголлар да килеп утырмаган. Болгар җирендә куелган каберташлар чама белән 1360 нчы елларга кадәр болгар телендә язылганнар. Зәя елгасы буйларыннан Уфа шәһәренә һәм Вятка (Нократ) шәһәреннән Самара өлкәсенә кадәрге җирләрдә болгар телендәге ташлар куелган. Борынгы болгар теле үзенчәлекләренең югала бару процессы бөтен Алтын Урдада дәүләт теленең татар теле булуы белән бәйләнгән.

Шушы дәверләрдән Арча төбәгенә кергән Иске Ашыт авылы кырында да болгарлардан ике каберташ сакланган. Алар галим Һарун Йосыпов тарафыннан табылып укылганнар.

Иске Ашыт

1 нче таш

Борынгы текст: *«бакый ахирәт йатуы тарих җийати җүр әл сикир җал, зәлкагъдә айых ун сикир кун әти, җийати кун әти...»*

Тәрҗемәсе: «бакый ахирәттә ятуы тарих җиде йөз илле сигезенче ел, зөлкагъдә аеның унсигезенче көне иде, җиденче көне иде...»

Әлеге язулы каберташ һиҗри 757 ел, милади хисап белән 1357 елның 3 ноябрендә вафат булган болгар кешесе кабере өстенә куелган.

2 нче таш

Борынгы текст: *«Болгар Тотай улы Салих зийарти, Рәхмәтуллаһи галәйһи рәхмәтән васигатән. Фани дөнйаран бакый ахирәти йатуы... тарих җийати җүр... үч җал... ... билех кун әти».*

Тәрҗемәсе: «Болгар Тутай улы Салих зияраты. Аның өстендә Аллаһе тәгаләнең киң рәхмәте торсын. Фани дөньядан бакый ахирәткә ятуы тарих җиде йөз... өч җыл... ... бишенче көн иде».

Бу таш һиҗри 7...3 ел, милади 13...3 елда вафат булган кеше кабере өстенә куелган.

КАЗАН ХАНЛЫГЫ ДӘВЕРЕННӘН КАЛГАН БОРЫНГЫ ЗИРАТЛАР

1. Иске Ашыт

Бу типтагы борынгы зиратлар Арча төбәгендәге күп кенә авылларда мәгълүм. Аерым алганда, Иске Ашыт авылы кырында Казан ханлыгы дәвереннән калган зиратта өч каберташ сакланган. Ул ташларны 1927—1928 елларда атаклы татар галиме Гали Рәхим табып, язуларын күчереп алган. Ташъязмаларның сакланышы начар булып, берсенең генә куелган елы таныла. Анда татар телендә «Тарих тукыз йөз кырыкда...», «Тикән», «Күрермең дөньяны вәйран (бары)», «бакый ирмәс юк (карары)» дигән сүзләр генә сакланган. Бу таш милади ел исәбе белән 1533 елда үлгән кеше кабере өстенә куелган. Анда Казан ханлыгы дәверендәге каберташ язмаларында еш очрый торган «бу дөньяда бар да бетә, бернәрсә дә мәңгелек түгел» мәгънәсендәге шигырь юлы китерелә. Язмадагы «Бикәҗ» исеме — кабернең татар югары катлавыннан булган дәрәҗәле хатын-кызга нисбәтлелегенә дәлил.

Казан ханлыгы дәвереннән Иске Ашыт авылында сакланган башка ике ташның язулары танылмый.

2. Түбән Оры

Казан ханлыгы дәверенә караган каберташны Гали Рәхим тапкан. Ташъязма тулы түгел.

> Борынгы текст: *«Һәза мәгъбәрән мөнәвәрәи солтанел-гали, тарих тукыз йөз... Бу ләүхәне хәлале... бина кылды...»*
>
> Тәрҗемәсе: «Бу нурлы кабер бөек солтанныкы. Тарих тугыз йөз... Ташны хатыны... куйдырды...»

Хәзерге хисап (милади) белән санаганда каберташ 1530—1550 еллар арасында куелган.

3. Арча станциясе

Арча тимер юл станциясенең көньягында Казан ханлыгы дәвереннән калган каберташлар сакланган зират булган. Картларның әйтүенә караганда әлеге ташларның (6—7 данә) күбесе чүп-чар астында калган. Аларның берсе мәчет халкы тарафыннан станциянең татар зиратына күчерелгән. Әлеге таштагы язуларның сакланышы начар, шулай да «тарих тукыз йөз иллик...» дигән сүзләрне укып була. Димәк каберташ Арчада 1542—1550 еллар арасында вафат булган кеше каберенә куелган. Ул чорларда Арча каласы Арча юлының (даругасының) административ үзәге булган.

4. Иске Иябаш

Авыл кырындагы урман полосасы янында Казан ханлыгы дәвереннән калган зират бар. Анда җәмгысы биш каберташның ватыклары саклана. Аларның берсендә Һиҗри 935 ел датасы укыла. Бу хәзерге (милади) исәп белән 1528 елга туры килә. Борынгы риваятьләр, легендалар буенча Казан ханлыгы дәверендә ул җирләрдә җиде мәчетле Миһербан авылы булган.

5. Иске Масра

Авыл янындагы кыр читендә Казан ханлыгы дәверенә караган иске зират бар. 1976 елда анда язу-билгеләре булган биш каберташ саналды. Аларның күп өлешләре җимерек иде. Бер ташта «тарих тукыз йөз... алтыда» дигән сүзләр укыла. Димәк зират XVI гасырның беренче яртысында барлыкка килгән. Икенче бер ташның артында «Бу ләүхәне

хәлале... солтан бина кылды» һәм өченче ташта «углы» дигән сүз генә сакланган.

Басып торган зур гына бер кабертаппа Коръән сүзләреннән соң «тарих тукыз йөз кырык алтыда» дигән юл укыла. Хәзергечә (милади) хисап белән бу дата 1539—1540 елларга туры килә.

6. Наласа

Авыл урамының зиратка якын булган очында ике борынгы каберташ сакланган. Аларның язулары укылмый, бизәкләре буенча XVI гасырның беренче яртысында куелганлыклары аңлашыла.

7. Иске Кишет

Авыл болынында иске зират өстеннән алынган каберташлар ята. Язулары бозылган, бизәкләре буенча Казан ханлыгы дәверенә карыйлар.

8. Түбән Мәтәскә

1 нче таш

Борынгы текст: *«...тарих тукыз йөз кырык сигездә Кунак Хуҗабай углы Җийан Хуҗа у... барганда кяфер кулындин шәһид булды...»*

Каберташ хәзерге (милади) хисап белән 1541—1542 елда куелган.

2 нче таш

Борынгы текст: *«...тарих тукыз йөз кырык сигездә Кунак Хуҗабай углы Аман Хуҗа узганда-барганда кяфер кулындин шәһид булды...»*

Әлеге каберташлар 1541 елда русларның Казан ханы Сафа Гәрәйгә каршы фетнәдә катнашып, Казан җиренә сугыш белән килгәнлекләре фактын күрсәтә.

Фәнни әдәбиятта моннан тыш Кадрәк, Казиле, Кишмәт, Югары Аты, Урта Аты, Югары Курса авылларында да Казан ханлыгы дәвереннән калган зиратлар, каберташлар булуы хакында мәгълүматлар бар. Кызганычка каршы, әлегә алар өйрәнелмәгән.

XVII ГАСЫР КАБЕРТАШЛАРЫ

Казан ханлыгы яулангач Арча каласы һәм аның тирәягындагы авыллар да туздырыла. Мәдәният-сәнгатькә зур зыян салына. Татарларга металл һәм таш белән бәйле эшләр тыела, халык талана. Бу хәл XVII гасыр буенча да дәвам итә. Шунлыктан Арча ягында XVII гасырдан калган язулы ташлар әлегә ике җирдә генә билгеле.

1. Түбән Мәтәскә

Бу авылда Казан ханлыгы дәверендә куелган ике кабер-ташның текстлары алда китерелде. Түбән Мәтәскә — XVI гасырдан соң XVII гасыр башында ук татар кабер ташы куелган бик сирәк урыннарның берсе.

> Борынгы текст: *«...тарих мең ел узыб йегерме сигездә мобарәк рәҗәб аенда ирде. Мамай углы Камашга Аллаһу тәгаля рәхмәт кылсын. Амин, раббел-галәмин, хәлале Каракайга Аллаһу рәхмәт кылсын. Амин».*

Ташның куелу вакыты милади хисап белән 1619 елның июнь-июль айларына туры килә.

2. Кәче иле

Авылның Казан — Арча юлы кырындагы зират коймасы буенда ук XVII гасырдан калган, күп кенә юллары бозылган кабер ташы саклана.

> Борынгы текст: *«...тарих мең дә туксан алтыда ирди Корбан углы Сарбай түрәләргә, бар иле иле-халайыкга рәхимле ирди, үз вакытында бу билгене ирәнләрдин дога өмид (өчен куйды)».*

Милади ел исәбе белән 1685 елга туры килә.

Кече иле каберташы үзенең чагыштырмача зур мәгълүматлы тексты белән кызыклы.

XVIII ГАСЫР КАБЕРТАШЛАРЫ

Хәзерге Арча төбәгендә XVIII гасырдан калган каберташлар сакланмаган. Әлбәттә, алар булган. Ләкин татар халкының XVIII гасыр дәвамында коточкыч рәвештә талануы, өзлексез баш күтәрүләр борынгыдан килгән гадәтләрне кысуга китергән. Арча төбәгендә XVIII гасырда Түбән

Оры авылында китаплар күчереп язу остасы Габдеррәзак Алма абыз углы кабере өстенә таш урнаштырылган булган. Ул каберташ ватылып, аның өстенә яңа бер таш язып куелган.

> Аның тексты: *«Һәза мәркадел-шәриф галим гала фазыл дамелла Габдеррәзак Алма абыз углының тәрбәседер мөддәт гомрендә 90 Коръән йазуы илә мәшһүрдер...»*
>
> Тәрҗемәсе: «Бу нурлы кабер, бөек галим акыл чыганагы дамелла Габдеррәзак Алма абыз углының тәрбәседер. Ахирәт гомерендә 90 Коръән күчереп язуы белән мәшһүрдер».

Габдеррәзак Алма абыз углы — XVIII гасырның беренче яртысында яшәгән шәхес. Аның заманында татарның китабы кулъязма күчерүчеләр тарафыннан тудырылган, Габдеррәзак хәзрәт — шундый мөхтәрәм затларның берсе.

XIX ГАСЫР КАБЕРТАШЛАРЫ

XIX гасыр халкыбыз тарихында иң тыныч дәверләрнең берсе була, көчләп чукындыру басыла; мәгърифәт, сәүдә, һөнәрчелек, сәнгать үсү өчен мөмкинлекләр туа, татар халкы кулында мал туплана башлый. Арча төбәгенә кергән татар зиратларында матур бизәкләр, язулар белән нәкышләп эшләнгән каберташлар куела. Алар аеруча сәүдә (Түбән Оры, Яңа Кенәр, Иске Кенәр, Яңа Тазлар яки Байкал) үзәкләрендә, мануфактуралы һәм мәгърифәтле Кышкарда, атаклы мәдрәсәле Ташкичүдә мәгълүм. Башка авылларның зиратларында XIX гасырның икенче яртысында куелган каберташлар очраштыргалый.

1. Яңа Тазлар (Байкал)

Авыл зиратында борынгы татар традициясе буенча корылган, кирпечтән эшләнгән зур дөрбә калдыклары да сакланган.

1 нче таш

> Текст: *«Тарихы гарәбия бең дә ике йөз кырык икенче елда җөмадиәләүвәлдә, галим фикъһия Монасиб мелла Муса углы дарел-ахирәтә интикаль кылды. Алла рәхмәт кылсын. 1826 сәнә румийә».*

Искәрмәләр: Җөмадиәләүвәл — ай елының бишенче ае. Галим фикъһия — ислам законнары фәне буенча галим. Дарел-ахирәтә — үлгәннән соң яши торган мәңгелек дөньяга.

2 нче таш

Текст: *«Румийә сәнәи 1837 нче ел, рамазан шәрифнең әүвәл көнендә Мөхәммәдша бине Габденасыйр 18 йәшендә нәкыль итте. Нур Аллаһу тәгалә а кабер».*

Искәрмәләр: Румийә сәнәи — хәзерге, руми ел исәбе буенча. Нәкыйль итте — күчте (үлде). Нур Аллаһу тәгалә а кабер — Аллаһының нуры каберенә иңсен.

3 нче таш

Текст: *«...вә сахибе әл-мәркад Габдерахман бине Фәйзерахман бине Габделгаффар әл-Түнтәри казый...»*

Искәрмә: Вә сахибе әл мәркад — һәм кабер иясе.

4 нче таш

Текст: *«...тарих мең дә ике йөз илле бишенче ел, рамазан шәрифнең 22 көнендә Габденасыйр Гомәр углы 55 йәшендә дарел-фанадин дарел-бакая нәкыль итте».*

Искәрмәләр: Рамазан шәриф — ай елының тугызынчы ае. Дарел-фанадин дарел-бакая нәкыль итте — фани дөньядан мәңгелеккә күчте.

Каберташның куелу вакыты милади (руми) хисап белән 1838—1839 елларга туры килә.

5 нче таш

Текст: *«...тарих мең дә ике йөз илле бишенче ел, рабигыләүвәлнең... Габденасыйр хәләле Мәхүбҗамал Габдерәшит кызы 28 йәшендә...»*

Искәрмә: Рабигыләүвәл — ай елының өченче ае.

Каберташ милади (руми) хисап белән 1838 елда куелган.

2. Яңа Кенәр

1 нче таш

Текст: *«Әлхөкем Аллаһу, мөтәвәффи Мөхәммәт-*

җан мәрхүм Габдерәхим улы Исхаков, румийә 1822 елда 1 нче июньдә 82 яшендә дарел-фанадин рихләт...»

Искәрмә: Әлхөкем Аллаһу — Аллаһ хөкеменә. Мөтәвәффи — үлгән. Рихләт — күчте.

2 нче таш

Текст: *«Һәза мәркади Сәйфулла бине Фәйзулла әл-Болгари карьяи Яңа Кенәри 1822 нче сәнәдә җәүзәсендә 53 яшендә вафат.*

Искәрмә: Җәүзә — сирия гарәби кояш календаренең бишенче ае — май.

3 нче таш

Текст: *«...румия 1856 сәнәдә уктәбер 19 нда, Һиҗри 1272 сәнә Яңа Кенәрнең хәзрәти ишан мелла Габдерәшит бине Сәгыйт бине Йәрмәк 63 яшендә дарелбакая рихләт».*

4 нче таш

Текст: *«...Мәрхүмә Мәрхәбә Габденасыйр кызы Әбелхәйер җәмәгате румийә илә 1855 нче елда, 1 июльдә 60 яшендә дарел-фанадин интикаль әйләде».*

5 нче таш

Текст: *«Румийә илә 1861 нче Һиҗрийә илә 1284 нче (сәнә) Шәмсеҗиһан мелла Исхак бине мелла Габдерәхим Исхаков углының...»*

6 нчы таш

Текст: *«Һиҗри 1300 нчедә рабигыләүвәлнең 4 йәүмендә хаҗи Мөхәммәдкамал бине Исмәгыйль бине Исхак... руми 1883...»*

3. Кышкар

1 нче таш
(Наянгуш зираты)

Текст: *«Әл-мәрхүмә әл-мәгъфүр Сәгыйдә бинте Ис-*

мәгыйль вөзәүҗәи Габделфәйез әл-Кышкари 1818 сәнә җәдидә».

Тәрҗемәсе: «Мәрхүмә атаклы Сәйдә Исмәгыйль кызы Габделфәйез Кышкари хатыны яңа 1818 елда (вафат)».

2 нче таш
(Кышкар зираты)

Текст: *«Румия 1857 рамазан шәрифнең 2 йәүмендә, 70 йәшдә Габделгаффар бине Габделваһаб вафат әйләде».*

Искәрмә: Йәүмендә — көнендә.

4. Түбән Оры

1 нче таш

Текст: *«Ибраһим бине Давыт мәркадедер. 72 яшендә вафат улмышдыр. Румийә илә 1832 нче йыл шоннең 21 нче йәүмендә. Аллаһу... тәгаләи».*

2 нче таш

Текст: *«...Ор карыйәсендә мәрхүм Габделгафур Габделхаликъ улы вафат булды 75 йәшендә 1851 нче сәнәдә гыйнварда...»*

3 нче таш

Текст: *«Васыйәтем будыр әүләдләремә. Дәхи ихваннарыма, дамадларыма. Кәрәм әйләп догада идеңез йад. Тасдыйклә кылыңыз рухымы шад. Газиз җиреңнең кадрен беләсез. Бу мәнзил йарагын анда кыласыз. Безгә Коръән укырга монда, тел юк. Тасдыйк мәһам вирергә кулда пыл юк. Уйан-буйан бакыб дога котәрмез, хәйер ихсан дәхи өмид итәрмез. Хәбибҗамал Муса кызы һәм Муса зәүҗәсе илле оч йәшендә 1858 сәнә.*

Искәрмәләр: Әүләдләремә — нәселемә. Ихваннарыма — кардәшләремә. Дамадларыма — кияүләремә. Кәрәм әйләп — киң күңелле булып. Идеңңез йад — искә алыгыз. Тасдыйклә — дөреслек белән. Мәнзил — бу урында «кабер» мәгънәсендәге сүз. Мәһам — сәдака. Пыл — бакыр акча. Ихсан — ярдәм.

4 нче таш

Текст: *«Румийә илә 1864 нче йылда 12 нче майда, гарәбийә илә 1287 нче йылда маhи золхиҗҗәнең 17 нче йәүмендә Бибизәбидә Хәмид кызы Мәхмүд Габдерахман улының зәүҗәсе 68 йәшендә шинбә кон мәдфүн улды бу кабернең мәркадидә. Вә Аллаhу тәгалә гарыйк рәхмәт әйләгән иде».*

5 нче таш

Текст: *«Бу кабер хәлләрен сагышлайасыз. Безгә Коръән укып багышлыйсыз. Тарих румийә илә 1898 сәнә фибрал 25 нче йәүмендә Йугары Шашының Бибизәһрә Сафиулла кызы, Нигъмәтҗан Корбангали углының хәлали 60 йәшендә шинбә кон дәфен иделде».*

Искәрмәләр: Йугары Шашы — Әтнә төбәгендәге авыл. Дәфен ителде — күмелде.

6 нчы таш

Текст: *«...әл-мәрхүм Сөләйман Ибраhим улының мәркадидер. Тарих Һиҗрийә 1274 нче елда зөлхиҗҗәнең 15 йәүмендә... Тарих румийә 1858 йылда 15 нче ийүлнең...»*

Искәрмә: Зөлхиҗҗә — мөселман ай елының уникенче ае.

5. Наласа

1 нче таш

Текст: *«Әл-хөкем Тәгаләи Наласа карийәсендә имамел-галим вә әл-гамил мелла Салих бине Әбелхәйер 1885 нче сәнә, июнь 5 ндә маhи рамазанның әүвәлге җомгасында 58 яшендә...»*

Искәрмәләр: Вә — һәм. Әл-гамил — хезмәтче. Маhи рамазанның — рамазан аеның.

6. Кәче иле

1 нче таш

Текст: *«Бихөкем Аллаhу тәгалә Бибигаишә Мәхмут кызы Гыйззәтулла зәүҗәсе 1898 нче йылда, нуйәбер-*

дә 55 йәшендә вафат... Кабрем заир улып әхваләмә идән нәгяһ. Рухыма кылсын дога вә хәлемдин улсын агяһ!»

Искәрмәләр: Заир улып — күрешергә килеп. Идән нәгяһ — вакытсыз иткән. Агяһ — хәбәрдар.

7. Күлтәс

Текст: *«Мөхәммәд рәсүл Аллаһ. Нурмөхәммәт бине Таһир Күлтәс карйәсендә күп сәнә имамәт итеп, 63 йәшендә миладийә 1884 беренче май вә Һиҗрийә 1301 16 нчы рәҗәбтә вафат уларак мәдфүн».*

Искәрмә: Бу кабердә татар галиме Шәмсетдин Күлтәсинең әтисе җирләнгән.

8. Мәмсә

Текст: *«...Галәмәтдин морадым бер догадыр. Бу көн бәңа икән йарин сиңадыр...»*

9. Яңа Ашыт

1 нче таш

Текст: *«...Гыйбадулла Сәгыйть улы миладийә илә дикәбердә 44 йәшендә дарел-бакая күчте».*

10. Яңа Кырлай

1 нче таш

Текст: *«...1895 нче йылда 3 нче априлдә Йаңа Ийабашы авылының Ибраһим җәмагате Гашшә Фәтхулла кызы 70 йәшендә вафат булды. Аллаһу тәгалә рәхмәт әйләсен».*

11. Курса

Текст: *«...Һиҗри илә 1305 нчедә рамазан шәрифнең 29 нда Йәдгәр иленең хаҗҗел-хәрамин Нигъмәтулла бине Габдулла Курсада игътикафдә 70 йәшендә шинбә көн дарел-бакайа васыйл улып рамазан шәрифнең 30 нда мәдфүн улды. Румийә илә 1888 нче сәнәдә майның 29 нда мәдфүн. Гомернең узганын сагышлайасыз. Безгә Коръән укып багышлайасыз! Бу көн бәңа икән, йарин сәңадыр».*

Искәрмәләр: Игътикафдә — тукталып торганда. Васыйл — ирешүче.

XX ГАСЫР БАШЫНДА КУЕЛГАН КАБЕРТАШЛАР

1. Ташкичү

1 нче таш

Текст: *«Рәхмәте Аллаһ әл-галим, әл-фазыйл мелла Галәэтдин бине мелла Баһаветдин әл-Мәрҗани руми 1908 нче, 17 април 68 йәшендә-дарел-бакая рихләт әйләде».*

Искәрмә: Әлеге каберташ татар язучысы Мәхмүт Галәүнең әтисе, Шиһабетдин Мәрҗанинең энесе кабере өстенә куелган.

2 нче таш

Текст: *«...1902 нче йылда, 14 нче апрельдә Казан өязе Ташкичү авылының Әхмәтҗан Халит углы бу фана дийарендә 75 йыл гомер кичереп гакыйбәт...»*

Искәрмәләр: Фәни дийарендә — фани дөньяда. Гакыйбәт — ахырында.

3 нче таш

Текст: *«Галәмәтдин морадым бер догадыр. Бу көн миндә икән йарин сиңадыр. Шаһиәхмәт Шаһимкрдән углының мәркадедер».*

Искәрмә: 1921 елда куелган каберташ кисәге.

2. Түбән Оры

1 нче таш

Текст: *«Углы бина кылдырды. Буны йазмакдан морадым догадыр. Бу көн бәңа, йарин сингадыр. Тарих румийә илән 1911 йылда 23 найәбердә, 67 йәшендә Хөсәйен Хәсән углы дарел-фанадин дарел-бакайа рихләт әйләде».*

2 нче таш

Текст: *«Һәза сахибел-кабер Казан мещаны Әхмәт-*

җан Мәхмут углы Рафикоф 1909 нчы елда 23 нче декабрь 77 йәшендә мәдфүн».

Искәрмәләр: һәза сахибел-кабер — бу кабер иясе. Мәдфүн — күмелде.

3. Симетбаш

1 нче таш

Текст: *«Әлхөкем Аллаһ Руми 1913 сәнә фибрал 17 дә, һиҗри 1332 сәнә, рабигыл әүвәл 23 дә Симетбашының Мөхаррәм Мозаффар углы 67 йәшендә...»*

Әлбәттә, Арча төбәгендәге язулы кабер ташлары югарыда бәян ителгәннәр белән генә чикләнми, алар йөзләр, меңнәр белән исәпләнә. Бу хезмәт бер кешенең үз ихтыяры белән егерме елдан артык дәвердә туплап килгән мәгълүматларының кечкенә бер өлешен тәшкил итә һәм халкыбызның рухи-мәдәни мирасы белән таныштыру юлында бер адым буларак бәяләнә ала.

II. Авыллар тарихы

АРЧА ЯГЫ АВЫЛЛАРЫ XVI ГАСЫРДАН XVII ГАСЫР БАШЫНА КАДӘРГЕ ДӘВЕРДӘ[1]

Арча ягы авылларының күп гасырлык бай тарихы бар. Аларның байтак өлеше инде Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгы чорларында ук (XIII гасыр — XVI гасырның беренче яртысында) барлыкка килгән. Арчага, мәсәлән, Болгар дәүләтенең Казансу буендагы кальгасы буларак, XIII гасыр урталарыннан да калмыйча (ә бәлки XII гасыр ахырында ук) нигез салынган. Хәзерге Иске Ашыт, Иске Кишет, Түбән Оры, Урта Сәрдә, Татар Кадрәге, Кишмәт, Наласа, Урта Аты, Югары Аты, Түбән Мәтәскә, Казиле, Иске Масра авыллары янындагы борынгы татар зиратларында да XIV—XVI гасырларга караган гарәп-татар язулы кабер ташлары сакланган (Казаков Е. П., Старостин П. Н., Халиков А. Х. Археологические памятники Татарской АССР.— Казан, 1978.— 95—100 б.).

Арча ягы Казан ханлыгының үзәк җирләреннән берсе булып саналган. Шунлыктан биредә халыкның ул чорда ук күпләп яшәве гаҗәп түгел. Бигрәк тә Казансу, Ашыт елгасы, аларның кушылдыклары буйлап авыллар күп булган. Ул вакытта Арча ягының төп халкын татарлар тәшкил иткән. Татарлардан тыш монда, ихтимал, беркадәр күләмдә марилар, ә бәлки удмуртлар да яшәгән. Арча ягында беренче рус авыллары бары тик XVI гасырның икенче яртысыннан башлап, Урыс дәүләте Казан ханлыгын басып алганнан соң гына оеша башлый. Аңарчы бу якларда рус авыллары бөтенләй булмый. Шунлыктан XVI гасырдан XVII гасыр башына кадәрге дәвердә Арча ягы авылларының халкы нигездә татарлардан торган.

Казан ханлыгы чоры авылларын барлау, аларның урыннарын ачыклау җиңел түгел. Моның сәбәпләре күп. Ләкин иң җитди сәбәпләрнең берсе — XV—XVI гасырлардан тарихи чыганакларның (бигрәк тә язма чыганакларның) бик аз сакланып калуы. Шуңа да карамастан, тарихчы Е. И. Чер-

[1] Бу очракта «Арча ягы» төшенчәсе астында асылда Татарстанның хәзерге Арча районы җирләре күздә тотыла.

нышев, XVI—XVII гасырларга караган язу кенәгәләренә таянып, Казан ханлыгының 700 авылын ачыклый алган (Чернышев Е. И. Селения Казанского ханства: по писцовым книгам // Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья.— Казань, 1971.— С. 272—292.). Е. И. Чернышев хезмәтенә һәм шулай ук үзебездә тупланган тарихи чыганакларга нигезләнеп, Арча ягының Казан ханлыгы чорындагы кайбер авылларын атап үтик.

Казан ханлыгының җирләре аерым өлкәләргә — «даруга»ларга бүленгән. «Даруга»ларның һәркайсы (Алат, Арча, Галич, Җөри, Нугай даругалары) ханлыкның башкала Казаннан билгеле бер юнәлештәге җирләрен үз эченә алган. Хәзерге Арча районына караган җирләрнең төп өлеше ул вакытта Арча даругасына кергән. Шул ук вакытта районның Ашыт елгасының югары агымындагы көнбатыш, төньяк-көнбатыш җирләре Алат даругасына, ә инде Норма елгачыгының югары агымындагы иң көньяктагы җирләре Җөри даругасына караган.

Арча даругасы, Казансу һәм аның тирә-ягы буйлап, киңәя барып, Казаннан төньяк-көнчыгышка таба сузылган. Ул үзенең атамасын Арча каласыннан алган. Казансу буйлап югары менгәндә Арчага кадәр, елгадан сул якта Чүриле, Абаш (Ашабаш), Үрсәк, Божа, Кадрәк, Чулпан, Кәче авыллары утырган. Казансуның уң ягында исә Кишмәт, Абҗабар дигән татар авыллары урнашкан. Морлы (русча чыганакта шулай), Зур (Олы) Сәрдә, Кече Сәрдә, Әрнәш, Орнашбаш, «Шай-суп кенәзнеке булган» Югары Аты авылы, Урта Аты, Субаш (Субаш Аты), Зур (Олы) Мәтәскә, Кече Мәтәскә, Мимәр, Наласа, Моллы (русча чыганакта) авыллары шулай ук Арча даругасына караганнар. Арчага якын гына Иске Төбәк, Төбәк, Хайван (Иске Айван) авыллары урнашкан булган. Казансу агымы буйлап Арчадан өстәрәк, елганың ике як яры, кушылдыклары буйлап Казанбаш (Казансу башланган җирдә), Билләр, Ирек, Төрнәле дигән авыллар, Пошалым (Түбән Пошалым), «Пошалым елгачыгы башланган җирдә» Пошалым (Югары Пошалым?), Әзәк, Өтнә, Кырлай, Иябаш (Иске Иябаш), Ия, Боркаш, Түбән Мәтәскә, Югары (Кече) Мәтәскә, Көтек, Кармыш (хәзерге Казанбаш авылы), Түбән (Олы) Казиле, Урта Казиле, Югары Казиле, Көтәрнәс (хәзерге Күпербаш) авыллары утырган. Казансуның сул кушылдыгы булган Кесмәс елгасы буйлап чыганакларда Сеҗе, Кесмәс, Чүриле, Зур (Олы) Муй, Кече Муй, Масра, Мөрәле, Курса, Төбәк-Чокырча, Нәүрәз, Хозяшево (урысча чыганакта шулай) авыллары искә алына. Русча чыганакларда «Тебе Кози» һәм «Старые

Емуи» (Иске Муй?) дип бирелгән авыллар да, ихтимал, югарыда санап кителгән авыллардан ерак урнашмаган. Чыганакларда шулай ук Кукма елгасының югары агымында урнашкан Коратай авылы искә алына. Ямчурино, Өске Айдар (Айдар), Югары Ишәйбай авыллары да Арча даругасына караганнар.

Арча даругасыннан көнбатыштарак Алат даругасы булган. Ул ханлыкның Казаннан төньяк юнәлештәге җирләрен үз эченә алган. Ашыт елгасының югары агымы һәм аның кушылдыклары буйлап утырган Кушлавыч, Ашытбаш, Сәрде, Кенәр, Кишет, Кече Кырлай, Кышкар, Симет кебек авыллар шушы даругага караганнар. Моннан тыш Иске Ашыт, Түбән Оры авыллары янындагы борынгы татар зиратларында XIV—XVII гасырларга караган гарәп-татар язулы кабер ташлары — ул авылларның Казан ханлыгы чорында да булуларына дәлил.

Арча даругасыннан көньяктарак Җөри даругасы җирләре булган. Аңа ханлыкның Казаннан көнчыгышка таба сузылган җирләре кергән. Норма елгасының югары агымында урнашкан Венета, Яңасала, Штерә авыллары Җөри даругасына караганнар.

Арча ягының Казан ханлыгы чоры авыллары, һичшиксез, югарыда атап кителгәннәр белән генә чикләнми. Әйтик, ханлыкта Югары Аты, Урта Аты дигән авылларның булуы ул чорда Аты елгачыгы буйлап түбәндәрәк Түбән Аты авылының да булганлыгы турында сөйли. Чыннан да, хәзерге Арча районында шул исемдәге авыл бар. Ахыр чиктә Казан ханлыгы чорында Арча ягында авыллар саны хәзергедән әллә ни ким булмаган, дип нәтиҗә чыгарырга була. Явыз Иванның баскынчы гаскәре белән XVI гасыр урталарында бу җирләргә килеп чыккан кенәз А. Курбский Арча ягында авылларның күп булуы, бу җирләрнең һәртөрле нигъмәтләргә, кош-кортка байлыгы турында сокланып язып калдырган. Арча ягы халкы ханлык чорында иген игү һәм терлек асраудан тыш аучылык, кыргый умартачылык, балык тоту, һөнәрчелек белән шөгыльләнгән. Халыкның төп өлеше ясаклы кешеләрдән торган. Соңгылары дәүләт һәм аерым феодаллар файдасына ясак һәм башка салымнар түләгәннәр. Ясаклы кешеләрдән тыш XV—XVI гасырларга караган тарихи чыганаклар еш кына «Арча кенәзләре»н искә алалар. Ихтимал, бу эре аксөякләр Казанда утырган хан идарәсеннән берникадәр ирек белән файдаланганнар. Ханлык вакытында Арча ныгытылган кирмән булып, анда хәрби гарнизон торган.

Гадәттә феодаллар, ханга хезмәт итү шарты белән, аннан җир биләмәләре алганнар. Ул җир биләмәләреннән

файдалану өчен хокук хан тарафыннан бирелгән махсус ярлыклар белән билгеләнгән. Андый ярлыклар феодалга билгеләнгән җирдәге авыллардан үз файдасына ясак җыю мөмкинлеге биргән. Шул ук вакытта хан ярлыклары нигезендә феодалларга беркетелгән җирләр ханныкы булып саналганнар, ә ул җирләрдә яшәүче игенчеләр аксөякләрдән бәйсез булып исәпләнгәннәр. Ханның үзе өләшкән җир биләмәләрен феодаллардан кире тартып алу мөмкинлеге дә булган. Яу чабарга кирәк булганда хан боерыгы буенча дәүләт хезмәтендәге аксөякләр тулы сугышчан хәзерлектәге үз гаскәриләре белән берлектә хан чирүенә килеп кушылганнар.

1552 елның 2 октябрендә Казан ханлыгын «җәннәт җирләре» буларак сурәтләгән һәм аны тату булган очракта да басып алырга кирәк дип тәкрарлаган Рус дәүләте чиркәү-дворян фикер ияләренең татлы хыяллары өлешчә тормышка аша. Рус гаскәре тарафыннан ханлыкның башкаласы Казан яулап алына. Рус елъязмалары бу вакыйганы «татарлар шулкадәр күп кырылдылар ки, бөтен шәһәрдә үлекләргә басмыйча йөрер мөмкин түгел иде»,— дип тасвирлыйлар (кара: ПСРЛ.— Т. 13.— С. 219). Казанны яулаганчы ук, 1552 елның сентябрендә рус гаскәре Арча крепостен басып ала. Арчаның тирә-ягындагы татар авыллары талана, туздырыла. Ләкин Казан һәм башка шәһәрләр яулану белән Казан ханлыгы җирләрендә орыш хәрәкәтләре тукталмый. Ханлыкның җирле халкы (татарлар, марилар, удмуртлар, чуашлар) милли-азатлык сугышына күтәрелә. Бу сугыш 1557 елга кадәр дәвам итә һәм күп кан коелуга китерә. Ханлыкның үзәк җирләрендә — Казан артында сугыш хәрәкәтләре аеруча канкойгыч була. «Ул елларда,— диелә рус елъязмаларында,— Болын (Иделнең сул як ярындагы җирләр — *авт.*) һәм Арча яклары бөтенләй баш имәделәр, христианнарның канын койдылар һәм аларга бик күп бәлаләр китерделәр» (ПСРЛ.— Т. 13.— С. 523). Әлбәттә, бу көрәш барышында иң зур хәвеф-хәтәр, бәлаләр җирле халык өстенә төшә. Сугыш нәтиҗәләре турында искәртеп, XIX гасыр тарихчысы С. М. Соловьев: «Арча һәм Яр буе (бу очракта Идел яры күздә тотыла) яклары соң дәрәҗәдә бушап калган иделәр»,— ди (Соловьев С. М. Сочинения.— М., 1989.— Кн. 3.— Тт. 5—6.— С. 465). 1552—1557 еллардагы азатлык хәрәкәтен, җирле халыкның чыгышларын бастырганда, җәза көчләренең ерткычлыклары нәтиҗәсендә Арча ягы халкы өлешчә һәлак була, өлешчә көнчыгыш һәм төньяк-көнчыгыш юнәлешләрдә башка җирләргә күченеп китә. Рус елъязмасы ул елларда Казан ханлыгының «иң яхшы» кешеләренең — гаярь кенәзләренең, морзаларының «тәмам бетүе» ту-

рында хәбәр итә (ПСРЛ.— Т. 13.— С. 282). Шушы хәвефле вакыйгаларның нәтиҗәсе буларак, XVI гасырның икенче яртысында — XVII гасыр башында элекке ханлык җирләрендә күп санлы «бушлыклар» (урысча «пустошь») барлыкка килә. Нигездә алар Казан ханлыгы чорының ташландык авыллары булалар. Ул елларда Арча ягында да «бушлыклар» күп булган. Мәсәлән, 1565—1568 елларга караган бер чыганакта Югары Аты, Югары Казиле авыллары «бушлык» буларак исәпкә алынганнар (РГАДА.— Ф. 1209.— Кн. 643.— С. 214, 231). «Пошалым елгачыгының башланган җирендәге» Пошалым, Симет кебек «бушлыкларда» хәтта 1619 елда да әле кеше яшәмәгән (Кн. 153.— С. 1280—1291).

XVI гасырның икенче яртысында — XVII гасыр башында элекке Казан ханлыгының җирле халкы арасында зур күченүләргә, 1552—1557 еллардагы көрәш һәм җәза көчләренең гамәлләреннән тыш Рус дәүләтенең яулап алынган җирләрдәге милли, сыйнфый-икътисади сәясәте дә сәбәп булып торган.

Рус дәүләте Казан ханлыгын басып алганнан соң Арча ягы Казан өязенә кертелгән. Өяз ханлык чорыннан калган даругаларга бүленгән. Арча ягының төп халкы элеккечә дәүләт казнасына (бу юлы инде Рус дәүләтенә) ясак түләп торырга тиеш булган. Хөкүмәткә каршы булмаган элекке татар аксөякләрен Явыз Иван үзенә буйсындырган һәм дәүләт хезмәтенә алган. Андый кешеләр йомышлы татарлар дип йөртелгәннәр. Алга таба йомышлы татарларның исәбе ясаклы кешеләрнең бер өлеше хисабына тулыландырыла барган. Элекке татар аксөякләренең бик азы гына кенәз, морза кебек ханлык чорыннан килгән дәрәҗәле исемнәрен саклап кала алган. Алар шулай ук йомышлы, ягъни дәүләт хезмәтендәге кешеләр исәбендә булганнар. Рус дәүләтенә хезмәт итү шарты белән йомышлы татарларга шәхси файдалануга җирләр өләшенгән. Ул хезмәт исә нигездә Рус дәүләте алып барган күпсанлы яуларда сугышчы сыйфатында катнашудан, ягъни хәрби хезмәттән гыйбарәт булган. Гадәттә йомышлы татарлар һәртөрле сугышларда аерым гаскәри берәмлек булып катнашканнар. Чынлыкта аларның хокуклары һәм мөмкинлекләре чикләнгән булган. Йомышлы татарлар феодаль җәмгыятьнең сыйнфый баскычында рус дворяннарыннан түбәндәрәк торганнар. Хөкүмәт, бу кешеләрнең икътисади яктан көчәеп китүләреннән шикләнеп, аларга зур җирләр бирмәскә тырышкан. Еш кына йомышлы татарларның матди хәле ясаклы кешеләрнекеннән начаррак та булган.

Татарларга һәм элекке ханлыкның башка халыкларына шәһәрләрдә яшәү, тимерчелек һәм көмешчелек һөнәрләре белән шөгыльләнү тыелган. Ханлык җирләренә рус кешеләрен күчереп утырту сәясәте дәүләт күләмендә алып барылган, рус колонизациясенә җирле халыклар яшәгән урыннарда кальгалар төзү, алга таба аларны рус колонизациясенең терәк пунктларына әйләндерү хас булган. Кагыйдә буларак, андый кальгалар төп транспорт юлларында урнашкан татар шәһәрчекләре нигезендә барлыкка килгәннәр. Бу кирмәннәрнең һәркайсының хөкүмәткә каршы баш күтәрүләрне аяусыз рәвештә бастырырга әзер торган хәрби гарнизоны булган. Мисал өчен, 1555 елда Арча кирмәне яңадан торгызыла. Монда стрелецлардан һәм казаклардан торган хәрби гарнизон урнаштырыла. Һичшиксез, Арча — хәзерге Арча районы җирләрендә барлыкка килгән беренче рус торак пункты була. Ихтимал, Арчаның ханлык чорындагы татар халкы аны 1552 елда ук ташлап киткән һәм шуннан бирле Арча (1555 елга кадәр, ягъни руслар монда яңа кирмән торгызганчы) берара «бушлык» булып торган. Кагыйдә буларак, Арча кебек кальга-шәһәрчекләр тирәсендә беренче рус авыллары барлыкка килгән. Еш кына аларның да һөҗүмнән саклану ныгытмалары булган. Арча ягында беренче рус авыллары шулай ук ханлык чорындагы татар авыллары нигезендә барлыкка килгәннәр. Бу исә еракларда кучеиеп килүче русларга үзләре өчен яңа җирләрне чагыштырмача азрак көч һәм вакыт бәрабәренә үзләштерү мөмкинлеген биргән. Арча ягындагы хәзерге рус авылларының байтагы әле дә булса үзләренең борынгыдан килгән татар исемнәрен йөртәләр. Алар арасында Абҗабар, Кишмәт, Чулпан, Чүриле, Бимәр авылларын атап китәргә була. Элекке Казан ханлыгы җирләрен руслар тарафыннан колонизацияләү XVI гасырның икенче яртысында шулкадәр колач ала ки, 1565—1568 елларда бер Казанда гына да Рус дәүләтенең 41 төбәгеннән күченеп килүчеләр яшәгән. Аларның бер өлеше яулап алынган җирләргә ирекле рәвештә килеп чыкса, икенче өлеше (бигрәк тә дәүләт хезмәтендәге кешеләр) монда куып китерелгән.

Җирле халыктан иң яхшы җирләр тартып алынган һәм төрле рус колонистларына (дворян-алпавытларга, яңа барлыкка килүче монастырьларга, рус крестьяннарына һ. б.) өләшенгән. Мәсәлән, Казиле елгачыгы буена утырган Түбән (Олы) Казиле авылының бер өлеше 1565—1568 елларда инде рус дворяны Ефим Чемодуровның Михаил һәм Иван исемле ике улы милкендә була. Норма елгачыгы буендагы Венета авылының бер өлешенә шул ук елларда рус дворяны-

ның тол хатыны Агафья Скрябина хуҗа булып торган (РГАДА.— Ф. 1209.— Кн. 643.— С. 210, 214).

Рус дәүләтенең яулап алынган җирләрдә милли сәясәтенең төп эчтәлеге җирле халыкны христианлаштырырга һәм урыслаштырырга омтылудан гыйбарәт була. Шул максаттан чыгып 1555 елда Казан епархиясе төзелә. Бу епархиянең башында торучы архиепископка Мәскәү патшасы тарафыннан зур вәкаләтләр бирелә. Җирле халыкны христианлаштыру сәясәтендә төрле ысуллар кулланыла. Ул ысуллар арасында чукынган очракта җинаять җаваплылыгыннан азат итү дә, җир, акча бирү дә, кешеләрне көч кулланып чукынырга мәҗбүр итү дә, башкалары да була. Җыеп әйткәндә, христианлаштыру сәясәте ут һәм кылыч ярдәмендә уздырыла. Шушы сәясәтнең башында христиан дин әһелләре торганнар.

Христианлаштыру шаукымы Арча ягы халкын да читләтеп узмаган. 1565—1568 елларга караган чыганакта ук инде Чүриле (хәзерге Иске Чүриле) авылының татарлардан торган халкы керәшеннәр (урысча «Новокрещен») дип күрсәтелә (РГАДА.— Ф. 1209.— Кн. 643.— С. 435). 1602—1603 елларда бу «яңа чукынган» авылда 5 йомышлы кеше һәм 13 ясаклы кеше хуҗалыгы исәпләнә (Писцовая книга Казанского уезда: публикация текста.— Казан, 1978.— С. 121—130.) XVII гасыр башында Арча ягының Әзәк, Кишмәт, Яңасала, Курса авыллары халкы да «яңа чукынганнар» рәтендә йөргән. Әзәк авылында, мәсәлән, ул вакытта йомышлы керәшен Василий Андреевтан тыш биш йортта ясаклы керәшеннәр дә яшәгән (шунда ук.— С. 123—124). Шунысы кызык, хәзерге вакытта Иске Чүриле һәм Кишмәт урыс авыллары булып исәпләнәләр. Аларның беренчел татар халкының православие дине кабул иткәннән соң монда күпләп күченеп килүче урыслар белән аралашып, алар арасында акрынлап урыслашкан халык булуы ихтимал.

Югарыда санап кителгән сәяси, сыйнфый-икътисади күренешләр Казан артының җирле халкы, бигрәк тә татарлар арасындагы күчеш хәрәкәтенә көчле этәргеч биргән. Татарлар Казан тирәсеннән күпләп ераграк, урманлы-сулы җирләргә күчеп утыралар. Алар монда яңа авыллар коралар яки булган авылларның халкын бермә-бер арттыра төшәләр.

Тулаем алганда XVI гасырның икенче яртысында — XVII гасыр башында Казан артында гаять катлаулы күченү процессы бара. Бу процесс барышында кайбер авыллар юкка чыккан, алар урынына икенчеләре барлыкка килгән. Казан ханлыгы чоры авылларының ханлык беткәннән соң берара «бушлык» булып, соңыннан яңадан авылга әйләнү

очраклары күп булган. Казан өязенең 1602—1603 елларга караган язу кенәгәсе Арча даругасында элекке «бушлыклар» урынында күптән түгел генә барлыкка килгән 8 авылны теркәгән (Писцовая книга...—С. 10, 116—152).

XVII гасыр башында Арча ягындагы кайбер татар авылларында йортлар саны, ул авыллардагы кешеләрнең сыйнфый бүленеше түбәндәге таблицада чагыла:

Авыллар	Авылдагы йомышлы хуҗалыклар	Авылдагы ясаклы хуҗалыклар	Авылдагы барлык хуҗалыклар (йортлар саны)
Әзәк	1	5	6
Кече Муй	1	7	8
Кече Сәрдә	1	12	13
Кишмәт	8	—	8
Көтәрнәс	2	10	12
Мөрәле	1	3	4
Төбәк-Чокырча	1	16	17
Түбән Мәтәскә	3	8	11
Чүриле (Иске Чүриле)	5	13	18
Яңасала	1	14	15

Таблица Казан өязенең 1602—1603 елларга караган язу кенәгәсе буенча төзелде. Соңгысы бары тик йомышлы татарлар яшәгән авылларны гына исәпкә алган. Чынлыкта Арча ягындагы авылларның күпчелеге XVII гасыр башында бары тик ясаклы кешеләрдән генә торган. Андый авыллар исә югарыда искә алынган язу кенәгәсенә бөтенләй керми калганнар. Шулай да әлеге чыганак XVII йөз башы Арча ягы авылларын берникадәр күз алдына китерергә мөмкинлек бирә. Түбән Мәтәскә авылында, мәсәлән, Шабулат Шачюрин, Байзильда Мааметов, Кармыш Онтиков (исем-фамилияләр чыганактагыча) дигән йомышлы татарларның 348,5 чирек («чирек»—урысча «четверть»тан тәрҗемә, 0,54627 га җирне биләгән) чәчүлек җирләре һәм 800 чүмәләлек печән җирләре булган. Моннан тыш, Шабулат Шачюрин Ия буенда су тегермәне тоткан.

Яңасала авылының йомышлы керәшене Яков Степановның дәүләттән алган акчалата хезмәт хакы 4 сумнан артык булган, 30 чирек чәчүлек һәм 50 чүмәләлек печән җирләре аңа әтисеннән калган. Авылда 14 ясаклы йортка барысы 574 чирек чәчүлек һәм 700 чүмәләлек печән җирләре туры килгән. Норма елгасы буендагы су тегермәне Яков Степанов һәм ике ясаклы кеше милкендә булган. Йомгаклап шуны әйтергә мөмкин, XVII гасыр башына Арча ягындагы авылларның яңадана тернәкләнә, ишәя башлавы күзәтелә. Аларның күпчелеге бу вакытта үсеш чорын кичерә.

Арча ягы авыллары (Казан ханлыгы чоры)

№	Авыллар	№	Авыллар
1.	Абаш	40.	Морлы
2.	Абҗабар	41.	Мөрәле
3.	Алдар (Айдар)	42.	Наласа
4.	Ашытбаш	43.	Нәүрәз
5.	Бимәр	44.	Орнашбаш
6.	Божа	45.	Поник
7.	Боркаш	46	Сеҗе
8.	Венета	47.	Симет
9.	Зур (Олы) Муй	48.	Субаш
10.	Зур (Олы) Мәтәскә	49.	Сөрде
11.	Зур (Олы) Сәрдә	50.	Төбәк
12.	Ирек	51.	Төбә-Хуҗа
13.	Иске Ашыт	52.	Төбәк-Чокырча
14.	Иске Муй	53.	Тәрнәле
15.	Иске Төбәк	54.	Түбән-Аты
16.	Ия	55.	Түбән (Зур, Олы) Казиле
17.	Иябаш	56.	Түбән Мәтәсе
18.	Кадрәк	57.	Түбән Оры
19.	Казанбаш	58.	Түбән Пошалым
20.	Каратай	59.	Урта Аты
21.	Кармыш	60.	Урта Казиле
22.	Кенәр	61.	Хайван (Айван)
23.	Кесмәс	62.	Хозяш
24.	Кече Кырлай	63.	Чулпан
25.	Кече Муй	64.	Чүриле (Иске Чүриле)
26.	Кече Мәтәскә	65.	Чүриле (Яңа Чүриле)
27.	Кече Сәрдә	66.	Штерә
28.	Кишет	67	Югары Аты
29.	Кишмәт	68.	Югары Ишәйбай
30.	Курса	69.	Югары Казиле
31.	Кушлавыч	70.	Югары Мәтәскә
32.	Кырлай	71.	Югары Пошалым
33.	Кышкар	72.	Ямчурина
34.	Көче	73.	Яңасала
35.	Көтек	74.	Әзәк
36.	Көтәрнәс	75.	Әрнәш
37.	Масра	76.	Өске
38.	Мимәр	77.	Өтнә
39.	Моллы	78.	Үрсәк

ЯҢА КЕНӘР

Татарстанның Арча районына керә торган Яңа Кенәр авылы — Казан артының борыңгы, төзек һәм зур авылларының берсе. Ул бүгенге көндә дә үсә, күркәмләнә бара.

Яңа Кенәрнең, күп кенә татар авылларыныкы кебек, борынгыдан язылып киленгән тарихы барлыгы мәгълүм түгел. Шулай да урта мәктәпнең һәвәскәр тарихчылары көче белән тарих язып карау тәҗрибәсе булган. Әлбәттә, ул 1950 елларда, бик күп чыганакларны искә дә алырга ярамаган чорларда язылган һәм тарихны дөрес үк чагылдыра алмаган.

Шуннан соң Яңа Кенәр тарихын язу тәҗрибәсе яңадан да 1974 елда ясалды. Шушы елны әлеге язма Арчада чыга торган «Коммунизмга» газетасы (5, 9 сентябрь саннары) битләрендә «Туган ягыбыз тарихыннан» исеме белән басылып чыкты. Шул вакыттан соң безнең кулга яңа тарихи мәгълүматлар керде, бу исә авыл тарихын тулырак күзаллау мөмкинлеге тудырды. Кенәр авылларының тулыландырылган тарихы Яңа Кенәр авылы халкында гына түгел, туган як тарихын өйрәнүче башка кешеләрдә дә зур кызыксыну уятыр дип уйлыйбыз.

Безнең әлеге язмабызга нигез булырлык күп мәгълүматларны биргән могтәбәр картлар Вәли Хәкимов, Габдулла Садыйков, Кави Каюмов, Мостафа Әхмәтҗанов һәм башкалар инде күптән вафат. Алар белән очрашулар 1970—1974 елларда булган иде. Шул елларда, археографик экспедицияләр вакытында, Яңа Кенәр һәм аның күршесендәге авылларда, тарихи чыганаклар буларак, борынгы риваятьләрне, шәҗәрәләрне, биредәге җир-су атамаларын, борынгы зират ташларын өйрәндек. Өлкәннәрдән буыннан-буынга тапшырылып килгән хатирәләрне язып алдык. Шулай ук моннан күп еллар элек һәм бүгенге көннәрдә басылган тарих китапларыннан, борынгы кульъязма битләреннән дә хәбәрләр җыйнадык. Шул нигездә Яңа Кенәр һәм аның күршесендәге авыллар хакында бер кызыклы гына тарих язылды.

Яңа Кенәр авылының килеп чыгышы һәм исеме аннан 6 чакрымлап көнбатыштарак урнашкан Иске Кенәр авылы белән бәйле. Шунлыктан, авылның тарихын һәм исемен ачыклау өчен, Иске Кенәргә тукталмыйча булмый. Үз чиратында, Иске Кенәр авылының исеме дә Яңа Кенәр төзелгәч барлыкка килгән. Аңарчы ул Кенәр рәвешендә йөргән.

Кенәр авылы тарихчы Е. И. Чернышев күрсәтүенә карaганда, Казан ханлыгы дәверендә үк Ашыт елгасы буенда

булган борынгы авыллар рәтеннән санала[1]. Бу атама Татарстаннан тыш җирләрдә дә бар икән.

1767 елда язылган бер документ буенча хәзерге Чувашия территориясендәге Чабаксар өязендә Киняр дигән чуаш авылы барлыгы мәгълүм.

Мондый фактлар Ке́нәр атамасының Болгар яки Дәште Кыпчак чорыннан ук калганлыгын күрсәтәләр. Иске Кенәр авылы кырында гына болгар һәм кыпчак телләре белән бәйле Ашыт һәм Печмәнтау кебек атамалар булуы да Кенәр авылының (Иске Кенәр) борынгылыгына дәлил.

Бүгенге Болгариядә һәм Төркиядә кенәр исемле төрки кабиләләр яши. Әлеге кенәрләр—угыз төркиләре, аларның славян болгарлары белән кардәшлеге юк. Алар телләре ягыннан азәрбайҗаннарга, төрекмәннәргә, төрекләргә якын торалар.

Иске татар һәм угыз телләрендә бүген дә кенәр сүзе бар. Ул «чик, яр» мәгънәләренә ия. Югарыда күрсәтелгәннәрдән чыгып, бүгенге көндә кенәр сүзе белән бәйле булган татар һәм чуаш авылларының атамалары килеп чыгышында борынгы угыз төркиләре ыру-кабилә исеме ята, дигән нәтиҗәгә киләбез.

Иске Кенәр, Яңа Кенәр, Кечкенә Кенәр дип аталган авыл исемнәреннән үк күренгәнчә, башта Иске Кенәр авылы булганлыкка шөбһә юк. Иске Кенәр авылы бүгенге көндә Яңа Кенәргә караганда күпкә кечкенә, ләкин узган чорларда анда укымышлы кешеләр яшәгән, бай гына авыл булуы хакында дәлилләр бар.

Иске Кенәр картлары кулында кызыклы гына борынгы кулъязма китаплар сакланган. Алар арасында Дәште Кыпчак чорларында Идел буенда язылган «Ана белән угыл» дастаны күчермәсе аерым урын алып тора. Иске Кенәр зиратында XIX гасыр ахыры—XX гасыр башында бик нечкә зәвык белән язылган һәм яхшы сакланган кабер ташлары бар. Аларның кайберләре ташка кисеп эшләнгән чын сәнгать истәлекләренә тиң.

XVII гасыр ахырларында Иске Кенәр авылыннан бер төркем халык бүленеп чыгып, хәзерге Мәмсә һәм Яңа Кенәр авылларына нигез салган. Бу датаны сакланып калган нәсел шәҗәрәсенә һәм тарихи риваятькә нигезләнеп ачыкладык.

1893 елда хәзерге Арча районына кергән Мәмсә авылында туган Мостай бабай (Мостафа Әхмәтҗанов) иске кулъяз-

---

[1] Чернышев Е. И. Селения Казанского ханства // Археология и этнография Татарии.—Казань, 1971.—Вып. 1.—С. 279.

мада сакланган түбәндәге тарихи риваятьне сөйләгән иде:

«Борынгы заманда Күшәр якларыннан чыккан тугыз уллы Исәнгол баба (Исәнкол), буш җирләр эзләп, хәзерге Иске Кенәр авылында туктала. Ул чакларда тирә-яклар урман була. Исәнгол бабай уллары белән бер аланлык җирдә йортлар корып яши башлый. Тора-бара болар ишәеп, тагын да җиргә ихтыяҗ туа. Исәнгол баба тирә-як җирләрне өйрәнеп чыккан була инде. Ул бер көнне улларының берничәсен җыеп: «Безгә җир кирәк, менә шундый-шундый җирне карап-өйрәнеп кайтыгыз»,—дип, хәзерге Яңа Кенәр авылы урнашкан якка җибәрә. Егетләр бераз баргач, бер матур гына алан һәм зур гына күл күреп, шатланышып, «таптык», дип кайталар. Исәнгол баба: «Анда ташлыкмы, абагалыкмы—шундый җир кирәк»,—ди. Егетләр яңадан чыгып, күлне узып, хәзерге Яңа Кенәр елгасына килеп чыгалар. Елга ташлык җирдән ага, ярларында абагалык. Исәнгол баба: «Менә анда авыл корырга ярый»,—дип, берничә улын шул елга буена күчереп утырта».

Җирле тарихны өйрәнүче рус галиме Износковның 1885 елда Казанда басылган «Список населенных мест Казанского уезда с кратким их описанием» исемле хезмәтендә «Мамсинский волость» дигән бүлекчә бар. Андагы материаллардан Иске Кенәрдән күчеп килүчеләрнең Мәмсә суы буена утырулары һәм Яңа Кенәр урынында «Бигашевский починок» исемле авыл булуы аңлашыла. Бүгенге Мәмсә авылын да башта, аны нигезләүче исеме белән, Байчура (Байчуринский починок) авылы дип атаганнар. Байчура авылы янындагы Укше елгасы буенда Укше (Починок Окше) авылы да була. Соңыннан Байчура һәм Укше авыллары үсеп, бер-берсенә кушылып бетәләр һәм Мәмсә елгасы исеменнән авылның яңа атамасы барлыкка килә.

Бигәш, Байчура авылларының нигезләнүләре дә XVII гасырның икенче яртысында булган.

Күренекле татар галиме Ризаэтдин Фәхретдиновның 1908 елда Оренбургта чыккан «Асар» китабының 509 нчы битендә Мәмсә авылыннан бер голяманың шәҗәрәсе китерелә. Ул 1871 елда үлгән Әхмәт бине Ихсан бине Гомәр бине Кадермәт бине Сәет бине Ирмән бине Исәнкол әл-Мәмсәви нәселенә карый. Нәселнең ерак бабасы Исәнкол белән, Мостай бабай сөйләгән Исәнгол—бер кеше дип карарга тулы нигез бар. Бу шәҗәрәнең ерак бабасы XVII гасыр урталарында яшәгән.

1650 нче елларда патша хөкүмәте күп кенә буш җирләрне ул вакытта Мәскәү дәүләтенә хезмәткә күчкән татар мор-

заларына ярлыклар биреп өләшкән. Хәзерге Яңа Кенәр, Мәмсә җирләрен үзләштерү дә шул чорлар, шул вакытлар белән бәйле булса кирәк. Нәкъ шушы елларда патша хөкүмәте Нократтан килгән Хуҗасәетовларга зур җир мәйданнары бирә.

Ихтимал, Мәмсә авылы XVIII—XIX гасырларда күренеклерәк булган, чөнки анда волость үзәге урнашкан. Яңа Кенәр халкының бер өлеше дәүләт салымнарын Мәмсәгә, икенче өлеше Иске Кенәргә илтеп түли торган булганнар. Бу мәгълүмат Яңа Кенәрнең нинди кавемнәрдән оешуын күрсәтә.

Яңа Кенәрдә борынгы нәселләрдән хәзерге Саба районына карый торган Максабаш авылыннан килгән Арслан баба нәселе дә бар.

Авыл халкы «Ашыт каршы», «Мокшытау» җыеннарын бәйрәм иткән. Җыен атналарын уздыру графигында да Яңа Кенәр риваятьтәге Исәнгол баба ягы итеп каралган.

Бигәш авылының, кайсы еллардан «Яңа Кенәр» дип атала башлау мәсьәләсе әлегә ачык кала. Ләкин XVIII гасырның икенче яртысында аның Яңа Кенәр дип аталуы хакында язма документ бар. Яңа Кенәрнең Мәмсә очындагы зиратында 1822 елда куелган таш сакланган. Ул таш шул елда, 53 яшендә үлгән Сәйфулла бине Фәйзулла әл-Болгари, карья-и Яңа Кенәри истәлегенә куелган. Бу язма күп нәрсәләр турында сөйли кебек. Яңа Кенәр атамасы авыл зиратында XIX гасырда куелган күп кенә кабер ташларында очрый. Бу күренеш — авылда материаль кыйммәтләрнең туплана баруы күрсәткече.

Яңа Кенәр халкы, җирләре күп булмау сәбәпле, сәүдәгә керешә. Авылның зур урманы була. Бу урман нинди дер сәбәпләр белән республика төзелгән вакытта Мари илендә калдырыла.

XIX гасырда һәм XX гасыр башында сәүдә капиталы туплану сәбәпле Яңа Кенәрдә агачтан һәм кирпечтән милли архитектура стилендә эшләнгән икешәр-өчәр катлы йортлар, кибет-келәтләр, сырлап-бизәкләп эшләнгән капкалар күтәрелеп чыга. Дүрт мәчетнең күккә ашкан манаралары авылга кабатланмас манзара биргән. Яңа Кенәрнең куе яшеллеккә күмелгән зур зиратларындагы агачлар шушы җирнең халкын күкрәкләре белән сакларга алынган борынгы алыпларның дәһшәтле төмәннәредәй басып торалар. Ул агачлыклар арасыннан биеккә күтәрелгән очлы башлы чыршыларның шәүләләре алыпларның корыч алпакларына, төрле чуклар бәйләнгән сөңгеләренә охшыйлар.

Гәрчә волость Мәмсә дип аталса да, аның идарә бинасы

Яңа Кенәрдә корылган була. Ул бина, соңгы елларга кадәр мәктәп булып хезмәт итеп, 1980 нче елларда сүтелде. Гомумән, Яңа Кенәрдә XIX гасыр агач татар архитектурасы истәлекләре калмады инде. 1930 нчы елларда район үзәге булган Әтнәдә янгын чыккач, Яңа Кенәрнең күпчелек зур, икешәр катлы агач йортларын «Әтнәгә ташыйбыз» дип, әрәм-шәрәм итеп бетерәләр. Калганнары, дәүләт тарафыннан саклау булмаганлыктан, тузып, сүтелеп бетте. XX гасыр башларында корылган берничә бинаны искә алмаганда, Яңа Кенәрнең XIX гасырдан калган күренеше бөтенләй юкка чыкты. Әлбәттә, халык иҗатсыз, эшсез тормый. Яңа Кенәрдә дә бүгенге яңаны тудыру юлында күп эшләр башкарыла, милли архитектура сәнгате традицияләре саклана.

Зиратларда матур каллиграфия белән язылган, шома итеп киселгән таш билгеләр шушы якларда таш кисүче осталар булганлыгы хакында сөйлиләр.

Яңа Кенәрдә XIX гасырда буыннан-буынга килгән балта осталары, һөнәр ияләре дә булган. Шундыйлардан Каюм (1882—1914) бине Хөснетдин (1843—1928) бине Габдерәфикъ, бине Габделгани, бине Габделгазиз бине Гайсә нәселе кызыклы. Бу нәселнең Габдерәфикътан алып XX гасыр уртасына кадәр яшәгән вәкилләре балта осталары буларак танылганнар, алар мәчет салуда махсуслашканнар. Алардан Хөснетдиннең — 34, Габдерәфикъның 36 агач мәчет төзүе хакында мәгълүматлар бар.

Яңа Кенәрдә яшәгән Галим байда зур нәсел шәҗәрәсе һәм авыл тарихыннан хәбәрләр язылган кулъязма була. Шул кулъязмадан укытучы Вәли Хәкимов заманында кайбер хәбәрләрне күчереп алган. Ул язмада Яңа Кенәрдә беренче мәчетнең 1818 елда Зәйни бай акчасына салынуы турында хәбәр ителә, 1870 нче еллар тирәсендә бу мәчетне Өчиле авылына күчереп салалар, чөнки ул Яңа Кенәр халкын сыйдыра алмый инде. Язманың авторы Галим бай, аның әтисе Габделсаттар, аның әтисе Асылмөхәммәт, аның әтисе Хөсәен, аның әтисе Кушай, аның әтисе Аксары исемле булганнар. Асылмөхәммәт Яңа Кенәргә XVIII гасырның икенче яртысында күчеп килгән.

Авылда икенче мәчетне 1860 нчы еллар тирәсендә Мортаза бай акчасына салганнар.

XIX гасыр башларыннан Яңа Кенәрдән чыккан укымышлы кешеләрнең һәм китап күчереп язучыларның исемнәре мәгълүм, алар күчергән китаплар саклана. Ул китаплар бүгенге көндә Казанның төрле фәнни мирасханәләрендә тупланганнар. Татарстанның берләштерелгән Дәүләт музеенда Сөендек бине Габделгазиз тарафыннан 1787 нче еллар

тирәсендә Габид бине Габделгазиз әл-Кенәри җитәкләгән Кариле авылы мәдрәсәсендә күчерелгән «Шәрхел фараиз...» (математика фәненең мирас һәм мал бүлүгә өйрәткән тармагына аңлатмалар) китабы саклана.

Габид бине Габделгазиз бине Гайсә әл-Кенәри 1833 елда Төркиянең Трапезунд шәһәрендә үлеп кала. Аның XIX гасыр башларында күчереп язган китаплары хакында да хәбәрләр бар. Ул күренекле татар филологы Байморад Мәңгәринең остазы була.

Кенәрдән чыккан янә бер зыялы — Салих бине Сәфәр. Ул XIX гасыр башында җәяүләп Бохарага бара, анда укый. Ватанына әйләнеп кайткач, халыкны агарту эшенә керешә, мәдрәсә тота.

XIX гасыр башында Бохарада укып кайткан Кенәр кешесе Исхак Сәгыйтов (мелла Исхак бине Сәгыйть бине Колмөхәммәт-әл Кенәри) эшчәнлеге «Татар әдәбияты тарихы»нда (Казан, 1985.— 74—45 б.) тасвирланган.

Казанда, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты кульъязмалар бүлеге мирасханәсендә Зыятдин бине мелла Мөхәммәткамал әл-Кенәри, әл-Болгари тарафыннан XIX гасырның беренче яртысында күчерелгән һиндстан галиме Габделхәким бине Шәмсетдин әл-Лаһуриның 414 битлек әсәренең кульъязмасы саклана (39 коллекция, № 1013).

XIX гасыр ахырына таба Яңа Кенәр зурая. Аның күп кенә кешеләре читтә сәүдә итеп йөри. Авылга елына бер-ике мәртәбә генә кайтучылар да күп була. Андыйлар юлда очрашканда бер-берсен танымый да торган булганнар. «Син кайдан?» — дип сорашып, «Кенәрдән!» — дигәч, аптырашып калганнар. Яңа Кенәрнең сәүдәгәрләре шул вакытларда ук Кызылъяр (Казахстандагы Петропавловск), Троицк шәһәрләрендә сәүдә иткәннәр.

1870 нче еллар тирәсендә Яңа Кенәрдән Кече Кенәр (русча «Четырехдворка») исемле авыл бүленеп чыга. Кече Кенәр урынында бу якларда атаклы җир биләүче Мортаза байның 400 дисәтинә чамасындагы җире булган. Мортаза бай әлеге җирен Яңа Кенәр кешесе Габдерәхим балалары — Әхмәтҗан, Әхмәтша, Мөхәммәтҗан һәм Хәмит исемле кешеләргә сата. Алар, ишәеп, бер урам тәшкил иткән авыл булып әверелгәннәр.

1970 нче елларда Кече Кенәр авылы халкын бер совхозга күчерделәр, шуннан соң авыл таралды.

Яңа Кенәрнең 1917 елдан соңгы бай тарихы да бар, ләкин ул өйрәнелмәгән әле.

КҮЛТӘС АВЫЛЫ

Казансуның иң югары агымында аңа күпсанлы уң кушылдыкларының берсе — Күлтәс елгачыгы килеп кушыла. Ул, әйтерсең лә, урманның сихри тынлыгын һәм салкынча һавасын үзенә иңдергән. Куе урманнан юл алучы Күлтәс инешенең берничә атамасы бар. Документларда ул гадәттә Күлтәс дип аталса да, җирле халык аны үзенчә Янык елгачыгы яисә Сулы Алан дип тә йөртә. Шунысы кызык, Сулы Алан дип күбрәк инешнең урман аша агучы өске агымын атыйлар. Монда әле ул челтерәп аккан саф, салкын сулы чишмә генә. Биредә җәйге эссе көннәрдә юлчылар, кыргый җәнлекләр, төрле кош-корт үзләренең сусауларын басалар. Ихтимал, Сулы Алан атамасы урмандагы аланнарның берсеннән алынган. Инешнең Янык дигән атамасының барлыкка килүе исә бу тирәләрне беренчеләрдән булып үзләштергән кешеләр эшчәнлегенә бәйле булуы мөмкин. Яңа, урманлы урыннарга күченеп утыручылар еш кына җирне агачлардан чистарту максатында урманны ут төртеп яндыра торган булганнар. Шундый юл белән алар үзләренә чәчүлек җирләр булдырганнар. Менә шушы берничә атамага ия булган елгачык буена Күлтәс авылы урнашкан. Ул — татар халкының XIX йөз ахырында — XX йөз башында яшәгән күренекле галиме һәм мәгърифәтчесе Шәмсетдин Күлтәси авылы.

Күлтәс авылы шул ук исемдәге инеш тамагыннан ике чакрым өстәрәк, Арчадан егерме чакрым төньяктарак урнашкан. Авылдан ике чакрым көнчыгыштарак данлыклы Себер тракты (юлы) уза. Күлтәс төньяк-көнбатыштан, төньяктан һәм көнчыгыштан урман белән чолганып алынган. Шунлыктан ул урман кочагында утырган сыман күренә. Гомумән, урман Күлтәс авылы кешеләренең яшәешендә элек-электән зур урын биләп тора. Хәзерге вакытта Күлтәскә иң якын торак пунктлар — Арча урман хуҗалыгы, Үрнәк поселогы, Югары, Урта, Түбән Пошалым авыллары — аннан ике-өч чакрым ераклыкта көньяк-көнчыгыш, көньяк һәм көньяк-көнбатыш тарафта урнашканнар.

Күлтәс «Пошалым авылыннан чыккан пүчинкә» (ягъни «починок») буларак әлегә табылган чыганакларда беренче тапкыр 1678 елда телгә алына (Россиянең борынгы документлар дәүләт архивы, 1209 нчы фонд, 6453 нче китап, 555—556 б.). Бу вакытта пүчинкәдә 19 йорт, 21 ир-ат, 5 яшүсмер исәпләнә. Балаларны, хатын-кызларны да кертеп, пүчинкәнең барлык халкы 80 кешегә җиткән булуы мөмкин. Пүчинкә халкы хөкүмәткә тугыз төрле ясак түләгән. Алар хөкүмәт файдасына акчалата һәм натуралата (умарта балы, арыш,

бодай һәм башкалар белән) түләнә торган салым тәшкил иткән. Ясакның күләме әледән-әлегә (әйтик, берничә елга бер тапкыр) үзгәргән. Шулай итеп, 1678 елда Күлтәс әле «пүчинкә» генә булган һәм «Күлтәс» дип аталмаган да. Ә «Пошалым авылыннан чыккан пүчинкә» атамасы исә аңа нигезне 1678 елдан чама белән берничә дистә ел элегрәк Пошалым авылы кешеләре салганлыгы турында сөйли. Төрле чор чыганакларын чагыштырып караганнан соң, бу очракта документта «Пошалым» атамасы астында хәзерге Түбән Пошалым авылы күздә тотылган диген фикер туа. Мисал өчен, әле XIX гасыр ахырында да Күлтәс һәм Түбән Пошалым авылларының җирләре «Түбән Пошалым» дип аталган бер үк җир биләмәсенә, «дача»га караган. Димәк, хәзерге Күлтәс авылына, XVII гасыр урталарыннан да калмыйча, Түбән Пошалым авылыннан күчеп килгән кешеләр башлангыч биргән дип уйларга нигез бар.

Казан университеты каршында эшләп килгән Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте «хәбәрләре»нең бер санында дөнья күргән, 1781—1782 нче елларга караган бер документта Күлтәс авылы «Күлтәс елгачыгы буена урнашкан Пошалым» дип теркәлгән (XVIII т.—4—6 нчы чыгарылыш, 257 б.). Бу вакытта авыл халкы 42 «ревизия җаны»ннан (монда бала-чага кермәгән), ягъни, якынча 84 кешедән торган. Күргәнебезчә, бу очракта Күлтәс авылы чыганакта «Пошалым» буларак искә алына. Соңгы атаманы хәзерге Күлтәс авылына Түбән Пошалым авылыннан күченеп килүчеләр биргән булуы ихтимал. Гомумән, авылларның барлыкка килү тарихында яңа оешкан авылның аңа нигез салучылар биргән авыл исемен кабатлавы гадәти күренеш. Моннан тыш, «Күлтәс елгачыгы буена урнашкан Пошалым» тәгъбире Күлтәс авылының, үзенең хәзерге исемен авыл аркылы агучы елгачыктан алганлыгы турында да сөйли.

И. А. Износков «Күлтәс» топонимы һәм гидронимының барлыкка килүен үзенчә аңлата. Татарча «күл» сүзен ул урысчага сазлык дип тәрҗемә итә, ә топоним, гидронимның «тәс» өлешенә «бөтен» (яки «чат», «гел») мәгънәсе бирә. Ахыр чиктә И. А. Износков «Күлтәс»не «чат («гел») сазлык» («әйләнә-тирә гел сазлык» мәгънәсендә) диген сүзтезмәдән барлыкка килгән дип фараз кыла.

«Авылны чыннан да кечкенә сазлыклы урыннар чорнап алган»,—дип куәтли ул үз фикерен. Ләкин, билгеле булганча, «күл» сүзе татарчадан урысчага берничек тә «сазлык» дип тәрҗемә ителә алмый. Чынлыкта И. А. Износковның «гел сазлыгын» үзгәртә төшеп, «гел күл» дип төзәтү дөресрәк булыр.

Җирле халык нигездә «Күлтәс» атамасы элекке заманнарда Күлтәс авылы тирәсендә булган күпсанлы күлләрдән берсенең исеменнән барлыкка килгән дигән караштa тора. Хәтта ул күлнең «Тәч күл» дигән варианты да китерелә. Ничек кенә булмасын, «Күлтәс» атамасының саф татар атамасы булуы һич тә шик тудырмый. Аның күлгә бәйләнешле барлыкка килүе дә бәхәссез.

Шунысы кызык, 1781—1782 елларга караган чыганак Күлтәс авылы урнашкан урында ул (документта «шунда ук» дип искәртелә) «Абаш» исемле кечкенә генә бер авылны теркәгән. Ул вакытта бу авылда 4 ясаклы «ревизия җаны» (барлыгы, якынча, 8 кеше)—татарлар яшәгән. (Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре.—XVIII т.—4—6 нчы чыгарылыш.—257 б.) Күрәсең, документ XVIII гасырда кешеләрнең хәзерге Күлтәс авылы тирәсенә башка яклардан да күчеп килеп, аларның монда төпләнеп калуларын искәртә. Хәер, И. А. Износковның XIX гасыр ахырында төзелгән «Казан өязенең кеше яшәгән урыннары исемлеге»ндә Абаш авылы инде күренми. Ул чорда инде авылның үз исемен югалтып Күлтәс белән тулысынча кушылган булуы ихтимал.

Күлтәс авылы халкында сакланган риваять-легенда буенча, авыл элекке заманда Яньк елгачыгы буйлап түбәндәрәк, иске Себер тракты янында ук урнашкан булган. Себер трактының икенче ягында куе урман башланган. Себергә илтүче олы юл Күлтәс авылы кешеләре тормышында зур урын алып торган. Моннан Себергә озатылучы тоткыннар, каторжаннар, юлаучылар йөргән. Олы юл кырыенда, Алан капкасы янында, зур торак (барак) торган. Анда юлаучылар куна торган булган. Олы юл тирәсендә талау белән шөгыльләнүче азгын кешеләр дә күп йөргән. Еш кына алардан Күлтәс авылында яшәүчеләр дә зыян күргән. Шуңа күрә, имеш, соңрак авыл Яньк елгачыгы буйлап өскәрәк күчеп утырган. Ләкин Күлтәс авылының кайчан да булса күченүен читләтеп булса да раслаучы язма чыганакларның әлегәчә табылганы юк. Шулай да, авыл халкында сакланган хәбәр буенча, шушы гасырның 50 нче елларында элек Күлтәс авылы урнашкан урынны сөргәндә, имеш, аннан нигез ташлары, бүрәнә кисәкләре һәм башкалар табылган. Ләкин югарыда китерелгән хәбәрләр барысы да фәнни исбатлауны таләп итә.

XIX гасырның 80 нче еллары башында Күлтәс авылында 37 йорт исәпләнгән. Аларда барысы 314 кеше яшәгән (155 ир-ат һәм 159 хатын-кыз). Шул кешеләрдән егермесе авылда торган булып саналсалар да, чынлыкта анда яшәмәгәннәр.

8 ир-ат озак вакытка авылдан хезмәт хакы эшләргә чыгып китә торган булган. Ике кеше йөк ташып көн күргән. Башка 2 кеше умартачылык белән шөгыльләнгән. Аларның 80 умарталары булып, ул умарталар хуҗаларына ел саен 100 сум табыш биргән. Күлтәснең барлык халкы бу вакытта аерым Күлтәс авылы крестьян общинасын тәшкил итеп, аның 714 дисәтинә (якынча 720 гектар) җире булган. Авыл крестьян общинасын община тарафыннан сайланып куела торган староста җитәкләгән. Ләкин чынлыкта староста кайбер вакытта «өстән» дә билгеләнгән.

Авыл халкы XIX гасырда берөзлексез диярлек арта торган. 1856 елда уздырылган X ревизия буенча Күлтәстә барлыгы 218 кеше исәпләнсә (99 ир-ат, 119 хатын-кыз), 1897 елга бу сан инде 356 га җитә (183 ир-ат һәм 173 хатын-кыз), 1908 елның 1 гыйнварена Күлтәс авылында 431 кеше яшәгән (218 ир-ат һәм 213 хатын-кыз). Авылның бу вакытта үзенең мәчете булган, вак-төяк белән сәүдә итүче 2 кечкенә кибет эшләп торган (Описание Казанской губернии.— Казань, 1909). «Пошалым» яки «Кече Пошалым» атамалары авыл исемендә XX гасыр башына кадәр сакланып килгән. Мәсәлән, И. А. Износковның «Казан өязенең кеше яшәгән урыннары исемлеге»ндә Күлтәс авылы «Күлтәс, Күлтәс елгачыгы, Кече Пошалым, Күлтәс елгачыгы буендагы Пошалым» дип берничә исем белән күрсәтелгән. Ахыр чиктә XX гасыр башыннан алып авыл исемендә аның хәзерге «Күлтәс» атамасы ныгып урнаша.

Күлтәс авылының күпгасырлык үткәне төрле тарихи вакыйгаларга да бай. Мәсәлән, Күлтәс авылы халкының XIX гасырның 40 нчы елларында «бәрәңге бунтлары»нда катнашуы мәгълүм. Әлеге бунтларның төп сәбәбе чынлыкта дәүләтнең бу якларда уздырган милли һәм сыйнфый-икътисади сәясәтендә яткан.

Казан артындагы иң матур урыннарның берсенә сыенып утырган Күлтәс авылының үткәненнән кайбер сәхифәләр шулардан гыйбарәт.

ТАРИХИ ҺӘМ МӘДӘНИ ИСТӘЛЕКЛӘР

Арча төбәге элек-электән мәдәни үзәкләрнең берсе булган, күп кенә атаклы мәдәният, фән эшлеклеләрен биргән. Әлеге регион халкыбызның үткәнен чагылдырган тарихи һәм мәдәни истәлекләргә бай.

Апаз

Мәчет.

Апаз авылындагы чукындырылган татарларның мөселманлыкка әйләнеп кайту хәрәкәте XIX гасыр ахырында башлана һәм 1907 елга кадәр дәвам итә. Бу күренеш татар җәмәгатьчелегенең игътибар үзәгендә була. Шуңа күрә, 1917 елның апрелендә Апаз крестьяннарының мәхәллә оештыру һәм ике катлы ярымташ мәчет төзү турында җыелышып кабул иткән карарларын милли-азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкилләре хуплыйлар һәм бу ниятләрне тормышка ашыруны үз карамакларына алалар. Оренбургтагы Диния Нәзарәте 1917 елның 15 маенда үзенең ризалыгын җиткерә. Эшләрнең болай уңышлы башлануында һәм тиз баруында ул чакта Нәзарәт җитәкчелеге әгъзасы булган Хәсәнгата Габәшинең дә өлеше була. С. Ш. Алкин һәм Казан мөселман комитеты рәисе М. Ф. Туктаров, Апаз халкының үтенечен уңай хәл итүне сорап, губерна идарәсенә мөрәҗәгатьләр юллыйлар. Нәтиҗәдә, Апаздагы мәхәллә рәсми рәвештә теркәлә. Төзелеш бүлеге, төзелеш уставының торак йортлардан 20 сажин ераклыкта дини бина-корылмалар төзүне тыйган маддәсенә ишарәләп, мәчетнең проектын раслаудан баш тарта.

Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган ике катлы ярымташ бинасы 1917 елгы планнарга һәм сызымнарга туры килми. Ихтимал, гыйбадәтханә соңрак төзелгән. 1917 елның язында мәхәллә мулласы итеп Спас өязенең Яңа Камка авылы (Татарстанның хәзерге Әлки районына керә) кешесе Габделрәүф Мөхәммәтсафа улы Хәмзин сайланган.

Казанбаш

Мәчет (икенче мәчет)

Икенче мәхәллә мәчете тузган иске гыйбадәтханә бинасы урынында 1892 елда төзелгән. 1822 елда ук барлыкка килгән мәхәллә Казанбаш һәм Көтек авыллары крестьяннарыннан торган, XX гасыр башында анда ир-ат затыннан 110 хуҗалыкта яшәгән 265 кеше исәпләнгән.

1851 елның 8 маенда имам булып Мөхәммәтйосыф Хәлитов (туган елы — 1836), икенче мулла итеп 1890 елның 3 апрелендә аның улы — Вятка губернасы Малмыж өязенең Арбор авылы (Татарстанның хәзерге Балтач районына керә) крестьяны Әсхәдулла Мөхәммәтйосыф улы Хәлитов сайлана (туган — 23.09.1856).

Беренче мәчетнең төзелү вакыты һәм аның мәхәлләсенең

барлыкка килү чоры мәгълүм түгел. Аның мәхәлләсендә Яналы починкасы крестьяннары да исәптә торганнар; мәхәлләдә барлыгы 320 ир-ат һәм 354 хатын-кыз исәпләнгән.

Беренче мәхәллә имамнарыннан Хафиз Хәмзин исеме мәгълүм. Ул бу урынга 1848 елның 6 апрелендә расланган. Шушы ук мәчетнең мулласы итеп 1872 елның 5 июлендә аның улы Садыйк Хафизов сайланган. Гасыр ахырында, 1898 елның 29 сентябрендә имам вазифасы Ягъфәр Сираҗетдиновка (1868 елда туган) күчкән. 1893 елның сентябрендә мөәзин һәм мөгаллим вазифаларын Хафиз Хәмзинның икенче улы Хаммат Хафизов (1843 елда туган) башкарган.

Беренче мәхәллә мәдрәсәсендә 45 малай һәм 40 кыз укыган, ә икенче мәхәллә мәдрәсәсендә 30 малай һәм 25 кыз сабакка йөргән.

Казиле

Мәчет.

Мәчетнең бер катлы кирпеч бинасы Казан губерна идарәсе раслаган проект буенча 1899 елда, шул елда янган агач мәчет урынына төзелгән.

1833 елның 1 ноябрендә мәхәлләнең имам-хатыйбы итеп Таҗетдин Габделҗәлилов (1806—1886) билгеләнгән. Ул Бәрәскә, Мәчкәрә һәм Ташкичү авылларының мәдрәсәләрендә белем алган, гарәп телен белгән. Аның Коръәнне көйләп уку сәнгатенә ия булуы хакында Ш. Мәрҗани искә ала, ул үзе дә бу сәнгать, осталыкка Т. Габделҗәлиловтан өйрәнгән.

Таҗетдин хәзрәт ярты гасырдан артык гомерен әлеге мәчеттә имамлык итүгә биргән. Аны Габделхәй Гатаулла улы Фәйзуллин алыштырган. Г. Г. Фәйзуллинның вафатыннан (03.09.1907) соң имам вазифаларын Сабирҗан Габделбадыйков (туган елы — 1866) башкарган.

Казиле авылы XX гасыр башында мәгарифнең яңа, алдынгы ысул-алымнарына нигезләнгән (җәдид) мәдрәсәсе белән дан казана. Шәкертләр саны артык күп булмаса да,— сабакка барлыгы 50 шәкерт йөргән,— мәхәллә кешеләре мәдрәсә өчен акча кызганмаганнар. XIX—XX гасыр чигендә бу уку йорты өчен махсус, кирпечтән бер катлы бина төзеткәннәр. Ул үзенең күркәмлеге һәм уңайлыгы ягыннан бөтен өяздә иң яхшылардан исәпләнгән.

XX гасыр башында Казиле мәхәлләсендә ир-ат затыннан 137 милектә яшәгән 405 кеше исәпләнгән.

Кер-Хайван

Мәчет.

Агач мәчетнең төзелү вакыты күрсәтелгән мәгълүматлар сакланмаган, XX гасыр башында салынган дигән фаразлар

бар. Бу чорда мәхәлләдә ир-ат затыннан 220 кеше исәпләнгән.

Мәчетнең мәгълүм булган руханилары: имамнар Таһир Сәфәров (1836 елның мартыннан), Мөхәммәтгариф Габдрахманов (1880 елның гыйнвареннан, 1898 елда вафат), беренче мулла Мөхәммәтхәсән Мифтахетдинов (1890 елның февраленнән, туган елы — 1873). Мөхәллә мәктәбендә 60 ир бала һәм 40 кыз белем алган.

Кушлавыч

Шагыйрь Г. Тукайның музей йорты.

Бер катлы агач йорт, утар корылмалары белән, 1976 елда реконструкцияләнгән.

Бу авылда 1886 елның 14(26) апрелендә бөек татар шагыйре Габдулла Тукай дөньяга килгән. Аның әтисе — Кышкар мәдрәсәсен тәмамлаган указлы мулла Мөхәммәтгариф Мөхәммәтгалим улы Тукаев (1842—1886). Ул 1864 елдан Кушлавычта имам-хатыйб булып торган. Шагыйрьнең әнисе Мәмдүдә 1890 елда Сасна (Сосна Пучинкасы) авылы (Татарстанның хәзерге Балтач районына керә) мулласына кияүгә чыккан һәм улын үзенә алдырган.

1955 елда Г. Тукайның туган авылында шагыйрьгә бронза бюст куелган (скульпторы И. А. Новоселов).

Кышкар

Мәдрәсә бинасы.

Бер катлы агач бина XIX гасыр ахырында төзелгән. Ул — кайчандыр Казан губернасында булган иң зур мөселман уку йортының сакланып калган корылмасы.

Мәдрәсә XVIII гасыр уртасында иң бай сәүдәгәрләрнең берсе булган Баязит бине Госман әл-Кышкари тарафыннан оештырылган. Ул берничә сабын заводын биләгән, Россиядә һәм Урта Азиядә сәүдә иткән. Ул һәм аның варис оныклары Муса бине Нәзир, Мортаза бине Мостафа бине Нәзир әл-Кышкариләр мәгариф һәм мәгърифәтчелек файдасына юмарт рәвештә иганәчелек белән шөгыльләнгәннәр. Тырышлык нәтиҗәсез калмаган. Сәгыйть бине Ибраһим әл-Барыши, Фаяз бине Габделгазиз әл-Кенәри, Якуб бине Муса әл-Дөбъязи һәм Исмәгыйль бине Муса әл-Мәчкәрәви (Үтәмешев) кебек дин белгечләре, галимнәрнең тырышлыгы нәтиҗәсендә мәдрәсә атаклы уку йортына, мөдәррислек мәктәбенә әверелгән. Кышкарга ераклардан — Казаннан, Оре-

нбургтан, Семипалатинскидан, Касыймнан һәм башка төбәкләрдән укырга килгәннәр. Мәдрәсәдә белем алучылар арасыннан күп кенә татар зыялылары, атаклы мәдәният әһелләре чыккан. Мәсәлән: Мөхәммәтгариф Тукаев (Г. Тукайның әтисе), Мотыйгулла Төхвәтуллин, Рәшит Ибраһим — руханилар һәм мәгърифәтчеләр, драматург Ф. Халиди һ. б.

XIX—XX гасырлар чигендә Кышкар мәдрәсәсе таркалу чорына керә. Бу хәл татар мәгарифендә моңарчы хөкем сөргән иске ысулларның, схоластик тәртипнең (Кышкар мәдрәсәсендәге уку-укыту шушы тәртипкә нигезләнгән була) кризисы, мәдрәсәгә гасыр дәвамында диярлек матди ярдәм күрсәтеп килгән сәүдәгәрләр нәселенең бөлүе белән аңлатыла. XX гасыр башында әлеге уку йорты үзенең элеккеге данын югалта, гадәти авыл мәктәп-мәдрәсәләре дәрәҗәсенә төшә. Шәкертләр саны да 50 дән артмый.

Мәчет.

Мәчетнең ике катлы кирпеч бинасы 1777 елда сәүдәгәр Баязит бине Госман әл-Кышкари (1797 елда вафат) тарафыннан төзетелгән. 1865 елда аның оныкларыннан берсе Мортаза бине Мостафа бинаны киңәйтеп, аңа кирпеч манара кордырган.

Мәчетнең беренче имамнарыннан берсе — Казан губернасы Тәтеш өязенең Барыш авылы (Татарстанның хәзерге Кама Тамагы районына керә) кешесе Сәгыйть бине Ибраһим була. Ул 1896—1913 елларда мәдрәсәгә җитәкчелек итә, мөдәррис буларак абруй казана. Аның вафатыннан соң имамлык Фаяз бине Габделгазиз әл-Кенәригә күчә. Бохара һәм Кабул (Әфганистан) уку йортларында белем алган бу рухани 1835 елда вафат була; имам-хатыйб булып Якуб бине Яхъя әл-Дөбъязи (1779—1844) билгеләнә.

Аның вафатыннан соң, 1846 елның 10 августыннан, 40 ел дәвамында мәчеткә атаклы имам Исмәгыйль бине Муса (М. М. Үтәмешев) җитәкчелек итә. Аңа уллары Ибраһим (1871 елның 27 февраленнән) һәм Габдрахман (1876 елның 24 февраленнән) Үтәмешевләр булышалар. Соңгысы 1887 елда мәрхүм әтисе урынына өлкән мулла итеп сайлана. Аннан соң беркадәр вакыт мулла булып мөәзин Мөхәммәтгомәр Муса улы Айдашев (туган елы — 1861) тора. Аны 1900 елның 8 июлендә Шәмсетдин Мирзаәхмәт улы Үтәгәнов (туган елы — 1857) алыштыра.

XX гасыр башында Кышкардагы мәхәлләдә ир-ат затыннан 214 милектә яшәгән 613 кеше исәпләнгән.

Үтәмешевләр йорты.

Бер катлы агач йорт XIX—XX гасырлар чигендә төзел-

гән, имам-хатыйб Габдрахман Исмәгыйль улы Үтәмешевнең милке булган. Г. И. Үтәмешев — чыгышы белән Мәчкәрә авылының атаклы сәүдәгәрләре нәселеннән. Аның әтисе Исмәгыйль Муса улы Үтәмешев (1887 елда вафат) 1844 елда Бохарадан укып кайтып Кышкарда мулла була, заманының укымышлы кешесе, тирән белемле мөдәррис дан казана, шәкертләр туплый. Әмма, Ш. Мәрҗани фикеренчә, табигать тарафыннан бирелгән сәләтенә һәм гыйлемлелегенә карамастан, И. М. Үтәмешев тәкәбберлектән котыла алмаган, дан-шөһрәт яраткан. Ул Ш. Мәрҗанинең фикри дошманына әверелгән. Шулай да, Җ. Вәлиди бәяләвенчә, И. М. Үтәмешев «үз чорының атаклысы булган, хәтта Бохарада да аның абруе белән исәпләшкәннәр».

Хәзерге вакытта сакланган йорт, ихтимал, И. М. Үтәмешевнең вафатыннан соң аның улы Г. И. Үтәмешев тарафыннан төзетелгән.

Мендеш

Л. В. Мостаев йорты.

Мәхәллә мәчете рухание имам Лотфрахман Вәлиәхмәт улы Мостаевның бер катлы йорты XX гасыр башында төзелгән. 1918 елда йорт хуҗасыннан тартып алынган һәм анда авыл советы урнашкан.

Мендеш авылы руханиларыннан тарихта тирән эз калдырган шәхес — имам Фәйзулла Мортазин әл-Мендеши (1850 елда вафат). Замандашлары тарафыннан «йолдызчы» дип исемләнгән Фәйзулла хәзрәт заманының камил белемле кешесе, зыялысы була. Ул математика фәннәре һәм астрономия өлкәсендә тирән белемнәр үзләштерә, кояш һәм айның тәүлеклек хәрәкәтен исәпләп календарьлар төзи, сәгатьләр һәм астрономик приборлар ясый. Бу әйберләр озак еллар дәвамында Ш. Мәрҗанидә сакланган.

Ун ел узгач, 1860 елның 27 октябрендә имамлык вазифалары Вәлиәхмәт Габдрахман улы Мостаевка (туган елы — 1838) йөкләнә. 1894 елның 21 декабрендә мәхәллә халкы аңа ярдәмче итеп улы Лотфрахман Мостаевны (туган елы — 1867) билгели. Л. В. Мостаев мәдрәсә белән җитәкчелек итүне дә үз өстенә ала. Анда 70 ир бала һәм 65 кыз укыган.

Орнашбаш

Мәчет.

Мәчетнең хәзерге көндә сакланган бер катлы агач бинасы 1907 елда иске (1887 елда корылган) гыйбадәтханә урынында төзелгән.

Орнашбаш авылындагы мәхәлләнең XIX гасыр башында ук рәсми рәвештә теркәлгән булуы мәгълүм. Ул чорда имам-хатиб вазифаларын Габделҗаббар бине Габдрахман әл-Орнашбаш (1829 елда вафат) башкарган. Ул күренекле педагог һәм дин белгече булган, 1823 елда Оренбургтагы Диния Нәзарәтенең җитәкчелегенә сайланган (утырышчы, заседатель). 1826 елда Габделҗаббар хәзрәт Казанга кайткан һәм «Барудия» мәчетендә мулла булып урнашкан. Җитәкчесез калган Орнашбаш мөселманнары Кариле авылы имамы Габделгазиз бине Гайсә әл-Кенәрине чакырганнар. Габделгазиз әл-Кенәри Орнашбашта мәдрәсә ачкан. Беркадәр вакыт эшләгәннән соң ул хаҗ сәфәренә чыккан. Юлда вафат булып, Төркиядә җирләнгән. Аның урынына улы Габит бине Габделгазиз сайланган. Ш. Мәрҗани бәяләвенчә, Габит хәзрәт намуслы, юмарт һәм игымлы кеше булган. Аның бу сыйфатлары 1833—1879 елларда имам-хатиб булып торган улы Мөхәммәтсадыйк Габитовка (Габит улына) күчкән. 1879—1917 елларда мәхәлләне бер-бер артлы аталы-уллы Габделгәлләм һәм Габдулла (туган елы — 1874) Зәбировлар җитәкләгән (1879—1899, 1899—1917).

XX гасыр башында мәхәлләдә ир-ат затыннан 400 кеше исәпләнгән. Мәдрәсәдә 54 ир бала һәм 43 кыз укыган.

Сарай-Чокырча

Мәчет.

Мәчет биналарының берсе 1908 елның 22 февралендә янган. Шул ук елның май аенда Г. Мансуров мәчетнең яңа проектын әзерләгән, Казан губерна идарәсе аны раслаган (17.01.1909).

XX гасыр башында мәхәлләдә ир-ат затыннан 112 хуҗалыкта яшәгән 395 кеше исәпләнгән. XIX гасырның 60 нчы еллары башында имамлык вазифаларын Гали Габделкәримов башкарган. 1866 елның гыйнварында аны Гариф Шәфиков алыштырган, XX гасыр башына кадәр мәхәлләне ул җитәкләгән. 1907 елның сентябрендә имам-хатиб булып Габделгазиз Мөхәммәткамалов (туган елы — 1882) сайланган. Авыл мәктәбендә 43 ир бала һәм 40 кыз укыган.

Ташкичү

Мәчет.

Мәчетнең ике катлы кирпеч бинасы 1817 елда сәүдәгәр Сөләйман Нәзиров (1837 елда вафат) тарафыннан төзетелгән.

XVIII — XIX гасырларда Ташкичү үзенең мәдрәсәсе белән шөһрәт казанган. Даны тирә-якларга таралган әлеге уку йортында заманының зыялылары, күренекле дин белгечләре дәресләр биргән, укыган. Алар арасында ахун Габделсәлам бине Оруви аерым урын алып торган. Габделсәлам хәзрәт, дин гыйлеме генә өйрәтеп калмыйча, шәкертләрдә мөстәкыйль фикерләү үстерергә омтылган. Аңардан дәресләр алган Габдулла Галиевнең (Батыршаның, 1715—1762) 1755 елда патша хөкүмәтенең колониаль сәясәтенә каршы күтәрелгән халык хәрәкәтен җитәкләве дә, ихтимал, очраклы хәл булмагандыр.

XIX гасыр башында мәчеттә имам итеп Шәмсетдин бине Габдерәшит билгеләнә. Ул Кышкар авылында туа, бик яшьли әти-әнисез кала. Үзенең балалары булмаган Ташкичү сәүдәгәре Баязит бине Ибраһим ятим малайны үз тәрбиясенә ала. Ул аның укымышлы булуын тели, Шәмсетдин Бохарадан әйләнеп кайтуга, аңа өлкән мулла һәм мөдәррис вазифаларын тәкъдим итә. Сәүдәгәр яшь рухани, мөдәррис өчен зур мәдрәсә төзетә. Шәмсетдин хәзрәт анда дәресләр бирә. 1820 нче елларда Шәмсетдин бине Габдерәшит хаҗ сәфәренә кузгала. Юл уңаенда ул Мисырда була һәм әлеге илнең хөкемдары Ибраһим паша белән таныша. Ибраһим паша имамның гыйлем дәрәҗәсен, белемнәрен югары бәяли һәм аңа Каһирәнең атаклы «Әл-Әзһәр» университетында фарсы теле укытучысы булып эшләргә тәкъдим итә. Шәмсетдин бине Габдерәшит тәкъдимне кабул кыла һәм анда җиде ел эшләп, 1832 елда вафат була.

Шәмсетдин хәзрәтнең Шәрекъкә китүеннән соң озак та үтми, 1820 елда Ташкичү мәчетенең тагын бер мулласы — Габделсәлам бине Габдрахман әл-Курсави дөнья куя. 1821 елда аның урынына Баһаветдин бине Сөбхан (1787—1856) — Ш. Мәрҗанинең әтисе билгеләнә. Чәки эль-Кобра авылыннан (хәзер Татарстанның Арча районына керә) чыккан Баһаветдин хәзрәт 12 ел Бохарадагы «Турсуния» мәдрәсәсен тәмамлаган, соңыннан 1814—1821 елларда Ябынчы авылы мәчетендә имам-хатиб булып торган. Баһаветдин хәзрәт Ташкичүдә педагогик эшчәнлек җәелдерә. Аның мәдрәсәсендә улы Шиһабетдин (атаклы фикер иясе, тарихчы-галим һәм мәгърифәтче) фән серләренә төшенү юлында беренче адымнарын ясый. Баһаветдин бине Сөбханның вафатыннан соң, имам-хатиб итеп 1858 елның 28 январенда аның улы Садретдин раслана. Садретдин бине Баһаветдин ярты гасырдан артык вакыт дәвамында үз вазифаларын башкара. 1890 елның июленнән аңа улы Габделмөэмин Баһаветдинов — мәхәлләнең икенче имам-хатибы булышлык итә башлый.

XX гасыр башында Ташкичү мәхәлләсендә ир-ат затыннан 160 хуҗалыкта яшәгән 526 кеше исәпләнгән, мәдрәсәдә 30 шәкерт укыган.

Чиканәс (Алыс Тархан)

Мәчет.

Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган агач бинасы 1889 елда төзелгән.

Гыйбадәтханәнең өч руханиеның исеме генә мәгълүм.

Таҗетдин Мостафиң (1798—1845). Ул 1834 елга кадәр имам булган һәм Тифлиска китеп, Кавказ мөфтие булып билгеләнгән.

XX гасыр башында мәхәлләне Фәйзерахман Ибраһимов (туган елы — 1845) җитәкләгән. Ул имам булып 1863 елның 22 февралендә расланган. 1900 елның 8 маенда аның улы Ширъяздан (туган елы — 1876) икенче мулла булып сайланган.

Чөмә-Елга

Мәчет.

1904 елның апрелендә Казан губерна идарәсе яңа гыйбадәтханә төзергә ризалык биргән. Мәчет 1905 елда төзелгән. XX гасыр башында мәхәлләдә ир-ат затыннан 415 кеше исәпләнгән.

1842—1873 елларда мәхәлләне Гиматдин Мөхәммәтрәхимов җитәкләгән. 1873 елда аны улы Габделсабир (туган елы — 1844) алыштырган. 1905 елның февралендә мәчетнең икенче имам-хатибы итеп Түбән Ушма авылы (Татарстанның хәзерге Мамадыш районына керә) кешесе Гарифулла Сәлахетдинов (туган елы — 1872) билгеләнгән.

XX гасыр башында мәхәллә мәдрәсәсендә 40 шәкерт укыган.

Югары Бирәзә

Мәчет.

XX гасыр башында Югары Бирәзә мәхәлләсендә ир-ат затыннан 120 милектә яшәгән 369 кеше исәпләнгән. Иске мәчет бинасы барлык мөселманнарны да сыйдыра алмаган, шуның өчен мәхәллә халкы тузган мәчетне сүтеп, аның урынына яңа гыйбадәтханә төзергә карар кылган. Мәчетнең сызымын Габдулла Мансуров төзегән, 1902 елның 28 маенда Казан губерна идарәсе тарафыннан расланган. Мәчетнең

сакланган агач бинасының тышкы күренеше белән Мансуров сызымы арасында кайбер аерымлыклар бар.

1849 елның 28 июненнән 80 нче еллар уртасына кадәр имам булып Сиражетдин Якупов торган. 1886 елның маенда аның урынына улы — Татар Такталысы авылы (Татарстанның хәзерге Спас районына керә) кешесе Минһаҗетдин Сираҗетдинов (Сираҗетдин улы) сайланган (туган елы — 1860).

Югары Курса

Мәчет.

Мәчетнең кирпеч бинасы XIX гасыр уртасында Муса Апанаев уллары, икенче гильдия сәүдәгәрләре Гобәйдулла һәм Габделкәрим Апанаевлар тарафыннан төзетелгән, ә 1863 елда бинаны төньяк тарафта өч тәрәзә киңлегендә зурайтканнар. 1880 елда мәчет төзәттерелгән, аның түбәсе һәм манарасы яңартылган.

XVII—XIX гасырлар чигендә мәхәлләдә имам-хатиб булып күренекле татар галиме, дин белгече Габденнасыйр Курсави эшли. Ул авылда мәчет ача. 1808 елда Г. Курсави Бохарага укырга китеп бара, аның урынына абыйсы Габделхаликъ Курсави (1839 елда вафат) билгеләнә. Ул дин белемен тирәнтен үзләштергән (Бохарада, Төркиядә һәм Мисырда укыган) кеше була. Урта Азиядә уңышлы сәүдә итә, бай милеккә ирешә. Ихлас күңелле һәм нык иманлы кеше буларак, Габделхаликъ мулла ишан вазифаларын да намус белән башкарган, үз мөридләре арасында зур абруй казанган. Аның вафатыннан соң, Габделхаликъ хәзрәт урынына кияве Хәсән Хәмитов билгеләнә. Х. Хәмитов чыгышы белән атаклы Чистай сәүдәгәрләре Уразгильдиевләр нәселеннән була, шәһәр һәм Мәчкәрә, Олы Сөн авылларының мәдрәсәләрендә укый. Ул, Ш. Мәрҗани билгеләп үткәнчә, саф әхлаклылык белән сугарылган һәм шәригать кануннарына тугры кеше булган. Вафаты — 1859 елда.

1859 елның 17 сентябрендә Норма авылының (Татарстанның хәзерге Мамадыш районына керә) элеккеге мулласы, чыгышы белән Кече Әшнәк авылы (Татарстанның хәзерге Балык Бистәсе районына керә) кешесе Гатаулла Мөхәммәтов мәчетнең имам-хатибы булып сайлана. Ул Апанай, Кышкар, Мендеш мәдрәсәләрендә укыган, Фәйзулла хәзрәттән астрономия, алгебра һәм геометрия буенча дәресләр алган. Г. Мөхәммәтов 40 ел дәвамында үзенең белемнәрен мәдрәсә шәкертләренә бирә. Нәкъ менә Гатаулла хәзрәт җитәкчелек иткәндә үсеш чоры кичергән. Анда һәр ел саен 70 тән артык шәкерт белем алган.

Г. Мөхәммәтов вафатыннан соң имам-хатиб итеп Х. Хәмитовның улы — Мөхәммәтшакир Хәсән улы Уразгилдиев (16.06.1861—1908) билгеләнә. Ул моңа кадәр икенче мулла вазифасын башкарган (указын 1890 елның 31 августында алган). Әмма авыл мәхәлләсенең башында ул озакка кала алмаган. 1897 елның февралендә үк, Казанның бай сәүдәгәрләре чакыруы буенча, М. Х. Уразгилдиев губерна үзәгенә күчә һәм Печән базары мәчете мәхәлләсенә җитәкчелек итә башлый. Бушаган урынга 1895 елның 23 декабрендә М. Уразгилдиевнең туганы Мөхәммәтгариф сайлана (1870 елның 25 июнендә туган).

XX гасыр башында мәхәлләдә ир-ат затыннан 680 кеше 246 хуҗалыкта яшәгән.

Яңа Кырлай

Мәчет.

Рәсми рәвештә теркәлгән мәхәллә 1807 елда оешкан. Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган бер катлы агач бинасы Казан губерна идарәсе тарафыннан 1911 елның 29 апрелендә расланган проект буенча төзелгән. Аңарчы XIX гасыр уртасында салынган һәм Синод фәрманы белән (1887 елның 16 июне) биш вакыт мәчеттән җамигъ мәчет итеп үзгәртелгән агач гыйбадәтханә эшләп килгән.

1849 елның 15 апрелендә имам-хатиб булып Гатаулла Гобәйдуллин сайлана. Ул, 40 ел буена үз вазифаларын башкарып, вафат булгач, аның урынына улы Фәтхерахман Гатауллин (туган елы — 1857) билгеләнә. Ф. Гатауллин 1917 елга кадәр имам булып тора, исеме тарихка Г. Тукайның беренче укытучысы буларак кереп кала.

1892 елның июнь уртасында авыл крестьяны Сәгъди абзый булачак шагыйрьне Өчиле авылыннан Кырлайга алып кайта, ә шул ук елның көзендә Габдулланы хәзрәт хатынына Маһруйбикә абыстайга сабакка бирәләр. Малай укуга сәләте белән бөтен кешене шаккатыра, шуны истә тотып, бер елдан соң ук, Габдулланы мәхәллә мәдрәсәсенә язалар. Монда ул, Фәтхерахман хәзрәт җитәкчелегендә башлангыч әдәбиятны үзләштереп, Коръән өйрәнүгә күчә. 1894 елның көзендә Г. Тукай Яңа Кырлай авылыннан китә. Икенче тапкыр шагыйрь бу авылда 1907 елның октябрендә була.

Яңа Кырлай авылы мәдрәсәсе артык зур булмаган. 1893 елда анда 17 малай һәм 13 кыз укыган. Мәхәлләдә 98 хуҗалык булып, аларда 269 ир-ат исәпләнгән.

Шагыйрь Г. Тукайның музей-йорты.

Бер катлы агач йорт XIX гасыр ахырында салынган.

1976 елда, аны реконструкцияләү белән бер үк вакытта музей комплексы төзелгән (архитекторлары Ю. Г. Мөхәммәтшин, Р. В. Билалов, скульпторлары Б. И. Урманче һәм М. К. Завьялова).

Биредә крестьян Сәгъди абзый гаиләсендә 1892—1895 елларда Г. Тукай тәрбияләнгән. Кырлайда булачак шагыйрь халкыбызның бай рухи мәдәниятенә якынайган, беренче тапкыр кулына китап алган, Фәтхерахман хәзрәт мәдрәсәсендә укыган. 1895 елда Г. Тукайның апасы Газизә Усманова булачак шагыйрьне Уральск шәһәренә алдыра.

Яңа Сәрдә

Мәчет.

Яңа Сәрдә авылындагы мәчет XIX гасыр ахырында төзелгән. Мәхәлләне озак еллар дәвамында Монасыйповлар нәселеннән чыккан имамнар җитәкләгән. Мәсәлән, 1848 елның 12 июлендә (кайбер мәгълүматлар буенча — 12 ноябрьдә) имам булып Мөхәммәтсадыйк Монасыйпов сайланган. Ул үзенең вазифаларын XIX гасырның 80 нче еллары уртасына кадәр башкарган. 1869 елда икенче мулла итеп аның улы Миргазиз Мөхәммәтсадыйков (Мөхәммәтсадыйк улы, туган елы — 1846) расланган. 1906 елның 16 декабрендә имамлык М. Монасыйповның оныгы Лотфулла Миргазизовка (ягъни Миргазиз улына, туган елы — 1881) йөкләнә.

XX гасыр башында әлеге мәхәлләдә ир-ат затыннан 60 хуҗалыкта яшәгән 356 кеше исәпләнгән.

Әтнә

Мәчет.

Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган агач бинасы 1908 елдан соң төзелгән, чөнки әлеге ел документларында 1800 елда салынган мәчет хакында бәян ителә. XX гасыр башында мәхәлләдә ир-ат затыннан 78 хуҗалыкта яшәгән 215 кеше исәпләнгән. 1859 елның февраленнән башлап, биредә 29 ел дәвамында Шәрәфетдин Сәйфуллин (1824—24.11.1888) имам-хатиб булып торган. 1889 елда имам итеп Түбән Пошалым авылы (Татарстанның хәзерге Арча районына керә) кешесе Минһаҗетдин Фәсхетдинов (туган елы — 1859) билгеләнгән. Мәхәллә мәдрәсәсендә 25 ир бала һәм 30 кыз укыган.

Өчиле

Мәчет.

Рәсми документлардагы мәгълүматлардан күренгәнчә,

мөстәкыйль мәхәллә 1787 елда оешкан. Мәчетнең хәзерге вакытта сакланган бер катлы агач бинасы 1878 елда төзелгән.

1879 елның 4 апрелендә имам-хатиб булып Зиннәтулла Зәйнелбәширов (30.12.1829—1909)—Г. Тукайның әнисе буенча бабасы сайлана. 1890 елның февраль-мартында Зиннәтулла хәзрәт ятим калган оныгын Саснадан Өчилегә алып килә. Биредә дүрт яшьлек Габдулла кыш башына кадәр яши. Шуннан соң аны бабасы Казанга—вак-сәүдәгәр Мөхәммәтвәли гаиләсе тәрбиясенә озата. Зәйнелбәширов вафатыннан соң аның урынына 1907 елның 17 ноябрендә улы Кәшфелкәбир (1885—1938) билгеләнә. Мәхәлләдә ир-ат затыннан 217 кеше исәпләнгән. Мәдрәсәдә 15 ир бала һәм 18 кыз сабак алган. Авылда 75 хуҗалык булган.

ЮГАРЫ, УРТА, ТҮБӘН ПОШАЛЫМ АВЫЛЛАРЫНЫҢ БАРЛЫККА КИЛҮЕ ҺӘМ ҮСЕШЕ

Пошалым атамасын Казансуның уң кушылдыгы булган Пошалым елгачыгы буендагы өч татар авылы йөртә. Бу авылларның тарихы күпмедер дәрәҗәдә Казан артындагы бүтән татар авылларыныкы белән охшаш һәм күп кенә башка очраклардагы шикелле үк әлегә бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән. Авторның Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларының борынгы тарихын язарга алынуы аның үзенең чыгышы буенча Урта Пошалым авылы кешесе булуы белән дә аңлатыла.

Җирле халыкта Пошалым атамасының килеп чыгышына кагылышлы төрле фикерләр яшәп килә. Күпләр аны «поши аулыйм» яки «поши аланы» сүзтезмәләреннән килеп чыккан дип, татар теле җирлегендә аңлатырга тырыша. Чыннан да, хәзерге вакытта өч Пошалым да урманга якын гына, аннан 1—3 км ераклыкта урнашкан. Борынгы чорда бу авылларның тирә-ягы куе урман белән капланган булган. Әлбәттә, ул урманда башка кыргый җәнлекләр белән беррәттән пошилар да күпләп яшәгән. Ләкин җирле халыкның Пошалым атамасы оешуга кагылышлы фаразлары асылда тарихи хәтергә түгел, ә бәлки тарихи күзаллауларга гына корылган булса кирәк. Чөнки тарихи чынбарлык ул фаразларның дөреслеген шик астына куя. Мәсәлән, XVIII—XIX гасырларда Югары, Урта Пошалым авылларының Нырты дигән икенче атамалары да булган. Казан университеты каршында эшләп килгән археология, тарих һәм этнография җәмгыятенең «хәбәрләр»ендә бастырылган, 1781—1782 нче еллар-

га караган «Казан наместнигы турында ведомостьлар»да Югары Пошалым «Нырты авылы, Усад булып яшиләр» дип, ә Урта Пошалым «Нырты елгачыгы башындагы Урта авыл, Яңа Пошалым» дип күрсәтеләләр (Хәбәрләр.—XVIII т.—4—6 нчы чыгарылыш.—257 б.). Ә инде XIX йөзнең 80 нче еллары башында И. А. Износков төзегән «Казан өязенең кеше яшәгән урыннары исемлеге»ндә (Казан, 1885) Югары Пошалым авылы «Югары Пошалым, Пошалым елгачыгы башы, Нырты, Усад булып яшиләр» дип, Урта Пошалым исә «Урта Пошалым, Урта Нырты, Нырты елгасы башы» дип билгеләнгән. Шунысы кызык, XVII гасыр чыганакларында бу авылларның Нырты дигән икенче атамалары күренмичә, Пошалым дигән исемнәре генә күзгә чалына. Димәк, хәзерге Югары, Урта Пошалымнарның Нырты дигән атамасы «Пошалым»га карата икенчел булып, XVIII гасырда гына пәйда булган. Ныртының төрки-татар топонимы, гидронимы булуы мәгълүм. Мәсәлән, Татарстанның хәзерге Саба районында Олы Нырты, Урта Нырты, Завод Нырты авыллары бар. Безнең очракта Нырты топонимы, гидронимы хәзерге Югары, Урта Пошалым авыллары, Пошалым елгачыгы исемнәрендә сакланып калмаган. Күрәсең, тарихи чыганаклар җирле татар халкының күрсәтелгән авыл, елга исемнәрен үзенә җайлаштырып үзгәртергә тырышып каравын теркәп калдырганнар. Әлбәттә, татар кешеләре хәзерге Югары, Урта Пошалым авылларына, Пошалым елгачыгына исемнәрне үзләре биргән булсалар, Пошалым топонимын, гидронимын Нырты белән алыштырырга омтылып карамаслар иде. Бу урында Пошалым елгачыгы Казансуга килеп кушылган төштә урнашкан хәзерге Тлаңгыр авылының XVIII—XIX гасырларда шулай ук Кече Пошалым һәм Тлаңгыр дигән ике исем йөрткәнен искәртеп үтү кызыклы булыр. Ахыр чиктә бу авыл атамасында Тлаңгыр дигән төрки-татар топонимы өстенлек ала.

Шулай итеп, хәзерге Югары, Урта Пошалым авыллары, Пошалым елгачыгы үзләренең төрки-татар исемнәрен йөртсәләр Пошалым дип түгел, ә бәлки «Нырты» дип аталырлар иде. Димәк ки, Пошалым татар-төрки топонимы, гидронимы түгел. Һәрхәлдә, тел галимнәренең бу атаманың килеп чыгышын татар теле җирлегендә аңлатырга тырышу очраклары безгә мәгълүм түгел.

Пошалым атамасының килеп чыгышына кагылышлы Казан дәүләт университеты галиме, тел белгече Гомәр Саттаровның фикере кызыклы. Аныңча Пошалым атамасы «пышалыны», ягъни «киндерле» дигән удмурт сүзеннән килеп чыккан. Чыннан да, Пошалым елгачыгы буйлап хәзерге

Түбән Пошалым авылыннан берникадәр түбәндә, елгачыкның уң як ярында борынгы «ар зираты» урыны бар. Мәгълүм булганча, элек-электән татарлар «ар» дип удмуртларны атап йөрткәннәр. Атап кителгән «ар зираты» Пошалым елгачыгы буендагы «чирмеш зиратлары»ннан (мари зиратларыннан) борынгырак. Күрәсең, якынча XIV—XV гасырларда, ә бәлки аннан да элегрәк, Пошалым елгачыгы Казансуга койган тирәләрдә кечрәк кенә удмурдт авылы булган. Удмуртларның Пошалым елгачыгына исем биреп, соңыннан ул елгачык буенда барлыкка килгән татар авылларының да үз атамаларын шуннан алган булулары бик ихтимал. Киндергә килгәндә исә, ул борынгы җирле культура булган. Аны Идел буе халыклары зур тырышлык куеп үстергәннәр (Этнография народов Поволжья.—М., 1964.—С. 29.). Хәер, бу очракта сүз элекке заманнарда Пошалым елгачыгы буйлап үскән кыргый киндер үсемлеге турында да барырга мөмкин. Шул ук вакытта Пошалым атамасының мари теле җирлегендә барлыкка килгән булу ихтималы да бар. Хәзерге мари телендә бу топонимга, гидронимга аваздаш сүзләр шулай ук күп. Ничек кенә булмасын, югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, без Пошалым атамасының фин-угор телләре җирлегендә барлыкка килгәнлеге турындагы фикерне куәтләргә мәҗбүрбез. Бу нисбәттән тел галиме Гомәр Саттаров фикеренең дөреслеккә туры килү ихтималын да искәртеп үтик. Ләкин моннан әле Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларына удмуртлар яки марилар нигез салган дигән нәтиҗә чыкмый. Һичшиксез, бу авыллар үзләренең атамаларын Пошалым елгачыгыннан алганнар.

Пошалым искә алынган тарихи чыганакларның иң борынгыларыннан берсе 1619 елга карый. Захар Онучинның Казан өязе ташландык җирләрен теркәгән кенәгәсендә Пошалым «бушлык» (русча «пустошь») буларак теркәлгән. «Бушлыклар» дип ул чорда кайчандыр кеше яшәгән буш, ташландык җирләрне атаганнар. Безнең өчен бик әһәмиятле булганлыктан. Захар Онучинның атап кителгән кенәгәсеннән бер өземтәне биредә нәкъ чыганактагыча, үзгәрешсез китерәбез. Документның беренче тапкыр дөнья күрүен дә искәртеп үтик. Чыганакта мондый юллар бар:

«Пустошь Пшалым по речке Пшалыме в вершине поречевской усад (чыганакта шулай.— *Авт.*). По смете пашенные переложные земли двадцать чети, да зарослей по смете тридцать чети, да сенных покосов по той же речке и дубравам и по глухим полянам по смете сто пятьдесят копен. А в сыску про ту пустошь сказали новокрещен деревни Азяк Семейка Иванов да чюваша деревни Ябаш Тоиш Янзегитов,

Болтай Уклемов, Байбулат Ишбулатов, Токтамыш Кудашев, Бахтыгильдей Бахтеяров, Тойгозя Байсеитов: та пустошь выгор (чыганакта шулай.— *Авт.*). А ныне тою пустошью владеют чюваша деревни Утни староста Елкей Епанчин с товарыщи по оброчной грамоте на пятьдесят копен. И та пустошь от Арского города сорок верст, из Казани города сто верст» (чынлыкта бу ара кимрәк.— *Авт.*). (Россиянең борынгы документлар дәүләт архивы.— 1209 ф.—153 нче кит.—1282—1283 бб.).

Бу документны соңрак чорга караган чыганаклар белән чагыштырып караганнан соң, анда сүз хәзерге Югары Пошалым авылы турында бара дигән фикергә киләбез. Ул вакытта әле Рус дәүләте Казан ханлыгын басып алганга берничә дистә ел гына узган була. Документта шул чорда татарларны христианлаштыру шаукымының бер чагылышы буларак Әзәк авылының «яңа чукынган» кешесе Семен Иванов искә алына. Чыганактагы «чювашлар»ны шулай ук чуаш халкы вәкилләре белән бутамаска кирәк. «Чюваш» төшенчәсе, ул вакытта сыйнфый-иҗтимагый мәгънәгә ия булып, ясаклы яки крепостной кешеләргә карата кулланылган. Әлбәттә Иябаш, Өтнә авылларының халкы ясаклы татарлардан торган.

Документтан күренгәнчә, 1619 елда Югары Пошалымда әле кеше яшәмәгән. Авыл урынында «бушлык» булган. Ләкин Югары Пошалымнан 4—5 чакрымда гына урнашкан Өтнә авылының ясаклы татарлары мондагы җирләрдән инде файдаланганнар. Моның өчен алар дәүләткә билгеле бер күләмдә оброк (салым) түләп торганнар. Бу җирләрдә хуҗалык итәргә рөхсәт бирүче махсус грамотада 50 чүмәлә печән турында гына сүз барса да, 1619 елда Өтнә кешеләренең Пошалым «бушлыгында» инде 20 чирек («чирек» — русча «четверь»тан тәрҗемә, I чирек —0,54627 га) җир биләгән чәчү һәм 150 чүмәләлек печән җирләре була. Өтнә авылы кешеләренең үк XVII гасырның 20 нче елларыннан да калмыйча монда яңа авылга нигез салган булулары да ихтимал. Шул ук вакытта Югары Пошалымның 1619 елда «бушлык» булуы бу урында кайчандыр элегрәк тә, күрәсең Казан ханлыгы чорында ук, авыл булганлыгы турында сөйли. Ул авыл халкының йә игенче татарлардан, йә аучы марилардан торган булуы ихтимал. Ихтимал, Югары Пошалым авылының беренчел халкы ни сәбәпледер үзенең торган җирен ташлап китәргә мәҗбүр булган. Бәлки моңа Рус дәүләтенең Казан ханлыгын басып алуы белән бәйле вакыйгалар сәбәпче булгандыр. Ул чорда Арча ягында күп кенә авыллар бушап калган.

Арча даругасына караган Шалым дигән авыл Казан өязенең 1602—1603 елларга караган язу кенәгәсендә дә искә алына. Бу документтан күренгәнчә, патша хөкүмәте 1601—1602 еллардан элегрәк йомышлы татар Бачкеш Байчуринның Шалым авылындагы җирләрен алып ясаклы кешеләргә тапшыра. Бачкешның үзенә Югары Әйшә авылында яңа җирләр бирелә. (Писцовая книга Казанского уезда 1602—1603 гг.—Казан, 1978.—С. 131—132). Кызганычка каршы, чыганакта Шалым авылының урнашкан урыны әйтелми. Шулай да документ эчтәлегеннән аның Казансу тирәсендә булганлыгы аңлашыла. Югары Пошалымның 1619 елда да «бушлык» булганлыгын, ә Урта Пошалымның XVIII йөз ахырына караган бер чыганакта «Яңа Пошалым» буларак күрсәтелгәнен исәпкә алсак, язу кенәгәсендәге Шалым авылының хәзер Түбән Пошалым дип аталган авыл булу ихтималы күзалланыр. 1678 елга караган чыганакта да Түбән Пошалым ачыклагыч «түбән» сүзеннән башка, «Пошалым» дип кенә күрсәтелә (Россиянең борынгы документлар дәүләт архивы.—1209.—6453 нче кит.—536 б.). 1602—1603 елларга караган язу кенәгәсендәге Шалым авылы чыннан да хәзер Түбән Пошалым дип аталган авыл булса, соңгысының XVI йөзнең икенче яртысында да, 1552 нче елга кадәр, Казан ханлыгы чорында да булганлыгы шик тудырмый. Һәрхәлдә, үз вакытында XVI йөзнең икенче яртысына — XVII гасырга караган язу кенәгәләре мәгълүматларына нигезләнеп, тарихчы Е. И. Чернышев Пошалымны Казан ханлыгы авыллары исемлегенә кертә. Ләкин галим үзе төзегән исемлектәге Пошалымның шул атаманы хәзерге вакытта йөрткән өч авылның кайсысы булуын ачыклап тормый (Чернышев Е. И. Селения Казанского ханства: по писцовым книгам//Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья.—Казан, 1971.—С. 272—292).

Ничек кенә булмасын, 1678 елга инде өч Пошалым да аякка баскан, ясаклы кешеләрдән торган авыллар булалар. Аларда 13 тән алып 21 гә кадәр йорт исәпләнә (Россиянең борынгы документлар дәүләт архивы.—1209 ф.—6453 нче кит.—547—557 бб.). Бу авылларның Казан ханлыгы чорыннан бирле хәзерге Югары, Урта, Түбән Пошалым урнашкан җирләрдә икенче тапкыр тергезелгән авыллар булуы да ихтимал. Югары Пошалым, мәсәлән, безнең инануыбызча, ханлык чорында кечерәк бер авыл булса, соңрак «бушлыкка» әйләнә, аннары яңадан авыл итеп тергезелә.

XVII гасырда Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларының халкы башка җирдән күченеп килүчеләр исәбенә дә тулылана бара. Чыганаклардан күренгәнчә, Урта Пошалым

Югары, Түбән Пошалым авылларыннан соңырак, якынча XVII гасырның 30—50 нче елларында торгызылган булса кирәк. Җирле халыкта авылга Казан ханлыгы җимерелгәннән соң өч татар һәм бер чирмеш (мари) нигез салган, дигән фикер яшәп килә. Халык хәтере ул елларда Урта Пошалым авылына хәзерге Татар Кадрәгеннән (бу авылны икенче төрле Бизәр иле дип йөрткәннәр) кешеләр күчеп килүе турындагы хәбәрне дә саклаган. Урта Пошалымны хәзерге вакытта Пошалым елгачыгының уң кушылдыгы булган Бәчели елгачыгы кисеп үтә. Җирле халык фикеренчә бу елгачык авылга беренчеләрдән булып килеп утырган чирмеш (мари) исемен йөртә. Чыннан да, 1678 елга караган чыганак бу вакытта Урта Пошалым кешеләреннән кайберләренең икешәр исемгә ия булганнарын күрсәтә. Ул исемнәрнең беренчеләре мөселман татар исеме булса, икенчеләренең мари исемнәре булуы ихтимал (Россиянең борынгы документлар дәүләт архивы.—1209 ф.—6453 нче кит.). Урта Пошалымның кайбер өлкән кешеләре, үзләренең ата-бабалары сөйләвеннән чыгып, элекке заманнарда авылда «чирмеш зираты» (мари зираты) булганлыгын бәян итәләр. Аның урыны халык хәтерендә сакланмаган диярлек. Күрәсең, ул зират зур булмаган һәм берничә каберлектән торган. Ахыр чиктә авылның мари вәкилләрен күпчелек татарлар тулысынча татарлаштыралар. Бу процесс шактый тиз барган булса кирәк. Чөнки XVIII гасыр ахырына караган чыганакта Урта Пошалым саф татар авылы итеп күрсәтелә (Казан университеты каршындагы Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре.—XVIII т.—4—6 чыгарылыш.—257 б.). Шулай да, әле дә булса җирле халыкта мари чыгышлы булган кешеләр авылның Бәчели елгасы буендагы урамында яшиләр, дигән фикер яшәп килә.

Чыгышы белән Урта Пошалымнан булган Сираҗиев Габдрахман исемле Казан кешесенең бу юлларның авторына шундый бер хикәят сөйләгәне бар: «XIX гасыр ахырларында — XX гасыр башларында булса кирәк. Урта Пошалым авылының бер төркем ир-аты хуҗалык эшләре белән Казанга юл тоткан. Болар арасында мари токымыннан булган озын буйлы, зәңгәр күзле, җирән чәчле Ибени абзый да булган. Юлчыларга Казанга барышлый шәһәргә якын авылларның берсендә, хуҗасы мари булган бер йортта төн кунарга туры килгән. Мари йортында кичке ашны ашап утырганда шаянрак юлчыларның берсе хуҗадан: «Безнең кайсыбыз мари? Әйтә аласыңмы шуны?» — дип сорап куйган. Шунда, имеш, йорт хуҗасы һич тә икеләнмичә Ибени абзыйга төртеп күрсәткән».

Вакыт узу белән Югары, Урта, Түбән Пошалым авыллларында йорт һәм кеше саны үсә барган. Алай гына да түгел, XVII йөзнең 50 нче елларыннан да калмыйча Түбән Пошалым кешеләре авылдан 2 чакрым ераклыкта Күлтәс авылына нигез салалар (Күлтәс авылының борынгы тарихына багышланган язманы кара). 1781—1782 елларда Югары Пошалым авылында 58 ревизия җаны (бу санга авылның барлык олы кешесе керә) исәпләнгән. Авылның, бала-чагасы да кертеп, барлык халкы бу вакытта 116 кешегә (58х2—116) җиткән булуы мөмкин. Урта Пошалымда шушы ук чорда 49 ревизия җаны, чама белән барлыгы 98 кеше яшәгән. Түбән Пошалымда 60 ревизия җаны (барлыгы 120 кеше) исәпләнгән. Өч Пошалым халкы да, XVIII йөз ахырында дәүләт хезмәтендәге йомышлы кешеләрдән торган. Күрәсең, бу кешеләрнең бөтен хезмәте Россия дәүләте һәм армиясе ихтыяҗларында урман әзерләүгә, арба-чана ясауга, балта осталары ясый алган башка әйберләр эшләүгә кайтып калган. (Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре.—XVIII т.—4—6 чыгарылыш.—257 б.) Бу урында XVII гасырда һәм аңа кадәрге чорда Югары, Урта, Түбән Пошалым авыллары халкының, XVIII йөз ахырыннан аермалы буларак, ясаклы кешеләрдән торганын искәртеп үтик.

XVIII гасыр ахырында Югары Пошалым авылында 4 ревизия җаны (барлыгы 8 кеше) исәбендә православие диненә күчкән, ягъни чукынган татарларның яшәве игътибарны җәлеп итә. Дөрес, XIX гасыр ахырына караган чыганак буенча бу вакытта Югары Пошалым авылында андый кешеләр инде булмаган. Күрәсең, авылның керәшеннәре беренче мөмкинлек туу белән үк киредән мөселман диненә кайтканнар. Шул ук вакытта бу тарихи факт Рус дәүләтенең татарларны христианлаштыруга юнәлтелгән сәясәтенең Пошалым авылларын да читләтеп узмаганлыгын күрсәтә.

Шунысы кызык, XVIII—XIX гасырлардагы чыганаклар без караган өч Пошалымнан дистәләгән чакрым ераклыкта, Ашыт елгасының түбән агымында тагын бер Пошалым дигән авылны теркәгәннәр. И. А. Износковның «Казан өязенең кеше яшәгән урыннары исемлеге»ннән (Казан, 1885) күренгәнчә, XIX гасырда Зур Битаман авылы (Татарстанның хәзерге Биектау районы) ике өлештән торган. Авылның бер өлеше Зур Битаман дип аталса, Пошалым дигән елгачык буенда утырган икенче өлеше Пошалым Битаман дип йөртелгән. Соңгысын татарлар Пүчинкә Пошалым дип тә атаганнар («Пүчинкә» — русча «починок» сүзеннән). Ашыт

елгасының кушылдыгы булган Пошалым елгачыгы һәм аның буендагы пүчинкә XVIII гасыр ахырына караган икенче чыганакта да искә алыналар. (Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте хәбәрләре.—XVIII т.—4—6 чыгарылыш.—163 б.) Һичшиксез, Ашыт елгасының түбән агымындагы Пүчинкә Пошалым (Пошалым Битаман) авылы без караган өч Пошалым авылыннан соңрак барлыкка килгән. Аның «Пүчинкә» дигән исеме дә («пүчинкә» дип яңа барлыкка килгән авылларны атаганнар), анда яшәүче кеше санының чагыштырмача аз булуы да шуны күрсәтә. Шулай да, Ашытның түбән агымындагы Пүчинкә Пошалым авылына без караган өч Пошалым авылының берсеннән чыккан кешеләр нигез салмадымы икән? — дигән урынлы сорау туа. Кызганычка каршы, бу сорауга без әлегә җавап бирә алмыйбыз. Пүчинкә Пошалым (Битаман Пошалым) авылының хәзерге вакытка кадәр сакланмавын да искәртеп үтик.

XIX гасырда без караган өч Пошалым да җитәрлек дәрәҗәдә тиз үсәләр, 80 нче еллар башында Югары Пошалымда 95 йорт исәпләнә. Ул йортларда 231 ир-ат һәм 364 хатын-кыз яши. Авыл халкы Югары Пошалым авыл общинасын тәшкил иткән. 15 ир-ат акча эшләргә озак вакытка авылдан чит җирләргә чыгып китә торган булган. Югары Пошалымда агачтан арба-чана, чиләкләр ясау һөнәрчелеге зур үсеш алган. Моннан тыш авылда 3 кеше 60 умарта тоткан. Югары Пошалымның 2207 дисәтинә җире булып (1 дисәтинә якынча 1,1 га җир биләгән) авыл халкы аннан Урта Пошалым авылы кешеләре белән берлектә файдаланган.

Урта Пошалым авылында XIX гасырның 80 нче еллары башына 66 йорт исәпләнгән. Аларда 272 ир-ат һәм 255 хатын-кыз яшәгән. Авыл халкы Урта Пошалым авыл общинасын тәшкил иткән. 6 ир-ат озак вакытка эшләргә авылдан чит җирләргә чыгып китә торган булганнар. Авыл кешеләре чана ясау (5 кеше) һөнәрен үзләштергән. 6 кеше төрле балта эшләре белән көн күргән. 4 кеше 80 умарта тоткан. Шул ук чорда Түбән Пошалым авылында 50 йорт исәпләнә. Авылда Түбән Пошалым авыл общинасын тәшкил итүче 197 ир-ат, 199 хатын-кыз яшәгән. 10 ир-ат озак вакытка эшләргә читкә чыгып китә торган булган. Авыл кешеләре игенчелектән тыш балта эшләре (4 кеше), умартачылык (15 кеше, 100 умарта) белән шөгыльләнгәннәр. Пошалым елгачыгында су тегермәне булган. Авылның җирләре 982 дисәтинә тәшкил иткән. Түбән Пошалымда бу вакытта 2 ир-ат һәм 3 хатын-кыз исәбендә рус крестьяннары да яшәгән. Алар башка авыл кешеләре булып саналганнар һәм, күрәсең, авылда вакытлыча яшәгәннәр. Бу крестьяннар һөнәрчелек белән көн күргәннәр. Әлбәттә, өч Пошалым кешеләренең дә төп шөгыле игенчелек булган.

Авыл исемнәре	Авыллардагы халык исәбе												1909 елның 1 январена йорт исәбе	1908 елның 1 январена файдаланудагы җирләр (дисәтинәләрдә)	1908 елның 1 январена башка мәгълүматлар
	1856 елгы ревизия буенча			XIX гасырның 80 нче еллары башына			1897 елгы халык санын алу буенча			1908 елның 1 январена					
	и-а	х-к	барлыгы	и-а	х-к	барлыгы	и-а	х-к	барлыгы	и-а	х-к	барлыгы			
Югары Пошалым	250	255	505	351	364	715	415	428	843	484	479	963	156	1168,9	Мәчет,3 бакалея кибете
Урта Пошалым	184	185	369	272	255	527	275	290	565	299	294	593	106	1038,9	Мәчет, 3 вак-төяк белән сату итү кибете
Түбән Пошалым	145	143	288	197	199	396	194	194	388	224	237	461	73	982,2	Мәчет, 3 вак-төяк белән сату итү кибете, су тегермәне

Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларының XIX гасыр урталарыннан алып 1908 ел башына кадәр үсешен түбәндәге таблица рәвешендә күрсәтергә мөмкин:

Таблицадан күренгәнчә, XIX гасыр урталарыннан алып 1908 ел башына кадәр Югары, Урта, Түбән Пошалым авылларында халык саны өзлексез диярлек арта барган. Һәр авылда мәчет, вак-төяк көнкүреш кирәк-яраклары, азык-төлек сатыла торган кечкенә кибетләр (лавкалар) эшләп торган. Ә Түбән Пошалым авылында хәтта он тартырга су тегермәне дә булган. Шулай итеп, өч Пошалымда XX гасыр башына инде шактый ук күп кеше яшәгән, ныгыган-үскән авыллар булалар.

III. Тарих һәм шәхес

ШАГЫЙРЬНЕҢ БИШЕГЕ[1]

«Казан арты» дигән кечкенә бер регионга хәзерге Биектау, Дөбъяз, Әтнә, Кенәр, Арча, Балтач тирәсендәге авыллар керә. Урманлы, кечерәк кенә елгалы, чокыр-чакырлы, ташлы басулы җирләр, яланнар. Катнаш урманнар бер яктан мәһабәт наратлы Илләткә барып тоташса, икенче яктан Киров өлкәсе урманнарына, Вятка зонасына тоташа. Елгаларның иң зурысы, әлбәттә, Казанка яки Казан елгасы. Казан шәһәреннән 80 чакрым ераклыкта Чыпчык, Бимәр исемле рус авылларын тоташтырган урман эчендәге кечкенә генә тибешле ашъяулык кадәр бер чыганактан башлана. Моннан тыш Казан артында Кесмәс, Кече Му, Бирәзә, Шушма, Ия, Ашыт сулары бар, тыйнак кына, күбесе инде хәлсез генә инешләр, ләкин гыйфрит кебек куәтле машиналарга, елгаларның җелекләрен киптереп киселгән элеккеге урманнарга, көйгән әрәмәлекләргә карамыйча, ул еглгачыклар һаман агалар, әле заманга бирешмичә, яз көннәрендә «юл өзеге» дигән дәһшәтләр ясап куялар, җәйнең иң коры вакытында да, менә бетәм-кибәм ди-ди, һаман кыштырдап, челтерәп, чурлап алга үрмәлиләр, әйтерсең, кырыс Каспий дулкыннарына кушылып Иран ярларына бәрелеп агарга, аннан күккә пар булып күтәрелеп, океаннар өстеннән узып туган якка яңадан кайтырга ашыгалар...

Казан артының этнографик ягы чуар: марилар, удмуртлар, руслар белән аралашып яшәү эзсез калмаган: җыйнак кына гәүдәле, кечкенә күзле, кызыл чәчле, кызыл сипкелле татарлар очрый икән — гаҗәп түгел, татар белән мари гомере буе ил-умач килеп яшәгән бу төбәктә. Балтач — Кукмара

---

[1] Мәкаләнең журнал варианты: Мөхәммәт Мәһдиев. Шагыйрьнең бишеге // Казан утлары.—1986.— № 6.—126—145 б.

ягында сап-сары чәчле, зәңгәр күзле, эре яңаклы, таза сөякле татарлар очрый икән — гаҗәп түгел, удмурт белән татар катнашкан авыллар Казан артында гадәти хәл. Руслары да шулай: үз телләрен онытып гел татарча сөйләшеп йөргән, татар кызына өйләнгән, тагын әллә ничек, әллә ничек туганлашып таралышып беткән руслар байтак анда. Әнә шул бай калейдоскоп эчендә татарның әдәби теле сакланган: Казан арты татарлары турында фикер йөртеп, Тукай болай ди: «Милли әдәбиятымыз фәкать шулар телендә, шулар рухында булуын телим» (С. Сүнчәләйгә хаты, 1910, 9 ноябрь).

Шулай да — ни өчен Казан арты? Бу төшенчә XVI гасырдагы мәгълүм тарихи вакыйгалар нигезендә туган булса кирәк. Мәскәү — Зөя ягыннан караганда Арча — Әтнә — Дөбъяз төбәге, чыннан да, Казанның арты бит һәм ул шулай тарихка кереп киткән дә. Тукай үзе бу төшенчәне бик яратып кулланган, мәкаләләрендә, очеркларында, хатларында ул аны ниндидер бер сагышлы җылылык белән, кайвакытта халыкның авыр тормышына газаплы сыкрану, ә кайчакта сатирик интонацияләрдә куллана. XX гасыр башында Казан артының мәдәният-мәгърифәт ягыннан бик нык артта калуына сыкранып шагыйрь болай яза:

Бер борыл да, и Казан, син бу Казан артын кара:
Нур чәчәсең бар өязгә, үз өязең кап-кара.

(«Казан вә Казан арты», *1912.*)

Әмма тарихка эчкәрәк керик әле. Казан арты халкы кемнәрдән, ничек формалашкан? Казан арты — Казан губернасында җан башына имана җиренең күләме ягыннан иң фәкыйрь регион. Анда — урман, ташлы басу, кызыл балчык, каниарлы кырлар. Тарихи хезмәтләрдә Казан артында Болгар чорында ук татар авыллары булганлыгы мәгълүм. Моның шулай икәнлеген бүгенге ономастика фәне дә раслый.

Казан ханлыгы чорында бу төбәктә байтак татар феодаллары яшәгәнлеге мәгълүм. Совет чоры галиме Гали Рәхим, мәсәлән, Зур Сәрдә, Кече Әтнә, Иске Мәңгәр, Өҗем, Рус Урматы һ. б. авылларда 1494—1548 елларга караган кабер ташларын искә ала. Ерганаклар, кызыл-сары ярлар, вак ташлы инешләр. XVI гасырның икенче яртысында Казан һәм Казан тирәсендәге бистәләрдән бик күп халык әнә шул яктагы урман аланнарына китеп урнаша, элеккеге шә-

һәр һөнәрчеләре, сәүдәгәрләре, укымышлылары үзләре өчен яңа, әмма ерак бабалары өчен таныш булган игенчелек һөнәрен үзләштерергә керешәләр. Игенчелек белән рәттән — урман эше, йорт-җир салу, каралты-кура торгызу, аучылык, умартачылык эшенә тотыналар. Урман яндыру (ышна әрчү), төп чыгару, иген басуы «ясау»... «Шәһәрдә яшәгән татар халкының авылларга күчүенең авыл өчен зур әһәмияте булган. Үз һөнәрләре белән шөгыльләнүләрен дәвам итеп, татарлар анда да һәртөрле производстволар булдырганнар: күн иләгәннәр, тун теккәннәр, итек баскаңнар, агач эшкәрткәннәр, слесарьлык һәм ювелирлык эшләре белән шөгыльләнгәннәр»[1]. Казан артына күчеп килгән бу халык мари, удмурт халкы белән тиз аралаша, ике арада дини-милли каршылыклар бөтенләй үк булмый кала. Казан артындагы байтак татар авылын халык әле дә булса «ар» авылы дип йөртә («ар» дип удмуртларны атап йөрткәннәр) һәм аларның кайчандыр удмурт булганнарын бүгенге сөйләшләрендәге фонетик яңгыраш әле дә сиздереп тора. Казаннан һәм шәһәр тирәсе бистәләреннән күчеп килгән татар халкы еллар узу белән Казан артында мануфактуралар — «фабрикалар»га нигез сала. Тар гына — өч ягыннан урман белән кысылган Казан арты. Арчадан көнчыгышка китсәң — удмурт урманнары, төньякка китсәң — Балтач — Уржум чыршылары, төньяк-көнбатышка егермешәр-утызар метр биеклектәге нарат урманы — Илләт ягы. Әмма шул Казан белән урман кыскан тар җирдә татарлар (өлешчә рус алпавытлары һәм купецлары) искиткеч зур өлгерлек белән промышленность тудыралар. Кышкарда, Бәрәскәдә, Орнашбашта, Орыда 1775—1798 еллар эчендә Муса Усманов, Корбан Борнаев, Рәхим һәм Хәмзә Мамышевлар, Хәмзә Сәитовларның комач мануфактуралары, Алатта аракы заводы (рус алпавыты Шувалов), бакыр эретү (1747) заводы эшли башлый. Кайбер өлгерләр авылдан кире шәһәргә — ата-бабалары чыккан Казанга да үрмәлиләр. Ибраһим Йосыповның, мәсәлән, (Кишет авылы фабриканты) Кишеттә дә, Казанда да комач эшләү фабрикалары була[2]. Тире эшкәртү,

---

[1] Татарстан АССР тарихы.— Казан, 1970, 103—104 бб.

[2] Алишев С. Х. Татары Среднего Поволжья в Пугачевском восстании.— Казань, 1973.— С. 206—208.

сабын кайнату мануфактуралары нигездә йомышлы татарлар кулында булган. Алар Кышкар, Бәрәскә, Орнашбаш, Оры, Ашыт авылларында урнашкан булганнар.

Элеккеге шәһәр халкының токымы монда сәүдә-промышленностьны җәелдереп кенә калмаган. Казан артына үз холкын, үз мәдәниятен, гадәтен, иҗатын да сеңдерә башлаган. Җир эшкәртә, иген чәчә, урман кисә, умарта, терлектуар асрый башлаган элеккеге шәһәр һәм бистә халкы җирле крестьяннарның авыз иҗатына шәһәр мәдәниятен үрә башлаган. Нәтиҗәдә авыл халкының авыз иҗаты белән шәһәр халкының авыз иҗаты бергә кушылып бер-берсен баету нигезендә фольклорның аерым бер катлавы — ике мәдәниятнең синтезы туган. Казан артының җырга, мәкальәйтемгә, сынамышларга, әкиятләргә аеруча бай булуы әнә шуннан килә. Кызганычка каршы, заманында Казан артының үз Каюм Насыйрие тумый калган, әмма Тукай китапларына кергән җырларның, әкият, мәкаль-әйтемнәр, афоризмнарның барысы да диярлек — Казан артыныкы.

Казан арты илебез тарихындагы зур вакыйгаларның шаһиты. Пугачев гаскәренең зур отрядлары 1773 елда Арча - Балтач, Арча — Казан юлларын үз кулларында тоталар, монда Мәсгут Назиров, Габделфаикъ Усманов, Гомәр Ибраев отрядлары йөри. Казан артының бик күп авыллары — Югары Сәрдә, Алат, Кечкенә Аты, Аты, Чыршы, Югары Арбаш, Түбән Арбаш, Субаш, Шәләнгер, Чүриле, Төбәк Чокырча, Чокырча, Корайбан, Югары Курса, Түбән Курса, Иске Му, Ташкичү, Мөндәш, Божа, Кишмәт, Бөреле, Шәпше, Көек, Кырлай авыллары баш күтәрә. Минем өчен ачыш: мин туган Гөберчәк авылы да (ул вакыттагы исеме Кечкенә Му) Пугачев восстаниесендә катнашкан, баш күтәргән. Менә юаш кына минем авылдашлар! Пугачев гаскәренең бер отряды Кышкар авылына да килеп чыга. Гаскәриләр Кышкарның иң зур баен талыйлар, мөлкәтен алып бетерәләр. Бу хәбәрне ишеткән Кишет авылы фабриканты Ибраһим Йосыпов тиз генә патша армиясенә барып хезмәткә керә: Пугачев гаскәре җиңелгәч патша хөкүмәте аңа салымсыз сәүдә итү хокукы бирә.

Тарих Казан артын сыйнфый сизгерлек хисе белән тәрбияли. Хезмәт халкының сыйнфый сизгерлеге асылда патриотизмга алып килә инде ул. 1812 елда Наполеон гаскәрләре Россиягә басып кергәч, Арча чиркәвендә бу вакыйгага багыш-

лап дога уку оештырыла. Чиркәүнең пономаре Александр Ильин шул вакытта, программада каралмаганча чыгыш ясый: «Җәмәгать,—ди ул,—изге җиребезгә дошман бәреп кергән. Безнең бурыч—сәламәт булганнарыбызга сугышка китәргә, монда калганнарыбызга сугышта җиңү өчен ярдәм күрсәтергә...»

Арчада ополченецларның зур отряды төзелеп Казанга килә.

Җире аз якта халык һөнәрле була. Электән дә һөнәр иясе булган, ил-җир күреп йөргән, сәүдә иткән бу халык Казан артында сәүдәне җанландырып җибәрә. Сәүдә үзәге—аерым регионнар өчен—базар. Казан артында акрынлап зур-зур базарлар оеша. Боларның иң мәшһүре—Чепья һәм Әтнә базарлары. Аннан кала Арча, Апаз, Күлле-Киме, Балтач, Иске Ашыт, Кенәр, Рус Алаты, Мәмдәл базарлары. Һөнәрчелекнең үсүенә базарның йогынтысы зур була, ләкин шул ук вакытта базарның үсүендә һөнәрчелек үзе зур роль уйный. Сәүдәгәрлек исә һаман киңәя, үзенә зур юллар таләп итә башлый. Казан арты крестьяннары катлавыннан акрынлап ерак юлларга йөрүче сәүдәгәрләр, Казан фабрикантларының товарларын «оптом» сатып алып, авылларда таратып йөрүчеләр барлыкка килә. Гасырлар узу белән, авылдан җир азлыкка чыдый алмыйча чыгып киткән крестьяннарның саны арта. Казан арты крестьяннары нигездә өч якка миграция кичерәләр: беренчесе Казан шәһәренә—ялчылыкка, хезмәтчелеккә.

Түбән Сәрдә һәм Дөбъяз ягы кешеләре, мәсәлән, Казанда «барабыз»лыкта хезмәт иткәннәр, ат белән кибетләрдә эшләгәннәр. Бу традиция (ат җигеп юл йөрү) Казан артында зур абруй эше иде, әле 1950 елларда да кышын ат җигеп Арча базарына килгәндә Сәрдә, Ашабаш, Штерә, Орнашбаш ирләре билне кызыл комач белән буып, аның очларын ике якка асылындырып куялар һәм билендә кызыл комач путасы булмаган ирне ат җигүчегә исәпләп тә тормыйлар иде...

Шәһәрдә эшләп йөргәннәрнең бер өлеше анда утырып ук калган. Алардан ахырдан приказчиклар (кибетчеләр), сәүдәгәрләр, XIX гасыр ахырына таба эшчеләр сыйныфы формалаша. Казан арты крестьяннарының җир азлыктан җәфа чигеп, бу якны ташлап хәзерге көньяк-көнбатыш Башкортстан җирләренә күчеп утыруларын Д. Рамазанова ар-

хив документлары белән расладыˡ[1]. Миграциянең тагын бер тармагы — Уральск, Троицк, Оренбург якларына. Монда күчеп килүчеләрнең бер төркеме — тегүчеләр, төрле һөнәр ияләре, икенче бер төркеме сәүдәгәрләрне тәшкил итә, өченче бер төркеменнән шулай ук эшчеләр сыйныфы формалаша. Ни өчен Уральск, Троицк, Оренбург? Чөнки алар — Урта Азия, казах-кыргыз далалары белән эчке Россия базарларын тоташтыручы олы юл өстендә капка. Казах-кыргыз далаларыннан Россия фабрикаларына чимал җыю, озату өчен иң кулай кешеләр татарлар булып чыга (диннең берлеге, телләрнең кардәшлеге, сәүдә юлында йөргәнлектән шомарган булу зур роль уйный, әлбәттә) һәм Казан артының җирсез халкы бик күпләп шул якка күчә. Игътибар итик: Кырлайдан Габдулланы алып китүче Бәдри солдат 1898 елда ук Уральск шәһәренә күчкән һәм ул бер дә изелгән татар түгел, Казанда бары тик кунакханәгә генә туктала. Сәгъди абзый белән сөйләшкәненә игътибар итегез: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга...» Ятим малайның киләчәк язмышын хәл итүгә әнә шулай дәүләт теле һәм элементар юриспруденция катнашкан. Юл йөргән кеше андыйның рәтен белә инде ул... Хәер, Алты-биш Сапый да Уральск шәһәреннән килгәч Казанда номерга гына төшә. Тукайның бала вакытта ук Уральск шәһәренә барып чыгуы, анда туганнары яшәве, бик күп якташларын табуы — бер дә очраклы түгел. (Мәсәлән, Уральскидагы «Казан» кунакханәсендә уздырылган кичәдә Тукай үзенең «Теләнче» шигырен укый. Шунда ук сәхнәгә хәерче киеменә киендереп Казан арты Иске Кишет авылы егете Хәкимҗан Йосыповны алып чыга.) Уральскида Казан арты — Әтнә, Бирәзә, Кишет, Өчиле, Чиканас, Гөберчәк егетләре, тегүчеләр, кәсепчеләр байтак булган. Әмма, монысы инде аның — яңа тарих.

Сәүдә үзәге Әтнә-Мәңгәр тирәсендә акрынлап акча тупланган. Сәүдә эшен йөртү, алып бару өчен гыйлем-мәгърифәт кирәк булган. Сәүдә, базарлар үсү белән бергә Казан артында мәдрәсәләр ачыла башлаган. Арадан иң зурлары — Кышкар, Курса мәдрәсәләре булган. Кечерәкләр-

---

[1] Рамазанова Д. Б. Формирование татарских говоров юго-западной Башкирии.— Казань, 1984.

дән — Ташкичү, Казиле һ. б. мәдрәсәләр. Әйтергә кирәк, бу мәдрәсәләрдә укыту системасы һич тә без күз алдына китереп өйрәнгән схоластикадан гына тормаган. Мәсәлән, бу уку йортларында география, астрономия, хисап буенча заманына күрә гыйлем бирелгән. Сәүдә эше белән көн иткән «ак» халыкка бик тә кирәкле мәгълүматлар бу. Мәдрәсәләрне сәүдәгәр байлар тоткан. Болар, әлбәттә инде, шәһәрчә яшәргә тырышканнар, затлы йортлар салдырганнар (Мәңгәр авылындагы архитектура үрнәкләре), тәрәзә капкачларын элеккеге Казан шәһәрендәге традицияләр үрнәгендә челтәрләп бизәгәннәр, авыл җиренә шәһәр мәдәниятен керткәннәр. Архитектурадагы бу матур традицияләр әле дә булса Балтач, Арча, Биектау, Кенәр якларында дәвам итә, тәрәзәгә наличникларының күп гасырлык орнаментлары Казан артына, һичшиксез, Казан шәһәрләреннән күчеп килгән.

Мәдрәсә акча булган җирдә генә яши ала. Мәңгәр-Әтнә байлары шулай Кышкарда, Иске Масра, Курса сәүдәгәрләре Югары Курсада заманына күрә зур уку йортлары салып куялар. Казан артында шәһәр традициясе буенча укымышлылык, китап язу, гыйлем эстәү дәвам итә. Әйтик, Ш. Мәрҗанинең әтисе Баһаветдин — Казан артының мәктәп-мәдрәсәләрендә күп төрле фәннәр укыткан, гыйлемлеге белән мәшһүр кеше, Урта Азиядәге галимнәр белән арадаш булган. Шиһабетдиннең әнисе ягыннан бабасы Габденнасыйр — Ашыт авылының зур укымышлысы. Оныгы Шиһабетдиннең формалашуында аның роле зур булган. Әтисе ягыннан бабасы Сөбхан — гарәпчә һәм фарсыча зур мәгълүматлы кеше, үз гомерендә берничә китап күчереп язган, оныгының тарихчы булып китүенә беренче этәреч ясаган. Казан артының Ташкичү һәм Япанчы исемле кечкенә авылларында Шиһабетдиннең ата-бабасының зур-зур китапханәләре булган. Ә авыл җирендә китапханә акрын хәрәкәт итүче «шартлаткыч» кебек инде ул: ул — гасырлар өчен эшли, акрын, эзлекле, әмма нәтиҗәле эшли. Мәңгәрләр, Ташкичүләр, Япанчылар шуның өстенә тагын Урта Азия белән зур сәүдә алып баралар. Казан артында кибетләр тоталар. Шиһабетдинне да Бохарага Мәңгәр сәүдәгәрләре алып китә: 1838 елда, әтисе Ташкичүдән Мәңгәргә китереп Мохтар бәк Мөхәррәм (бәк!) исемле сәүдәгәрнең кәрванына урнаштырып гыйлем эстәргә Урта Азиягә озата.

Шунысы характерлы, Казан арты сәүдәгәре кая гына барып чыкмасын — эше рәтләнеп китүгә, шул төбәктә мәдрәсә сала. Мәдрәсә сала, үзе белән китап, кулъязма алып бара, төрки халыклары арасында шуны тарата. Арадан дин китабы да байтак булгандыр, әмма тарихта алары түгел, ә чын әдәбият кына файдалы эз калдыра. Әйтик, «Кыйссаи Йосыф» әсәренең күп кенә вариантлары Казан артыннан табылган. Әмма Казан артында күчерелгән бу вариантлар читкә дә китеп таралганнар. Мәсәлән, поэманың Олы Мәңгәрдә күчереп язылган нөсхәләре ерак-еракларда табылган. Әйтик, Әстерханда. Димәк, Казан арты сәүдәгәре белән килгән. Инде бастыручыларны әйткән дә юк: гел Казан арты. Рәхмәй тылмач беренче басмасын дөньяга чыгарса, Түбән Курса авылы крестьяны (әлбәттә, сәүдәгәр инде) Шәмсетдин Хөсәенов 1885 елда университет басмаханәсендә шуны ук яңадан бастыра һәм аннан соң да халыкка кирәкле күп китаплар чыгара. Казан арты кешеләренең университет басмаханәсеннән шулай файдаланулары бик гыйбрәтле. Хөсәеновларда «Йосыф китабы»ның кулъязмасы да сакланган булган.

Бик кызыклы күренеш: минем туган авылым Гөберчәк — XIX гасырда Казан артының иң кара авылларыннан берсе булган. Әмма 1961 елда мин анда «Кыйссаи Йосыф»ның бер кулъязмасын таптым. Бу хәзер фәнни әйләнешкә кереп китте (37 сан белән). Каян килгән? — дип егерме елдан соң кабат кызыксынам — Шиһабетдин Мәрҗани авылы Ташкичүдән икән. Безнең авылның революциягә кадәрге мулласы Хәким хәзрәт Ташкичүдә туып, Кышкарда укып, монда китерелгән булган икән. Кулъязманың юлы әнә шулай ачыкланды. Тукай әнә шул — мәшһүр поэманың бик күп таралган төбәгендә балалык елларының бер өлешен уздыра. Бу, әлбәттә, тәэсирсез калмый. Аның беренче шигырьләре шул үлчәүдә, шул матрицада язылган, Тукай бу поэмадагы ритм, рифманы үзенчә яңарта, заманча яңгырата. Үлчәү генә түгел, фикер йөртү формасын да алган.

Йусеф әйдүр: «Кәнганда дормыш идүм,
Бер вакыт-дә ул мәками күрмеш идем,
Кечеклекдә анда тәлим тормыш идем —
Бу тели — бән үгрәндем» — дәйүр имди.

Карале, Тукай искә төште бит: мин бераз торган идем, җирне аз-маз чәчкәләп урган идем...

Казан артының китапка, кульязмага байлыгын раслаучы тагын бер дәлил бар: 1934 елда тарихчы галим В. Зәбиров (Тукайның апасы Газизә улы) татар кульязмалары җыю буенча Тарих комиссиясе, Тарих — археография институты һәм Көнчыгышны өйрәнү институты тарафыннан Татарстанда оештырылган археографик экспедициягә җитәкчелек итә. Арча, Биектау, Балтач районнарында һәм Казанда эшләгән бу экспедиция тарафыннан «1203 кульязма, бер мең данә чамасы документаль чыганаклар, 1859 басма китап җыела»[1]. Бу бит Казан артының гасырлар буе тупланган рухи байлыгы!

Сүз — мәдрәсә салу турында иде... Татарда зур, борынгы нәсел Яушевлар булган. Болар дәүләткүләм сәүдә эше йөрткәннәр... Троицк төбәгендәге Яушевлар XX гасыр башында үзләренең мәдрәсәсенә тарихта беренче буларак Земство акчасын алуга ирешү белән билгеле. Әмма Яушевларның да нигез башы — Казан артыннан. Сәүдә эше белән Кызылъяр шәһәренә (Петропавловск — Казахстанда) барып чыккан Габделбари Яушев — Казан арты Күшәр кешесе. Кышкар төбәгеннән. Ул Кызылъяр шәһәрендә мәдрәсә салдыра, ләкин үз малае Габделваһапны ул, үсеп җиткәч, гыйлем эстәр өчен туган ягына — Кышкар мәдрәсәсенә җибәрә. Иптәш итеп Минзәлә ягы Кормаш авылыннан сәүдә эше белән килеп төпләнгән Мөхәммәтзарифның Кызылъяр мәдрәсәсендә укып яткан Әхмәт Уразаев дигән улын ияртә. Әхмәт белән Габделваһап Кышкар мәдрәсәсендә 6—7 ел чамасы укып, җәйләрен Күшәрдә — Габделваһапның туганнары Галибшә Яушевларда уздыралар. Атаклы «Таһир — Зөһрә»не шулай итеп Күшәр авылында торып Минзәлә тумасы Әхмәт Уразаев-Кормаши иҗат иткән. Шунда ук «Бүз егет» тә язылган, Күшәр-Кышкар тирәсендә бу ике поэманың икесен дә кулдан-кулга йөртеп укыганнар, күчереп язганнар. Тукайда «Таһир — Зөһрә» турында: «Минем гөманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер», — диелә.

---

[1] Миңнуллин Ж. Археограф Вәли Зәбиров. // Казан утлары.—1983.—№ 10.—186 б.

Мәдрәсә салу дигәннән... Халкыбызга бик зур укымышлы кешеләр әзерләшкән (Г. Ибраһимов, Ш. Бабич, Сәйфи-Кудаш һ. б.). «Галия» мәдрәсәсен салуга беренче акчаны шулай ук Казан арты сәүдәгәре, Битаман кешесе Садри Назиров биргән, ул кеше әле 1925 елда гына Казан шәһәрендә үлгән...

Татар халкына царизм шартларында белем учаклары ачу мәсьәләсендә кайбер меценатларның файдалы хезмәтен һич тә инкяр итәргә ярамый. Андрей Вознесенский болай ди: «Как обязано наше искусство меценатам. Художник хрупок. В отношениях с миром ему нужна поддержка...»

Казан арты, гомумән, хәтергә, тарихка, кулъязма китапларга бай булган. Олы Мәңгәр авылының «отставкада»гы мулласы Шаһиәхмәт Мөхәммәдиев, мәсәлән, 1878 елгы крестьян восстаниесендә катнашкан һәм үзе күргән канлы вакыйгаларны «Мирьат-эль вакыйгать» исемле («Булган хәлләрнең көзгесе») кулъязма китапта яктырткан. Бу кулъязма хәзер кайда икән?

Казан арты мәдрәсәләре акрынлап нәтиҗә бирә башлый. XIX гасырның беренче чирегендә Габденнасыйр Курсави (1776—1818) Бохара схоластикасына беренче һөҗүмне ясый — кыска гына гомерендә ул (42 яшь) үз авылларында зур мәдрәсә ачуга ирешә. «Туры юлга өндәү» исемле китап яза, кыскасы, мөселман-татарлар дөньясын шау иттерә. Курсавиның үз заманында Казан һәм Казан арты кадимчеләрен ничек тетрәтеп торуы турында Мәрҗани «Мөстафадел-әхбар» исемле хезмәтендә искә ала: «Мулла Әбүнасыйр Бохара галимнәренең һәммәсен бер тишеккә тыгып китте... Казан шәһәрендә Апанай Хафиз әүладыннан улан байлардан кияүләренә килер иде, ул гасырында улан Казан голямасы дәгъвәт иделдектә мәҗлесеннән качарлар икән. Бервакыт Мусабай мулла Фазылны иртә белән чәйгә алмага җибәреп, кыраеп килеп җиддекдә хадимдән: кунак, я мәҗлес бармы, дип сорагач, юк, Курса мулласы гына бар, дип җавап биргәч, бәла тәүкыйф (кулга алынган кебек — *М. М.*) җәяүләп Яңа Бистәгә кайтып китмеш... мулла Җамалетдин әл-Сабавиның: һай шул нәрсәне Бохарада алып кына куймадылар лабаса, дидекене нәкыль кылыр иде»[1].

---

[1] Мәрҗани Ш. Мөстафадел-әхбар.—Казан, 1900.—2 нче жилд.—169—170 б.

Курсави мәдрәсәсенең даны еракларга тарала, болар — Кышкар һәм Курса — урманлы, ташлы басулы Казан артында ике йолдыз булып калкалар. Әдәбият тарихында Һибәтулла Салихов дип йөртелгән шагыйрь дә (1794—1867) Оренбург тирәсендәге гыйлемгә генә риза булмыйча Курса мәдрәсәсенә (XIX гасырның 20 еллары), аннан Кышкарга килеп белем күтәрә. Аның мәшһүр шигыре «Тәндә җаным», ихтимал, Курса-Кышкар белем учакларын күргәч язылгандыр:

Тәндә җаным ничә көн миһман иткәндер, белмәдем,
Үтте гомрем, барысы хосран икәндер, белмәдем.

(Миһман — кунак; хосран — үкенеч.)

Казан артында әле Дөбъяз төбәге дә бар. Кайбер егетләр Кышкар, Курсага гына риза булмыйлар (шул ук Шиһабетдин Мәрҗани), белем эзләп әллә кайларга чыгып китәләр: әйтик, Бәрәзә егете Хәмзә бине Мөхәммәт (Хәмзә Бәрәзәви 1775—1827) Бохарада гыйлем алып, аңа гына риза булмыйча, Кабулга китә. Кабулга китеп гыйлем эстәүче бер ул гына түгел: 1796 елда Кабул мәдрәсәләрендә, китапханәләрендә Утыз Имәни дә гыйлем өсти. Хәмзә Бәрәзәви исә, Урта Азия, Кабулда йолдызлар гыйлемен өйрәнә, халык арасында «Хәмзә мөнәҗҗим» («Йолдызларны белүче») дип шөһрәт ала. Бәрәзәгә кайта, әмма үзенең астрономия буенча белеменә ихтыяҗ күрми, шуңа күрә Казан Бохара юлында сәүдә эшенә керешә. Астрономия буенча белгечлеген исә үзенең туганы — гыйлемгә хирeслеге булган Фәйзулла бине Мортазага (1781—1851) тапшыра, өйрәтә. Фәйзулла — Арча юлы өстендәге Мөндеш авылы егете. Агасы Хәмзәдән астрономия генә түгел, үз заманының дәрәҗәсенчә югары математиканы да өйрәнгән була. Курса мәдрәсәсенә килеп (ике авыл арасы 10—12 чакрым гына) Курсави лекцияләрен тыңлый, бераздан үзе шунда укытучы булып кала, дәрес әйтә. Димәк, Курса мәдрәсәсендә астрономия, югары математика (риязият) буенча заман таләбенчә мәгълүмат бирелгән. Фәйзулланың үзе эшләгән астролябиясе (почмаклар, градуслар белән үлчәп, йолдызларны табу коралы — секстант) Мәрҗанинең эш бүлмәсендә саклангaн. Фәйзулла мөнәҗҗим үзе ясаган кораллар белән эш итеп ай

һәм кояш тотылышы, һава хәлләре үзгәреше турында алдан хәбәр бирергә өйрәнә, табель-календарь эшли, сәгатьләр поясын яза. Үзенә алмаш та хәзерли. Галимлекнең иң күркәм бер сыйфаты инде ул. Лаеш өязе Кече Әшнәк авылыннан Курсага укырга килгән егет Гатаулла — еллар буе Фәйзулла мөнәҗҗимнән математика, астрономия өйрәнә һәм Курса мәдрәсәсендә үзе дә озак кына укыта (1830—1840 еллар тирәсе — Г. Әшнәки). Йолдыз гыйлеме дигәннән, бик кызыклы күренеш: Казан артының урман эчендәге иң караңгы бер авылында — Күлтәстә яшәгән мулла Шәмсетдин Күлтәси (1856—1930); йолдызлар, кояш, ай хәрәкәте турында китап язган. «Хикмәте җәдидә» исемле ул китап Казанда 1899 елда басылып чыккан һәм университет профессоры Н. Ф. Катановның мактаулы рецензиясенә лаек булган. Ш. Күлтәсинең фәлсәфә, мәгърифәт, гыйлемлек турында байтак китабы Казанда басылган. Болар: «Һәйәте җәдидә» (1896), «Мофассал һәйәте җәдидә» (1900), «Хәлемездән шикаять» (1903) һәм «Мәктәп баласы яхуд Сәхилә әби» (1909).

Казан артының татар халкын астрономиягә өйрәтүе, һәрхәлдә, кызык күренеш. Моңа сәбәп ни? XIX йөз башында Казанда мәшһүр университет ачылуның игелекле йогынтысымы? Курсави, Мәрҗаниләрнең татар акылын шәригать кысаларыннан азат итү буенча эшләгән эшләренең нәтиҗәсеме? Ике сәбәпнең (бәлки башка бик күп төрле) нәтиҗәсеме?

Казан артындагы сәүдәгәрлек, юл йөрү белән бәйле хезмәтләр фәннең башка өлкәләренә дә ихтыяҗ тудыралар. XIX гасыр башында Әтнәдә туган Габделхәким Габделрәшид углы Дөбъяз төбәге Мәмсәдә башлангыч белемне алгач, Казанда Күл буе мәдрәсәсендә укый: аннан Казан артыннан күчеп киткән халыкның балаларын укыту өчен Троицкига килеп, шундагы мәдрәсәдә дәрес әйтә. 1861 елда ул татарча география картасын бастыра, ул картада Европа, Азия кыйтгалары (сәүдәгәр татарлар өчен әлегә Америка, Африка, Австралия кирәк түгел) төшерелгән була.

Шунысы кызык, Кышкар, Курса мәдрәсәләрендә белем алганнарның бер төрлесе Казан, Троицк, Оренбург якларына китә. Татар мәгърифәтчесе, И. А. Крылов мәсәлләрен татарчага тәрҗемә иткән, әдәп-әхлак буенча күп кенә хезмәтләр язган Таип Яхин да Кышкар шәкерте. Кышкарда укуны тәмамлагач ул Казанга килеп белемен күтәрә һәм

Татарская учительская школада ислам дине курсын укыта башлый (Ш. Мәрҗанидән соң). Әмма Кышкар тәрбиясе үзенекен эшләгән була инде: 1910 елның 22 мартында Таип карт үлгәч матбугатта мондый хәбәр күренә: Таип абзый юаш, вәкарьле кеше иде. Мәктәптә Таип мулла мөгаллим булганнан бирле шәкертләр дин гыйльменә бер көлке, әллә нинди аңлануы мөмкин булмаган сүзләрне бикләт дип кенә карый башлаганнар иде. «Таип абзый имтихан алдында шәкертләргә бары сораган бер нәрсәгә тукталмыйча «лыбыр-лыбыр» җавап бирүләрен үтенә торган булган». Шулай итеп, хәйләне аңлаган шәкерт имтихан билетында чыккан «тәбарәк» урынына «Ясин» сүрәсен укып бирә икән, Таип карт моңа әйбер әйтмәгән: имтихан вакытында утырып торган русларга барыбер ич».

Кышкар әнә шулай тәрбияләгән.

Кышкарда Тукайның әтисе дә укыган. «Минем атам... 14—15 яшьләрендә Кышкар мәдрәсәсенә китеп, анда хәтме көтеб кыйларга (укып тәмам итәргә.— *М. М.*) гадәттә ничә сәнә кирәк булган булса шулкадәр тотып, карт атасы тере вакытта ук авылымыз Кушлавычка кайтып, мулла булмыштыр» («Исемдә калганнар»). Гомумән, Тукайның биографиясе, тегеләйме-болаймы Кышкарга килә дә бәйләнә, килә дә бәйләнә. Аның Кырлайдагы остазы Фәтхерахман Гобәев — Кышкар шәкерте. Ул — Габдулланың атасы белән бергә укыган. Уральск шәһәренә барып төшеп «Мотыйгыя» мәдрәсәсенә керсә — мәдрәсә хуҗасы Мотыйгулла Төхфәтуллин — Кышкар шәкерте. Яхшымы — яманмы, Тукай тирәсендә гел кышкарлылар. Анда төрле кеше булган, алдарак бу турыда да әйтелер...

Мәҗит Гафури, яшьлегендә күп мәдрәсә күргән кеше, «Беренче озын юл җиһанда — Себер тимер юлы» дигән шигырендә, бераз үкенгән сыман, кече күңелләләнеп болай яза:

Укыган мәктәбем Троицкида.
Баралмадык Бохара һәм Кышкар, Казан.

Ул вакытта мәгърифәтче шагыйрь өчен, димәк, Кышкар мәдрәсәсе абруйлы уку йортларыннан исәпләнгән.

Казан арты тагын кемнәрне «очырган»? Бик күпләрне. Заманында шәһәр һәм шәҗәр тирәсеннән күчеп килгән халык җир, крестьян хезмәте белән физик һәм рухи яктан баеп потенциаль энергия туплаган. Күп гасырлар буе тупланган

бу энергия XIX гасырда матур нәтиҗәләр биргән. Арадан берсе — Дөбъяз төбәге егете Мөхәммәтгали Мәхмүдев (1824—1891) Мәмдәл волосте Сөләнгер авылында крестьян гаиләсендә туып, Сөләнгердә һәм Казан мәдрәсәсендә белем алып, мәшһүр Казан университетында укытучы булып эшли башлый. XIX гасырда — крестьян малае университетта укыта! Лобачевскийлар, Готвальдлар эшләгән гыйлем пайтәхетендә Казан арты егете Гали Мәхмүдев гарәп, фарсы, төрек телләрен өйрәнүче студентларга каллиграфия укыта, дәреслекләр төзи («Татар телен өйрәнүгә практик кулланма»). Бу китап турында үзәк рус матбугатында уңай рецензия күренә. Моннан тыш ул рус теленнән татарчага берничә брошюра тәрҗемә итә, русча-татарча сүзлек төзү эшенә керешә. Казан арты, шулай итеп Казанга белем бирә. Белем бирә, кеше бирә.

Казан арты — Кышкар мәдрәсәсе Казан шәһәренә, татар мәдәниятенә бик тә кирәкле тагын бер кешене әзерләп биргән. Ул — Олы Мәңгәр егете Габделмәннән Рахманколый. Кышкардан туп-туры Казанга килә. Җәяүләп. Татарская учительская школага кереп белем ала, Мамадыш өязе Олы Шыңар авылына барып яңача укыта башлый. Яңача укыткан мөгаллимне кыйныйлар, өркетәләр. Габделмәннән (1860 елда туган) Казанга күчеп килә. Татар мәктәпләре өчен уку китаплары чыгара, Пушкинны, Крыловны тәрҗемә итә, балалар үстерә. Бу балаларның һәрберсе татарлар арасындагы прогресска хезмәт күрсәтәчәк: Каюм, Нәҗиб, Солтан, Мәрьям. Егетләр 1905 ел революциясендә катнашачак, Солтан Рахманколый тәрҗемәче, сүзлекләр төзүче, җырчы, Тукайның якын дусты. Якташлар. Тукай белән бергә уздырган көннәр, төннәр. Бәләкәй Мәрьям аларны хәтерли — абыйсын да, Тукайны да, РСФСРның халык артисткасы Мәрьям Рахманкулова әнә шулай — әтисе ягыннан — Казан арты «сандугачы».

Инде Г. Камалны да онытмыйк: ул Казанда туган, әмма әтисе дә, әнисе дә Казан артыннан. Әтисе бәхет эзләп Сикертән авылыннан килгән дә, үзеннән алдарак Казанда төпләнгән, Иске Масра авылы кешесенең (инде бай булган) кызына өйләнгән. Галиәсгар Сикертәнгә ничә тапкыр кайткандыр, Масрада бер кыш чыкканлыгы билгеле, әмма «Беренче театр»дагы тел, каламбур — Сикертәннеке. Димәк, әтисеннән. Бу авылга бүген барыгыз һәм теләсә кем белән

сөйләшегез — Г. Камал комедияләренең тамырын шундук тоеп алырсыз...

Казан арты әдәбиятка тел биргән, кеше биргән.

Кеше дигәннән, тагын бирәү: Нәкый Исәнбәт Казан артының бу хикмәтле кешесенә бәйле байтак мәзәк, мәкаль теркәгән. Сүз уңаенда әйтергә кирәк, Н. Исәнбәтнең өч томлыгына Әтнә — Мәңгәр — Күәм зонасыннан күп хәзинә кергән. Бу — алда әйтелгән шәһәр-авыл фольклорының үзенчәлекле бер катнашмасы, сыгынтысы. Казан арты халкы игенне дә гыйлем белән иккән, аңа «кара эш» итеп түгел, акыл эше, «ак» эш итеп караган һәм шуңа күрә иген игү, ел фасылы, һава шартларына бәйле бөтен бер поэтик сүз байлыгы тудырган. Әйе, теге кеше бит әле... Рәхмәй тылмач. Тылмач — тәрҗемәче дигән сүз. «Татарга тылмач кирәкми», — дигән мәкаль «тәрҗемәче кирәкми» дигән сүз, бу — Урта Азиядә сәүдә белән йөргән Казан арты татарлары тудырган мәкаль. Чыннан да, Урта Азиядә сәүдә кылган татарга тылмач кирәк булмаган. Әмирхан Рәхмәтулла улы (1807—1874) Тукайның Өчилесенә якын гына Яңа Кишет авылында туган. Казанда белем ала — үзлегеннән өйрәнә, гарәп, фарсы, рус телләрен бик яхшы өйрәнә. Профессор Готвальд китапханәсендә тәрҗемәче булып утыра. Рус газеталары, рус китаплары укып дөнья хәлләре белән танышып бара. Казан губерна идарәсендә төрле эшләр башкарып дәүләт орденнары ала. Казан басмаханәләрендә яхшы кара, яхшы кәгазь белән мәктәп өчен кирәкле китаплар бастырып, Казан арты мәктәп-мәдрәсә укытучыларына шуны бүләк итүне үзенә бер шөгыльгә әйләндерә. 1839 елда беренче тапкыр «Кыйссаи Йосыф»ны, 1841 елда беренче «Гоppәнамә» (табель-календарь), 1861 елда географик карта, болардан тыш төрле шагыйрьләрнең әсәрләрен җыеп «Диване ризаи» дигән китап бастыра. Ш. Мәрҗанинең якташы, фикердәше һәм замандашы буларак, ул да Казанның кара бае Ибраһим Юнусов белән конфликтта була. «Кыйссаи Йосыф»ның беренче басмасының ахырында мондый сүзләр бар: «Ушал Йосыф китабы» Казан өязе Яңа Кишет авылының Рәхмәтулла угылының хәраҗәте илән нәфгы гыйбаде мөслимин өчен, укыяннардан догаи хәер өмит итеп, Казан университетының Азиатский табгыханәсендә хәзинәлектән басма улынмыштыр, шәһре Казан, 1839 нчы елда вә гарәбия илән 1254 сәнәдә». Яңа Кишет авылы егете, шулай итеп,

миллионлаган татар халкына классик поэма «Кыйссаи Йосыф»ны бастырып тарата! Шуның өстенә Арча янындагы Казиле авылы мәчете янгында һәлак булгач, Рәхмәй тылмач үз акчасыннан бу авылга кызыл кирпечтән яңа мәчет салдырып куя. XIX гасыр архитектура үрнәге буларак бу бина әле дә халыкка хезмәт итә: кирәк икән — клуб, кирәк икән — концерт залы, китапханә һ. б.[1]

Рәхмәй тылмач артыннан күрше авыл егете — Орнашбаштан чыккан Корбангали Халиди (1846—1913) үрмәли. Анысы Кытай уйгурлары арасына сәяхәт итә, гыйлем-мәгърифәт эзләп Мисыр, Иран, Гыйрак, Иерусалим, Төркиядә йөри, күп китапханәләрне актара. «Яңа тарих сәхифәләре» дигән хезмәте 1889 елда Казанда аерым китап булып басылып чыга, 1910 елда исә яңа хезмәтен «Тәварихы хәмсәи шәркыя» («Биш көнчыгыш иленең тарихы») бастыра. Чит җирдә — уйгурлар арасында 1913 елда үлеп кала...

1878 елда Казан артын дер селкеткән вакыйгалар булып ала. 1861 елгы реформадан соң авылда эксплуатация көчәя, аз җирле Казан арты халкы шулай Уральск, Троицк, Урта Азия, Оренбург якларына күпләп күчә. Авылларда күп җирле кулак катлавы оеша башлый, ярлы крестьяннар исә аларга кабалага көннән-көн күбрәк төшә, эләгә баралар. Шуның өстенә 1878 елда патша хөкүмәтенең «Мир җыемнары» турында инструкциясе чыгып, бу инструкция татар авылларына да таратыла. Инструкциядә татарлар гадәтләнгән «мәхәллә», «авыл» сүзләре урынына «епархия» дигән сүз кулланыла, янгынны кисәтү өчен авыллардагы калку урыннарга чаң куярга диелә. «Епархия», «колокол» дигән сүзләр татар агайларын сискәндереп җибәрә. Көчләп чукындыру түгелме бу? Шул шик астында Олы Мәңгәр авылы крестьяннары баш күтәрәләр.

1907 елда Тукай «Әлгасрел-җәдид»нең 2 санында «Локман Хәким сүзләре» дигән баш астында афоризмнар бастыра. Локман Хәким — легендар зат, нәкъ инде Хуҗа Насретдин кебек. Тукай аның авызыннан әйттергән булып, ихтимал, үз сүзләрен дә урнаштыргандыр. Арадан берсе: «Гадел солтан, тугъры казый, белгеч табиб, агым су, корылган базар булмаган җирдә тормак тиеш түгелдер». Акыл

[1] Мәгълүмат 1980 нче еллар уртасына карый.

иясенең сүзләрен ахырдан алга таба санап барыйк: Казан артының базарларын, суларын күрдек — алары бар. Белешмәлекләр күрсәткәнчә, XIX гасырда Арчада бер доктор да булган. «Гадел солтан»нары да булган... Тарих Романовлар династиясенең никадәр «гадел» икәнен күрсәтте. Локман Хәким әйткән «тугры казый» исә — Казан губернаторы Н. Я. Скарятин кораллы отряд белән Казан артына үзе килеп төшә. Калганын безгә фольклорчы, галим, драматург, прозаик һәм шагыйрь Гали Рәхим сөйли. Г. Рәхим 1878 елгы крестьян восстаниеләренең тарихын язу өчен 1927 елның җәендә Олы Мәңгәргә килә. Ни өчен нәкъ менә Г. Рәхим килә? Г. Рәхимнең әтисе Мөхәммәтшакир Габдрәхимов — Мәңгәр авылы крестьяны. Бәхет эзләп Казанга килә дә, шуннан мая туплап, сәүдәгәр булып китә. (З. Хәсәни һәм Р. Габдрахимоваларның (Г. Рәхимнең сеңлесе) миңа сөйләгән истәлекләреннән.) Күп материаллар актара торгач, моны юкка чыгара торганы да очрады: 1934 елның августында НКВД канцеляриясеннән Г. Рәхимгә бирелгән белешмәдә «әтисе — Мөхәммәтшакир Бикчәнтәй улы Абдрахимов, Лаеш өязе Олы Мәтәскә авылы крестьяны» диелгән. Бу ике факт мине бераз бутады. Шулай да, Г. Рәхимнең Казан арты белән бик нык кызыксынуы, восстание тарихын, Уразаев-Курмаши биографиясен өйрәнүе, 20 елларда Гыйльми Үзәк планы буенча «Бүз егет» операсы өчен либретто язарга тотынуы аның нәселе Мәңгәр ягыннан булгандыр, дип уйларга нигез бирә.

1878 елгы чуалышларның нигезендә әлбәттә инде, беренче чиратта, социаль-экономик изү торган. Дини изү — сылтау гына...

Казан артында крестьяннар хәрәкәтенең аеруча көчле үзәген Мәмсә, Әтнә, Олы Мәңгәр волостьлары тәшкил иткән. Олы Мәңгәр волосте — анда 4000 ир кеше исәпләнгән. Халык гаделсезлеккә протест йөзеннән авыл старшиналарын, волость старшинасын урыннарыннан алып, яңаларны сайлый, полиция стражнигын кыйный. Халыкны тынычландырырга теләгән мулланы да кыйнап ташлыйлар. Чиновниклар качып китәргә мәҗбүр булалар.

Әтнә волостенда 3500 ир кеше исәпләнгән. Анда да нәкъ шундый ук хәлләр була. Волость идарәсенә бәреп кереп андагы кәгазьләрне ертып ташлыйлар, алар старшина һәм писарь «1879 елдан чукындыру башланырга тиеш» дигән

кәгазьне яшергән дип ышанып, шуны эзлиләр. Волость старшинасының печатен алалар һәм сандыкка бикләп куялар.

Мәмсә волостена 20 авыл керeп, анда 4000 ир кеше исәпләнгән. Анда да нәкъ шулай волость старшинасын алыштырудан башлыйлар. Теге приговорны таләп итеп старшина һәм писарьне кыйнап ташлыйлар. Волостьтагы 12 промышленникны, кире кайтсагыз, үтерәбез дип куып җибәрәләр.

Казаннан 500 кешелек атлы батальон белән губернатор Скарятин юлга чыга. Ул Олы Мәңгәр — Мәмсә — Олы Әтнә маршруты буенча уза. Крестьяннарны волость үзәкләренә җыялар. Тезләнеп, бүрек, кәләпүшләрен салдырып, губернаторны каршы алдыралар. Губернатор рәт араларында йөри, крестьяннарны «этләр» дип сүгә, сакалларын йолкый, күнитек белән тибә. Чиновникларга кул тидергән кешеләрне сайлап алып камчы белән ярдыра. Бәхтияр авылыннан Шакир Исхаковны, Орнашбаштан Шәмсетдин Сәйфетдиновны тотып (элек кулга алынган кешеләр) Олы Мәңгәргә Скарятин янына китерәләр. Олы Әтнәгә килгәч, губернатор волость идарәсен саклаган Хәсән Вәлиуллинны, Гобәйдулла Әхмәдуллинны, Кәлимулла Әхмәдуллинны, Гыйззәтулла Миңлебаевны үз кулы белән кыйный. Йөзләгән крестьян суктырыла, судка бирелә, каторгага озатыла. Казан арты таза, гайрәтле ирләрдән бушап кала. («Коммунизмга» газетасы, 1979 ел, 134 сан, Арча).

Тукай туарга нәкъ 8 ел вакыт бар әле...

Бу вакыйгалар турында восстаниене үз күзе белән күргән Шаһиәхмәт мулла Мөхәммәдиев сөйли. Г. Рәхимнең бәхетенә каршы, 80 яшьлек картның хәтере әйбәт була...

«Тугры казый» Казан артыннан әнә шундый канлы экспедиция белән уза. Иң асыл уллар бу вакыйганың корбаны булалар.

Казан губернасындагы крестьян чуалышлары Т. Гыйззәтнең «Ялкын» («Фәрхиназ») драмасына нигез була. Анда мондый юллар бар:

Исправник: Господин ротмистр! Боларны яклап Тигәнә, Мәңгәр авылларында көчле восстание... Генерал-губернатор Скарятин хәзрәтләре биш йөз кешелек гаскәр белән Казаннан Спаска киткән. Сезгә һич кичекмәстән Мәңгәр волостена барырга әмер иткән.

Бу вакыйгалардан соң нәкъ унөч ел үткәч, Петербургның хәрби ахуны Гатаулла Баязитов рус матбугатында патша администрациясен ялгышлар җибәргәне өчен тәнкыйть итәр: «Инде килеп, калку урыннарга чаң урнаштыру мәсьәләсен алсак, монда сүзнең мәчет манараларына чаң куйдыру турында бармаганын татарларга аңлатырга кирәк иде. Шулай ук: бер волостька рус теле дәреслекләре җибәргәннәр, ә китап ахырында христиан догалары урнаштырылган. Йә, нигә инде бу?» («Санкт-Петербургские ведомости», 1891, 96 сан.)

Казан арты татар культурасы, мәгърифәте мәйданына әле тагын берничә шәхес бирә. Шул чорда ул төбәктә тагын ике кызыклы кеше туа: Солабаш авылында Хәсәнгата Габәши һәм Бикнарат авылында Хәбибулла Әхмәдуллин.

Хәсәнгата Габәши мәдрәсә белеме алганнан соң Казандагы Вәли мулла мәдрәсәсендә (кара фикерле мулла) хәлфәлек итә. Көннәрдән бер көнне үзенең якташы Шиһабетдин Мәрҗани белән әңгәмәдәш булу бәхетенә ирешә. Берике авыз сүздән кешене таный һәм «диагноз» куя алу сәләтенә малик булган Мәрҗани ахырдан болай ди: «Вәли мулла мәдрәсәсендә шундаен ачык фикерле шәкертнең булуына тәгаҗҗыб иттем (гаҗәпләндем), һәм шул мәдрәсәдә канәгать итеп торуына да тәгаҗҗыб иттем». Аларның танышлыгы күптәннән килә: Мәрҗанинең атлары шәп булган, җаны теләгән вакытта ул Казан артына кайтып, нәселнәсәбенең хәлен белеп йөргән. Хәсәнгата болай дип искә ала: «Мәрхүм илә (Мәрҗани үлгәч язган.— *М. М.*) без авыл юлларында очраша торган идек. Күбрәк очрашу Югары Сәрдә илә Соңгыр арасында була иде. Бервакыт кыш көне шактый буран көндә, аның — Казанга кайтышы, безнең әткәй илә Иске Йорт авылына барышымыз иде. Ерактанрак яхшы пар кара ат, мичәүләп повозкага җиккән, кучер утырткан берәү күренде. Безгә ун сажень микъдарда калгач, бер казылма янында мичәү аты читкә керде дә, кергәннән кереп, төп атны да читкә тартып төшереп, үзе карга батып егылды. Әткәм мәрхүм миңа: «Кем дә булса олугъ кешедер, чыгарып!» — диде. Мин дә өске киемемне салып йөгереп бардым да, чанада кем икәненә күз салмастан, тизрәк мичәү атны башыннан тотып, бераз мәшәкать илә булса да, юлга чыгардым, төп ат та чыкты. Менә чанадагы белән күзебез-күзгә төште. Мәрҗани хәзрәтләре икән. Ул да буран арала-

рыннан минем күренүемне гаҗәпсенеп: «Ни гаҗәп тәсадыф (очрашу)! Мөшкел вакытыбызда җитештең. Син Хәсәнгатамы?— диде.— Әйе, хәзрәт, мин Хәсәнгата,— дидем.— Хәзрәт, сезнең урында бер ишан булса, ат башында бер мөрите булса иде, әлбәттә, мине Хозыр дип санарлар вә ишанның олугъ кәрамәтеннән хисап итәрләр иде бит!— дидем дә, көлештек, соңра юлыбызга киттек...

Х. Габәши, күрәсең, Мәрҗани тәэсирендәдер, үзен тарих гыйлеменә багышлый, Мәрҗанинең әдәбият-сәнгатькә карашлы фикерләрен пропагандалый. Х. Габәшинең тарих буенча хезмәтләре рус мөстәшрыйкләренә (востоковед) таныш булган. Мәсәлән, академик В. В. Бартольд Себер буенча 1913 елдагы сәяхәт вакытында аның хезмәтен өйрәнгән. Һәм андагы кайбер хаталарга игътибар иткән. («Вакыт», 1913, № 1240) Х. Габәши, Уфадагы Диния нәзарәтендә казый булып торганда, җыр-музыка мәсьәләсендә «Дин вә мәгыйшәть»челәр белән конфликтка керә. 1905 ел революциясе белән рухланган татар яшьләре һәр җирдә музыкаль кичәләр оештыра башлагач, кадимчеләр дин, шәригать дип бу кичәләрне тыймакчы булалар. Әмма Диния нәзарәте казый Х. Габәши яшьләрне яклап чыккач, югалып калалар. Тарихчы галим исә болай ди: халыкны җырсыз, музыкасыз калдырсаң, ул үлә. «Вакыт» газетасы Габәшине яклый, кадимчеләр исә моның өчен «Вакыт»ка һөҗүм итәләр. («Дин вә мәгыйшәт», 1915, 20 сан) Казан арты Солабаш авылыннан чыккан галим шулай итеп татар музыкасын шәригать кануннарыннан азат итәргә булыша. Шуның өстенә, үзенең улы Солтанны музыкага әзерли. Солтан Габәши — татарның беренче профессиональ композиторы булып җитешә, «Сания» операсын яза, «Эшче» операсының соавторы була, мәшһүр «Кәккүк»не иҗат итә.

Татар музыкасын теоретик һәм практик нигезләү өлкәсендә Казан артының роле искиткеч зур. Мәрҗани «музыка хәрәмме, хәләлме» дигән мәгънәсез сорауны бер селтәнү белән көн тәртибеннән алып ташлаган. «Музыканың... дөрес түгеллегенә шәрган дәлил юк, бәлки сандугач кеби тавышлары матур кошларның тавышларын ишетмәк вә тыңламак дөрес, вә тавышларның хәйваннардан чыкмакы берлән җансыз нәрсәләрдән чыкмакы арасында аерма юк.»

Мәрҗани бервакыт В. В. Радловның өендә булып кайт-

кач, кызларына болай дигән: «Радловның кызлары... музыка белә икән. Сез дә дөм сукыр булып үсмәгез».

Мәрҗанинең фикерен дәвам итеп, Хәсәнгата Габәши яза: «Музыка табигатькә тәэсир итә, халыкны күркәмләндерә, вәхшилекне бетерә, канны сафлый, фикерне киңәйтә — бонлар шиксездер, фән күрсәтүе илә сабиттыр».

Дөбъяз төбәге Бикнарат авылы... Кечкенә генә авыл. Әмма шәхесне зур авыл бирә дигән зарурилык кайда? 1875 елда Бикнарат авылында туган Хәбибулла Әхмәдуллинга да музыка хисе бик якын була. Үзлегеннән музыкага өйрәнеп ил буйлап чыгыш ясап йөри. Кушаматы — «Кара малай». Чәченә чал кергәч тә аны шулай дип йөрткәннәр. Скрипка остасы Хәбибулла үзенең осталыгына мәйдан таба алмый, мәйханәләрдә, чәйханәләрдә уйнап көн итә. Гаҗәеп талантлы әсәр «Аккош» көен иҗат итә. Бу көйне (моны марш дип тә, вальс дип тә йөрткәннәр) музыка коралы осталары Минкин, Г. Сәйфуллин «Стэлла» пластинкасына язып алалар.

1883 елда Әтнә авылында Әхмәтгәрәй Хәсәни туа. Бу кеше, Казанда «Гасыр» нәшрияты оештырып татар мәдәниятенә зур өлеш кертә. 1912 елда Тукай, Әмирхан белән әдәбият, сәнгать журналы «Аң»ны чыгара башлый, русча-татарча сүзлекләр бастырган Әтнә янындагы Түбән Киек авылыннан Уральскига сәүдә эше белән киткән Ногман агайның 1887 елда кызы туа — аңа Зәйнәб дип исем кушалар. 1904 елда ул Әхмәтгәрәйгә кияүгә чыга һәм «бирнә» акчасын «Гасыр» нәшриятын җайга салу өчен исраф итә. Тукайның Клячкин шифаханәсеннән язган иң соңгы хатлары — Хәсәниләргә.

Крестьян восстаниеләренең дәһшәтле, күз яшьле вакыйгалары халык йөрәгендә кара кан булып укмашкан хәсрәтле Казан артында — шул атмосферада — 1886 елда тагын ике бала туа. Берсе — Кушлавычта, Мөхәммәтгариф хәзрәт гаиләсендә, булачак шагыйрь Тукай. Икенчесе Шиһабетдин Мәрҗани нәселендә, Ташкичү авылында хәлфә гаиләсендә — Мәхмүт Галәветдинов. Әдәбиятта — Мәхмүт Мәрҗани. Башлангыч белемне әтисендә алгач Казанга мәдрәсәгә килә, 1903 елда Әстерханда балалар укыта. Шунысы характерлы, яшь журналист үзенең эшчәнлегендә беренче көннән үк революционер Зариф Садыйков йогынтысында була. З. Садыйковның яшерен исеме — Ибраһим Моратов. Бу

шəхес турында сүз чыккач (М. Галəүнең дөньяга карашын тəрбиялəүдə аның роле зур була), кызыклы гына ике-өч документны телгə аласы килə. З. Садыйков — революциядə катнашкан өчен сөрелгəн социал-демократ. Əстерхан губерна жандарм идарəсенə байтак мəшəкать тудырган ул. 1911 елның февралендə Əстерхан губерна жандарм идарəсе начальнигы Уфа ГЖУ начальнигына «танып белү» өчен бер фоторəсем җибəрə: «Ибраһим Моратов псевдонимы астында 1908 елда Əстерханда күренекле социал-демократлар арасында кайнашкан һəм матбугатта Əстерхан мөселманнары арасында пропаганда алып барган татарның фотография карточкасын сезгə юллап, 1909 елда бу кеше нинди исем астында сəяси эш буенча Уфада төрмəдə тотылганын хəбəр итүегезне сорыйм». Уфаның җавабы: «Ибраһим Моратов ул — Əхмəттин Тумаркин». Тагын бер җавап: «Карточкадагы шəхес — 1035 нче статья буенча җавапка тартылган Оренбург мещаны Габдрəүф Ниязбаев, ул ук — Казанец, ул ук — Кəримов»[1].

М. Галəүнең Əстерхан чоры революцион вакыйгаларга бай булган! Ул чыгарган журнал «Туп» кыска гомерле була, патша властьлары аны ябалар. М. Галəү Оренбургка китə һəм анда сатирик журнал «Кармак»ны чыгара башлый, китап кибете ача.

Тагын кемнəр чыга Казан артыннан? 1886 елда кечкенə генə Орнаш (Əрнəш) авылында Зөлəйха исемле кыз туа. Бераздан без аны «Сəйяр» труппасында күрербез. «Сəйяр»ның күренекле артисткасы Зөлəйха Богданова Тукайның яшьтəше һəм якташы — совет властеның беренче елларында театр сəнгатен үстерү эшендə күп көч куя. (Зөлəйха 1950 елда Буада үлə.) Аның белəн бергə «Сəйяр»да тагын бер кыз уйный: анысы Зөлəйханың якташы — күрше Утар Аты авылыннан Нəгыймə Таҗдарова, 1888 елда туа. Крестьян Əхмəдулла абзыйның сигезенче баласы. Бəхет эзлəп Казанга килə, Гайниҗамал исемле игелекле бер карчыкка фатирга керə һəм əтисе биргəн акчага тегү машинасы сатып алып тамак туйдыра. Нəгыймə укый-яза белə, Казан арты халкына хас булганча хезмəт итəргə күнекмəсе зур була, шуның өстенə яшь, чибəр. Укытучы булырга җыена.

---

[1] ТР ҮДА, ф. 51, 1 тасв., 175, 177, 178 эшлəр.

Әмма, очраклы рәвештә «Сәйяр» артисткасы Мәрфуга Иманская белән таныша һәм Мәрфуга аның турында Габдулла Кариевка сөйли.

...Утар Аты кызының күзләре Кариевны тетрәтә. Мондый күзләр сирәк була! Бу — борынгы Болгар кызларының гүзәллеге! Кариев аны сәхнәгә әзерли башлый. Ләкин Нәгыймә моңа әзер түгел. Күрсәтелгән көнгә «Шәрекъ клубы»на килеп, ул Кариевка болай ди:

— Мин сезнең тәкъдимнән баш тартам, укытучы буласым килә...

Сәхнә псевдонимын — Әхмәдуллина урынына «Таждарова»ны аңа Кариев табып бирә. Нәгыймә башта кечкенә рольләрдә чыгыш ясый. Булдыра алмый — ташлый. Бераздан Кариев аны кабат чакыра.

— Әгәр дә аллага шулай ялынсам, ул да минем сүземне тыңлар иде, — ди мәшһүр режиссер.

Н. Таждарованың сәхнә биографиясе Ф. Әмирханның «Тигезсезләр» әсәре буенча эшләнгән спектакльдә Рокыя образын иҗат итүдән башлана. Тукайның ике җан дусты — Ф. Әмирхан һәм Г. Кариев бу рольне аның якташына — Утар Атының гүзәл, сихри карашлы принцессасына уйнатуны кирәк табалар. Н. Таждаровага ТАССРның халык, РСФСРның атказанган артисты дигән мактаулы исемнәр бирелә.

Кушлавыч авылыннан чыккан Мөхәммәт Вәлишин да артист булып китә. Иренә һәм бөек шагыйрь туган авыл исеменә ихтирам йөзеннән аның хатыны артистка Рөкыя үзенә псевдонимны әллә каян түгел, Тукай туган бишектән сайлап ала: Рөкыя Кушловская...

Тарих кызык: Зөләйхалар, Нәгыймәләр, Тукайлар туып ята. Әле кемнең кем буласын берәү дә белми. Әле Арчадагы икееллык һөнәр училищесында укып йөргән тәртипсез малай — Әмә тавыннан (Казан бистәсе) килгән Федяның да кем буласын белгән юк. Казан малае столярлык эшенә өйрәнә. Әмма дәрес вакытында берәр артык хәрәкәт эшләдеңме — хезмәт укытучысы туп-туры фуганок белән суга. Гел кыйнау... Федя бу хәлгә чыдый алмый, китап төпләү классына күчә. Анда да кыен. Көннәрдән бер көнне Федя кача. Арчадан җәяүләп Казанга чыгып кача. Иске Чүриле авылына килеп җитәр-җитмәс, атка атланган училище каравылчысы аны куып җитеп, Арчага кире алып кайта. Федяны

яткырып суктыралар. Кемне кыйныйлар диген? Бөтен Россияне һәм Парижны таң калдырачак җырчы Федор Шаляпинны...

«Ул заманда Арчада яшәвемнән бер генә әйбәт истәлек калган — ул да булса — шимбә көн мунчада чабына идек һәм мунча янындагы карга чыгып ауный идек». Моны инде ул Парижда яза.

Утар Атыда, Әрнәштә, Кушлавычта Зөләйхалар, Нәгыймәләр, Габдуллалар туып ята, бишектә тибрәнәләр, Федяны училище идәненә яткырып чыбык белән туныйлар, Сембер шәһәреннән килгән 17 яшьлек Володя шул вакытта царизмның реакцион кануннарына каршы протест белдереп, университетта сходка оештыра. Болар барысы да бер-ике елда, Казан артында һәм Казанда...

Инде тагын кемне бирсен Казан арты дисәң — бәрәкәтле якта ниләр булмас... 1900 елны Казанда һөнәрче Җамалетдин Бикчәнтәев гаиләсендә бер малай туар. Чүәкче Җамалетдин Казан арты Өбрә авылыннан. Шәһәргә бәхет эзләп килгән. Яңа туган малайга Салих дип исем кушалар. Нибары ике дистә ел үтәр — аның исеме инде Сәйдәшев дип яңгырар. Казан арты татар халкына әле алга таба да сәнгать кешеләрен бирер.

1895 елның 26 декабрендә Дөбъяз төбәге Чыршы авылының Гайниҗамал апа бер малай табар — ул малай татар сәхнәсенең сандугачы Ситдыйк Айдаров булып җитешер, татар музыка сәнгатен үстерүдә якташы Солтан Габәши белән җиң сызганып эшләр. Ситдыйкның биографиясе бик кызык: аның әнисе Чыршыдан Казанга килеп Зәңгәр Мәчет мулласы Касим хәзрәткә асраулыкка керә. (Ахырдан бу хәзрәт Тукайны күмгәндә кабер өстенә басып шагыйрьнең «Васыятем» дигән шигырен укый.) Мулла абзый Чыршы кызын Тау ягының Иске Чәчкаб авылы егете солдат Хәнәфигә кияүгә бирә, алар дөньяга Ситдыйковны китерәләр. Ситдыйкның музыкаль тәрбиясенә Сәйдәшев зур йогынты ясый, Ситдыйк исә, үсә төшкәч, Тукайның остазы Мотыйгулла Төхфәтуллин кызы Галия Кайбицкаяга өйләнә... Галия Уральск шәһәрендә Тукай газета-журнал чыгарып ятканда туа.

Чыршы — гомумән, хикмәтле, куәтле авыл. Легендаларга караганда, Пугачевның бер кучеры Әбдрәшитов — шул авыл егете. Ахырдан Пугачев офицеры — Рус Алаты егете

белән бергә алар судта булалар. 1905 елда Әтнә төбәге кечкенә Шашы авылында туган Ильяс Әүхәдиев тә скрипка остасы, сәнгать белгече, педагог булып җитешер. Өбрә — Өмбе — Әлдермеш төбәгеннән совет чорында Әнвәр Бакиров, Хәй Вахитлар чыгар.

Ләкин болары инде соңыннан...

Игътибар иткәнегез бармы? Гомеренең иң соңгы айларына кергәч язган шигырьләрендә Тукай — Атлант кебек. Бер генә вак фикер, бер генә «бытовизм» юк. Тукай 1913 елга чыккач пәһлеванга әйләнә дә куя. Күңелен аның кемнәр билгән соң?

Толстой, Некрасов, Мәрҗани, Пушкин, Лермонтов, Жуковский, Толстой фикере белән бер-бер артлы дүрт шигырь, «Суык» поэмасы. Китап төзүче Тукайчылар юри әйтмиләр: Некрасовка ияреп язылган ул «Суык» әсәре. Һәм шулар арасында — Мәрҗани. Ник алай, нигә гомеренең соңгы айларында гына Тукай аны телгә ала? Бер дә шикләнмичә әйтергә мөмкин ки, Тукай 1913 елда кабат һәм иң көчле «прозрение» кичерә. Тарихны кабат күзаллаганда яңадан Толстой. Клячкин шифаханәсендә язган Тукайның иң соңгы шигырьләреннән берсе — «Толстой сүзләре». Тукай анда намуслы хезмәт белән яшәргә, кеше малын алмаска чакыра. Толстойның кайсы сүзләрен нигезгә алган соң ул? Ихтимал, менә боларындыр: «Кешене хезмәт кебек башка берни дә яхшырта алмый. Хезмәттән башка кеше үзенең кешелек дәрәҗәсен саклый алмый».

Тукай гомеренең соңгы айларында, гомумән, Толстой дөньясына керә. Шул ук чорда Тукай үзенең уй-хисләре белән Мәрҗанигә килеп чыга.

...Алар — Мәрҗани һәм Тукай — якташлар гына түгел. Аларның татар халкына иткән файдалары, ясаган тәэсирләре охшаш. Биографияләренең башлангыч адымы уртак. Тукай гомеренең ахырында әнә шулай Мәрҗанине ача. Биографияләре дидек.

Шиһабетдинга 5 яшь тулганда аның әнисе Бибихәбибә баладан үлә. Соңгы минутында улын чакырып китереп аның башыннан сыйпый. Бер шәкерт исә Шиһабетдинны әнисенең җеназасы артыннан күтәреп алып барган. Тукай да: «Мин монда әнкәмнең җеназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан, үкереп җылый-җылый, йөгереп чыгып: «Әнкәйне бире-

нез!»—дип, шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне (хәтерләвемне) язамын» («Исемдә калганнар»).

Казан артында әнә шундый биографияләр бар. Ләкин биографик параллелизмнар моның белән генә бетми. Бөек биографияләрдә һәрвакыт охшашлыклар була. Казан ягы биографияләргә, гомумән, бай. Ул биографияләр тегеләй-ме-болаймы, Казан артына параллель сорыйлар. Бөек шәхес Николай Лобачевский бар. 1830 елда Казан тирәсендә ваба авыруы таралгач, университет ректоры Лобачевский шул авыруга каршы көрәшү өчен галимнәрдән, табиблардан отряд оештырган, махсус халат, бияләй киеп дезинфекция төнәтмәләре ясаган, авылларга үзе чыккан, профилактика уздырган. Күпмедер дистә еллар узгач ваба авыруы Казан губернасына тагын һөҗүм иткән, әмма бөек математик инде юк. Татар авылларына профилактика белән килгән «урыс докторларын» надан муллалар кертмиләр. Ваба авыруы таралган көннәрдә Казан губернасында бигрәк тә хатын-кыз кырыла. Әмма, Ш. Мәрҗани губернатор кәнсәләреннән торып, татар муллаларына фәтва күндерә: наданлыкның корбаны булмагыз, докторларны авылга кертегез, дәва чараларын уздырырга ярдәм итегез... ди.

Алар—Лобачевский, Мәрҗани, Тукай—әллә ничек кенә бергә бәйләнгәннәр, бер үк юлдан баралар, Казан губернасының язмышын ягъни халык язмышын өчесе өч чорда, бергәләп кайгырталар. Лобачевский патша реакциясенең җәберен күреп, шәхси фаҗига кичереп (яраткан улы үлә), эшеннән алынып авыру хәленә килгәч, мәшһүр «Пангеометрия» дигән әсәрен кешегә әйтеп торып яздыра: үзе үлем түшәгендә. Мәрҗани үз шәкертләрен чакыртып үләренә санаулы көннәр, сәгатьләр калганын белә торып, тарихи хезмәтләрен әйтеп яздыра. Тукай Клячкин шифаханәсенә кергәч үз иҗатының иң югары биеклеге булган шигырьләрен, мәкаләләрен яза.

...Безнең фольклор галимнәре әдәби телебезнең XVI йөз Казан-шәһәр теле белән Казан арты авыл теле катнашмасы нигезендә туган халык иҗаты әсәрләре җыю буенча Арча—Әтнә—Дөбъяз—Балтач регионында соңгы елларда бик үк актив түгелләр. Фольклорчы Хуҗа Бәдигый Венгриядән килгән галимне 1907 елда нәкъ менә фольклор оясына—Курса авылына алып барган. Юлий Мейсарош белән бергә

алар бик күп мәкаль-әйтем җыялар, 1912 елда Х. Бәдигый бу мәкальләрне аерым китап итеп бастырып чыгара. Казан арты җырга, бәеткә, әкияткә, мәкальгә гадәттән тыш бай: һөнәрле, сәүдәле, юл йөрешле, базарлы һәм иген-тарулы җирдә шунсыз мөмкин түгел. Халык тыгызлыгын да искә алыйк. Менә 1897 елгы халык санын алу нәтиҗәләре: Олы Әтнәдә — 2986 җан, Яңа Кенәрдә — 1998, Олы Мәңгәрдә — 1775, Яңа Кишеттә — 1326, Югары Курсада — 1197 җан. Зур авыллар!

Пугачев явында актив катнашкан авылларда, 1878 ел вакыйгаларын кичергән халыкларда азмы бәет булгандыр! Тукайның сүзләре бар: «Безнең халык — шигырь вә җырбәетләр чыгарырга бик маил халык. Чү, аз гына бернәрсә «шылт» иттеме, инде аның тугърысында иртәгә урамга бәетләр чыга» («Халык әдәбияты»).

Казан артында булган хәлләр, гомумән, әдәбиятта зур эз калдырган. Тукайның «Шүрәле»се — бары тик Казан артыныкы. «Кәҗә белән Сарык хикәясе» дә шуннан. «Тормышлары шактый гына фәкыйрь булган; үзең яхшы беләсең бит печән хакын» һ. б. Тукай моны 1909 елда язган, ә әкият 1877 елда Казанда уздырылган археологларның Дүртенче съездында рус телендә хәбәр ителгән инде. Тукай әле аны язып бетермәгән, дөресрәге — туктаткан. Аның әле съездда сөйләнгән текст буенча дәвамы бар... «Су анасы» — Казан арты татарларының гасырлар буе бала тәрбияләү мәктәбе булган педагогик кулланмасы. Монда ике эш эшләнә: а) кеше әйберенә тимә; б) ялгыз су коенма. Казан артында көн уртасында, бигрәк тә көндезге 12 дә, ялгыз су коенган баланы су анасы ала дигән ышану бу якларда елгалар кибеп беткәнче яшәде әле. Тукай авыл, табигать темасына кайда гына торып язмасын, Уральскидамы, Казандамы — тасвир бары тик Өчиледән, Кырлайдан, Кушлавычтан, Масрадан, Иске Йорт — Чиканас төбәгеннән. Бу — бәхәссез.

Казан артындагы социаль фон, сыйнфый көрәш иң зур полотно булып Мәхмүт Галәүнең «Болганчык еллар», «Мөһаҗирләр» дигән ике романында чагылыш тапты. Монда Мәмсә, Мәңгәр, Әтнә вакыйгалары да, Ш. Мәрҗанинең Казан бае Ибраһим Юнусов белән катлаулы авыр мөнәсәбәтләре дә — барысы да искиткеч зур осталык белән сәнгатьчә чагылдырылган.

Тукай үзенең язмаларында бер генә тапкыр булса да

«Арча» дип телгә алмый. Ә без — Арчадан чыккан әдәбият әһелләре — гел тукып торабыз: без — Тукай якташы, Тукай якташы... Язмаларында Тукай бер дә «Арчада булдым» дигән сүзне кулланмый. Югыйсә, тарихи урын: «Арча» сүзе беренче булып 1375 елгы Новгород елъязмасында очрый. Арчада бик борынгы крепость булган. Ниһаять, Арча — Балтач юлыннан Радищев узган. Арча турында көндәлегенә язган. Арча крепосте тарихы С. М. Шпилевский хезмәтләрендә чагылыш тапкан. 1900 елның җәендә Казан университетының Тарих, Этнография һәм Археология җәмгыяте Арчага махсус экспедиция оештыра. Арча крепостеның манарасын саклау эше шәһәр старостасы Н. П. Щелкинга йөкләнгән. Щелкиннар нәселе Арчада әле дә яши.

Әнә шул тарихи «шәһәрчек»тә Тукай бер тапкыр да булмаган, аны телгә дә алмаган. Дөресме бу, табигыймы бу?

Тукайның йөргән юлы беркайчан да Арчага туры килмәгән. Ул вакытта ат юлы: Өчиледән Кырлайга бару өчен Арчага керүнең хаҗәте юк. Өчиледән Яңа Масрага барганда Арча читтә кала. Мин моны күз алдына китерәм: Өчиледән туры Мөндешкә, аннан Казанбашка, аннан — Яңа Масрага, Казан — Өчиле арасында да Арча бөтенләй читтә. Тукайның очеркларында күренгәнчә, алар Казаннан Чыпчык, Коркачык, Тимерче, Кишмәт, Сәрдә юлыннан йөргәннәр. (Тукайны 1911 елның декабрендә Өчилегә алып кайтучы кеше Сәрдәнеке булган.) Тукай Казанга кайтканда нәкъ шул маршрут буенча узганын яза.

Өчиледән Кәбир мулла белән базарга килгәндә, Тукай Әтнәдә түгел, ә Арча урысында патшалар, дәүләт политикасы турында сөйләшеп утырган. Покровка урамында революциягә кадәр салынган зур лапаслы, өч-дүрт бүлмәле йортлар, крыльцолы, зур капкалы хуҗалыклар әле дә бар. Аларда сәндерә дә сакланган әле, мич башы да. Арчаның кайсыдыр бер йортының мич башында Тукай, әнә шулай, базар көнне сөякләрен җылытып яткан...

Ихтимал, шундый фатирда җыелган чактадыр, Казан артының кырыкка якын мулласы — яңача укыту тарафдарлары — бөтен тирә-якның кара көче Ишми ишан өстеннән губернаторга жалоба бирү турында сөйләшкәннәр. Ләкин Ишми ишан аларга караганда җитезрәк булып чыккан һәм губерна жандарм идарәсенә «яңача укытучы кызыл мул-

лаларның» исемлеген төзеп донос җибәргән. 1911 елның февраль-мартында аларны җыеп төрмәгә утыртып та куйганнар. Казан арты тынсыз калган. Күпмедер тикшерүләрдән соң аларны азат иткәннәр. Әмма мулла-мөгаллимнәр, үзара сөйләшеп, моңа чик куярга булганнар һәм якшәмбеләрнең берсендә Арча базарыннан Югары Курса авылына юл тотканнар. Ул төбәктә, ни сәбәптәндер, Казаннан җибәрелгән шәһәр муллалары булган. Югары Курсада — Казан кешесе Уразгилдеев, күрше Иске Масрада — Казаннан, Мөхәммәдия мәдрәсәсе шәкерте, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимовлар белән тегеләйме-болаймы Нижгар мишәре Гаяз Фәтхетдинов, Яңа Масрада — гарәп телен камил белүче, әдәбиять-тарих буенча зур әзерлекле кеше, Тукайның туганнан туганы Габдрахман Җәләлетдинов...

Казан артына белемле, үткен, телләр буенча әзерлекле муллаларны Казан, Сергач, Чистай, Нижний Новгород мишәрләрен җибәрү модада булган. Г. Камал әтисенең авылына — Сикертәнгә — Кышкар шәкерте, рус телен мөкәммәл белгән Габдулла Хәсәневне имам-хатиб итеп җибәрәләр, ул исә — үткен мишәрләр — Чистай ягыннан. Ә теге елны (1911) яңача укытучы муллалар, Курса мулласы Уразгилдеев өенә җыелып, губернаторга гариза-прошение язалар. «Безне Ишми дигән бу афәттән коткарыгыз, бу кеше безнең Казан артын бөтенләйгә харап итә»,— диләр. Ахырдан Курса авылына килеп допрослар ясыйлар. Уразгилдеевтан сорыйлар: кемнәр килде, кемнәр килде, кем яза башлады, кем нәрсә дип әйтте... Бу турыда документлар Казан жандармерия идарәсенең фондларында сакланган.

Казан арты — бөтен Казан губернасында иң һөнәрле як. Бу — бәхәссез. Һөнәр, кәсеп — зур базарларда гына түгел, зур җыеннарга да ихтыяҗ тудырган. Ниһаять, галимнәр моны да өйрәнә башладылар. Соңгы елларда җыеннар турында дөньяга чыккан иң әһәмиятле хезмәтләренең берсе — Н. Б. Борһанованың «О системе народного праздника джиен у казанских татар» дигән тикшеренүе[1]. Моннан күренгәнчә, Алат юлында Олы Кыр, Биектау, Кушнарат, Әтнә ягында Шөмбер, Мукшы тавы, Калатау, Кенәр ягында — Кенәр,

---

[1] Исследования по исторической диалектологии татарского языка (Казань, 1982) дигән китапта.

Тазлар каршы, Шекә, Казакъ, Иябаш, Кишет, Дөбъяз тирәсендә Бәрәзә җыены булган. Бәрәскәнең дә үз җыены булган.

Арча тирәсе җыеннарга аеруча бай: Урман җыены (Чиканас — Өчиле), Утар, Ямаширмә, Сасмак, Сәрдә (икенче төрле — Кушлавыч), Әйше, Наласа, Күкчә, Күпербаш, Пошалым, Казан тавы җыеннары; Кесмәс буенда — Му җыены. Тар гына Казан арты өчен болар, әлбәттә, күп. Әтнә — әлбәттә, инде борынгы Казан нәселе. Анда, күрше-тирә авыллары җыелып, «Кала җыены» үткәргәннәр. Риваятьләр буенча, кайчандыр бу якларга күчеп килүчеләрнең бу тирәдә «кала»лары булган, халык бу урынны гасырлар буе «Болгар каласы» дип атап йөрткән...

Бу як авылларының тагын бер үзенчәлеге — һәр авылның үзенә күрә һөнәре бар. Рус авыллары — умартачы, калайдан йорт кирәк-яракларын ясаучы, кием манучы, буяучы, самовар төзәтүче (Бимәр, Чуриле руслары) Ключище руслары — чүлмәк ясаучы, Өҗем, Ташчишмә — кирпеч суга, Казаклар (йомышлы татарлар) — такта яручы, Гөберчәк, Кече Әтнә — итек басучы, Мөрәле — морҗасы, Пошалым — арба, чана, дуга, кисмәк ясаучы, Кылачы, Мүлмә, Әйше, Тимерче, Сәрдә, Сасмак — чигүче, аяк киемнәре тегүче, Мөндеш — көмешче, Күпербаш — итче, базарда — маклер. Әтнә гөрләгән: анда биш мәхәллә! Әтнәлеләр мари ягыннан терлек-туар алып кайтып, шуны базарга чыгарган. Өйдәге хатын-кыз, бала-чага, карт-коры бүрек теккән, читек каеган. Җәйләрен ирләр күмер, дегет эшләгәннәр, бөтен Казан арты авылларына хуш исле дегет сатканнар, тимерче алачыкларын шыңгырдап торган нарат күмере белән тәэмин иткәннәр. Аннан кыш буе Орнашбаштан заказ алып мех бүрек теккәннәр. Кыскасы, Әтнәләр йоклап, ләчтит сатып уздырмаганнар гомерне.

Моннан тыш та һөнәрләр бар: Казан юлы өстендәге Чыпчык, Арча, Мәтәскә, Карадуган — фатир төшерүчеләр. Бу авылларда крестьян йортлары, зур лапаслы каралтылар, чәйханәләр, кибетләр урнашкан. Боларның бай легендалары, фольклоры, горурлыклары бар.

Кенәр ягы — байлар ягы. Чыпта сугучы, дуга, чана эшләүче, чүлмәк ясаучы Шекә, Шушма якларын алар «кара як» дип атаганнар. Кенәр тирәсендә җир, урман биләүче байлар булган, бу авылда чигү, киндер сугу алга киткән. Дүрт

мәхәлләле «ак авылның» һәр мәхәлләдә үз мәдрәсәсе булган, Кенәрнең вак тартмачылары мари ягына сәүдә эше белән йөргәннәр.

Курсалар — көрәшче. Казан артында татарча көрәшнең бөтен нормасы, әдәп-әхлагы, методикасы Курсада эшләнгән. «Курсалар килгән!» — шул хәбәр ишетелгәндә, Казан арты сабантуйларында таза гына ирләр җиргә иңеп алалар иде. «Курсалар килгән!» — бу инде зур, чын көрәш була дигән сүз. Колхозлар төзегәндә, аларга исемне дә шулай биргәннәр: «Батыр Курса», «Көрәш Курса».

Кызыклы күренеш: Казан артыннан чыккан шанлы-шаулы ике мәгърифәтче. Ш. Мәрҗани һәм Т. Яхин — көрәшче булганнар. Ш. Мәрҗани яшьлегендә бик каты көрәшкән, батыр кала алмаган сабантуйларында начар кәеф белән йөргән. Таип исә яшьлегендә бик күп авылларда батыр калган... Боларның традициясе Арча — Балтач ягында әле дә яши...

Арча ягындагы Кәче авылы ирләре — гасырлар буе крушниклыкта. Идел пристанена барып, гомер буе йөк төягәннәр, бушатканнар. Халкы җор, елдам, үткен. Холыклары да эленеп кенә тора — гомер буе юлда, пристаньда. Ф. Сәйфи-Казанлы хикәяләренә күп материал биргәннәр алар. Базар йөрү, юл йөрү ул — шәхес эшли. Казан артында элегрәк елларда һич тә «Казанга бардым» дип сөйләшмәделәр. «Казан йөрү», «базар йөрү» дип кенә әйтелә иде. «Йөрү» — зур сүз, бу инде атлау гына түгел, ә ил-җир күрү, агай-эне, татар, урыс, мари, мордва белән аралашу, ипле тормыш кору мәсьәләсен киңәш-табыш итү дигән сүз. Базар, сәүдә юлы, нәкъ крестьян хезмәте кебек үк, шәхес ясый, шәхес эшли. Ә андый «эшләнгән» шәхес киләчәктә, һичшиксез, кирәк булачак. Бәдри солдатны хәтерләгез: «Юк, сез не имеешь права кеше баласын тотып торырга...» Бу шәхес тарихта үз сүзен әйтәчәк, бу — патша түрәсе яткырып сукканда «ләббәйкә» дип тормаячак...

Казан артында элекке авылларны «ак як», «кара як» дип бүлгәләп йөрткәннәрен әйткән идек. «Ак як» — базар белән әвәрә килүчеләрдән ясала. Мәсәлән, Арча асты Күпербаш авылы. Базар көн — болар өчен бәйрәм. Күпербаш халкы бу көнне өйдә тәмле ризык пешерә, бер йомышлы булмаса да, базарга бара, иң яхшы киемнәрен кия, кызлар бизәнә, шулай бөтен авыл Арча базарына китә. Кайтышлый өйләренә

кеше төшерәләр, туган-тумача, күргән-белгәнне чәйгә алып керәләр, кунак итәләр. Бу гадәт аларда Арча базары беткәнче яшәде. Күпербаш гомергә «ак» булды.

1919 елда 2 нче Армиянең Революцион хәрби Советы члены Сафонов Үзәк Мөселман Хәрби коллегиясенә менә нәрсә хәбәр итә: «Арчадан Вятские Поляныга китәр алдыннан халык безгә үз фикерен белдерде. Кешеләр Совет властеның нәрсә икәнлеген сезнең белән яшәгәндә генә белдек, диләр. Бу аңлашыла да: биредә, без бар чакта, байлар һәм полицейскийлар акыруы булмады». Икенче бер документта: «Арчада... һәм күрше-тирәдәге кайбер авылларда всеобуч көннәре байраклар, музыка һәм речь сөйләүләр белән үткәрелде».

Казан артыннан — эшлекле, һөнәрле халык арасыннан чыккан укымышлылар шулай туп-туры Октябрь революциясенә хезмәткә күчте.

...Алдарак Арча турында сүз барган иде.

Тукай һәм... аның әсәрләрендә бер генә тапкыр да телгә алынмаган Арча. Әмма, тарихта символик мәгънәләр, символик киселешләр-очрашулар бар. Тукай 1912 елның кышында Арча урысының мич башында сөякләрен җылытып яткан. Алты ел үткәч шул ук Арчада Тукайның рухи дусты Мәхмүт Дулат Али булачак: 1910 елда Тукай Казанда аларның флигелендә яшәп алган, Мәхмүт белән дуслашкан, «иптәшем Мәхмүдкә ядкарь» дип рәсемен бүләк иткән, Мәхмүт исә — РСДРП члены...

Мулланур Вахитов та эш-гамәлләре белән Тукай эзләренә тоташа. Символик деталь: Мулланурны Көңгердә туган дип йөртсәләр дә, ул Казанда туган һәм Шиһаб Мәрҗани мәчете каршындагы метрикага теркәлгән! Тукай сөякләрен җылыткан Арчада Мулланурның әнисе Өммегөлсем апа була. Аны Казанны ак чехлар алгач Арчага Исхак Казаков алып килә һәм Арчадагы Азин дивизиясе штабы комиссары Минһаҗ Конов кулына тапшыра. М. Конов исә Өммегөлсем апаңны Вятские Поляныга (Малмыж аркылы) чыгарып Мәскәүгә озата. Ә бу көннәрдә Малмыжда хәрби революцион трибунал Ишми ишан эшен карап ята...

Тукайны биргән Казан арты — шагыйрьнең бишеге әнә шулай вакыйгаларга, шәхесләргә, сыйнфый аңга, шигърияткә бай як. Ул вакыйгалар, ул хәлләр, шәхесләр, ул табигать аерым-аерым хис булып, матдә, тойгы булып 26 ел буе

шагыйрь Тукайны ясаган, ул шигъри бишек аны гомеренең иң авыр вакытларында тибрәткән. Әнә шуңа күрә авыруы бик көчәйгән, шәһәр атмосферасы һәм социаль мохит рухын бик нык кыскан вакытларда ул туган ягына — шул бишеккә кайтып киткән, шунда рухына ләззәт тапкан.

Казан арты — тарихтан чыгарма түгел, анда нәкъ башка җирдәге кебек канэчкеч алпавыт, кулак, надан мулла, куштан крестьян, ришвәтче түрә, әлбәттә, булган. Мактаулы Кышкар мәдрәсәсендә дә кадимче, искелеге белән дан тоткан баш мулла дамелла Исмәгыйль хәзрәт булган. Ф. Әмирхан яза: «Мәрҗани вакытының бик мәшһүр Кышкар дамеллаларына... бер дә әһәмият бирми, аларны наданга саный иде» (Сайланма әсәрләр.— Казан, 1956.— 2 т.— 458—459 бб.). Әмма бөек мәсәлче И. А. Крыловны тәрҗемә иткән, балалар өчен күп китап бастырган мәгърифәтче Таип Яхин — шул тискәре хәзрәт кулында укыган. Ихтимал, кадимче Исмәгыйль хәзрәтнең искелеге Таип шәкертне яңалыкка — рус әдәбиятына этәрүче сәбәпләрнең берсе булгандыр. Русларда мондый мәкаль бар: «Нет худа без добра»... Таип Яхинның нәсел шәҗәрәсе миңа бик таныш. Аның бабасы Яхья — Теләче ягындагы Күкчә авылы мулласы. Яхъяның бер оныгы, шигырьләр язучы (кайбер шигырьләре сакланган) Мөхәммәтгариф — минем ерак бабам. (Тукай этисе белән бутыйсы түгел!) Икенче оныгы Таип Яхин, әлеге мәгърифәтче, китапчы, дөньяга карашларында гаять дәрәҗәдә каршылыклы, ләкин яктылыкка берөзлексез юл эзләүче шәхес... Казан артының тискәре кешеләре шул Исмәгыйль хәзрәт кенә булсачы! Аларның бит сәүдәгәрләр арасында берәр терәге була. Тискәре идеология һәрчакта да акчага, байлыкка нигезләнеп туа. Казан артының кадимче муллаларын Казан артының ук кадимче сәүдәгәрләре акча белән тәэмин итә. Әйтик, Казанның кадимчесе, сәүдәгәр Вәли (Арча ягы Аты авылыннан) гел искелекне яклый. Ф. Әмирхан «У-у... шатлык» дигән фельетонда болай яза: «Утыз еллар чамасыннан Әхмәтҗан абзый Сәйдәшев туганына йөз ел буладыр. Бу елны Аты Вәли ысулы җәдидә кабул итеп, Әхмәтҗан абзыйны түрәләр хозурында эш йөртергә Петербургка җибәрергә агитация ясаячактыр». Китапның артында укыйбыз: Аты Вәли — «Казанның кадимчеләр яклы бер сәүдәгәре» (592 бит). Сәрдә авылының Гыйләҗ мулла да кадимчелек фронтының алгы рәтендә тора. Кадим-

че — искелек тарафдары беркайчан да тик ятмый: ул яңалыкка каршы һәрвакыт актив көрәш алып бара, китап яза, вәгазь сөйли, эш йөртә. «Яңа чүпләр» дигән фельетонында Ф. Әмирхан Гыйләҗ мулланы тешләп уза... «Әүвәлдә,— ди ул,— Ишми муллалар, әллә нинди Гыйләҗ муллалар һәзлиятләрен (көлеп, мыскыллап язылган әсәр.— *М. М.*) үз исемнәре белән, яшеренми, качырынмый нәшер итәләр иде» (шунда ук — 359 бит).

Казан арты кадимчеләрен Ф. Әмирхан, Г. Камал, Тукай җае килгә саен тәнкыйтьләп торалар. «Ялт-Йолт» идарәсеннән сораулар» исемле фельетонында Тукай, уйлап чыгарылган исем астында булса да, туган ягы кадимчесен эләктерә: «Мәскәү губернасы Олуг Мәңгәр волостеның Шилметдин Җонлыбияләев»,— ди. Бу исемнең, һичшиксез, конкрет бер кешесе күздә тотылган инде, без аны белмибез генә...

Тукай ул заманда ат белән йөргән, юлы болай: Өчиле, Югары Аты, Түбән Аты, Кушлавыч... Казанга таба: Өчиле, бер рәт Аты, Кишмәт, Тимерче, Әйше, Чыпчык, аннан — Балавыз урманнары, хәзерге Ливадия ял йорты, Казанка буйлап астан кышкы юл, Подлужная урамы, аннан өскә таба хәзерге Суворов училищесы яныннан Толстой яшәгән йорт — аннан К. Маркс урамы. Шагыйрьнең юльязмаларында Казан артына тулы икътисади, мәдәни, рухи яктан бәя бирелә. Кишмәттән чыгып болын буйлап килсәң — Тимерче авылы. Боларда элек (Казанка харап булганчы) гел болын, гел печән кибәне генә иде. Тукайда ассоциация: «Бу авылның мулласы» Әннә солул Җәдидә...»че («Ысул җәдидәне юкка чыгара торган тимер кебек нык китап»,—*М. М.*) һәм әллә нинди исемнәр белән ысулы җәдидәгә каршы китаплар чыгарган каһарман». Шунда ук Тукай мондагы печән кибәннәренә игътибар итә һәм болай ди: «Бер данә диярлек арыш, богъдай кибәне булмаса да, печән кибәне бик күп дәрәҗәсендә. «Моны күргәч: «Мулласы» «Дин вә мәгыйшать»че булган бу авылның халкы да печән ашыймы әллә?— дигән фикерләр килде» (Шунда ук).

Күрәсең, Казан артында кара таплар җитәрлек булган. Казан арты реакцион фикеренең башында Ишми ишан торган. Аның чыгарган реакцион китаплары, гомумән, эшчәнлеге Казан алпавыты Габдрахман Ишморатов тәэминатында булган. Казан артының бик матур бер почмагында — өч яктан урманлы Казанка елгасы буенда алпавытның җәйге

утары, ат заводы, кирпеч сугу, такта яру заводлары булган. Ул як авылларына мулла кую, мәчет салдыру, яңа мәхәллә ачу — барысы да Ишморатов карамагында. Яңача промышленность корган Ишморатов идеологиядә кадимчелекне бик нык яклаган һәм Казан артындагы кара реакция җитәкчесе Ишми ишанның яңалыкка каршы гел өстерәп торган. Ишморатов акчасына Ишми ишан Казанда «Икамәтель борһан...» дигән китап та бастырган — бөтен фикере яңалыкка каршы. Бу турыда 1969 елда «Казан утлары» журналының 12 санында язылган иде.

Безнең бурыч шул ук — Казан артының нindидер үзенчәлеген ачу, шул үзенчәлекләрнең тарихи җепләрен эзләү иде. Алдарак без Казан артының сыйнфый аңга зирәк булуын, эшкә-хезмәткә һәвәскәр булуын ачарга тырышкан идек. Кырыс чырайлы тәнкыйтьче, ул урыннарны язганда да, авторның күз алдыннан китмәгән иде. Әмма тарихи-матур фактлар бар. Кантарлы-балчыклы, ташлы-ярлы, чокырлы шул Арча, Әтнә ягы гаҗәп кызыклы биографияләрне һаман тудырып тора. Арча районының иң чигендә бәп-бәләкәй бер авыл бар. Исеме — Мирҗәм. Әнә шул Мирҗәм соңгы 40 елда дөньяга өч герой бирде инде. Болар: Советлар Союзы Герое Нәкыйп Сафин, Социалистик Хезмәт Геройлары Дания Галимова (авыл хуҗалыгы) һәм Галимулла Әсхәдуллин (эшче). Кечкенә генә бер авыл өчен күп, Мирҗәмдә бит нефть чыгарылмый, мамык үстерелми. Бу төбәкнең тарихына керсәң — кызык. Ун-унбиш йортлы авылда туып-үскән Илсур Шәйхетдиновны (алда телгә алынган авыл — Әрнеш егете) бүгенге көндә бөтен Европа белә. Социалистик Хезмәт Герое Илсур Уренгой — Помары — Ужгород линиясендә газ үткәрә[1]. Алда телгә алынган авыллардан тагын әллә ничә герой чыккан: Түбән Орыдан Гатаулла Салихов, Иске Кишеттән генерал Гани Сафиуллин, Арчадан Валентин Ежков — Советлар Союзы Геройлары. Түбән Көектән Нургали Бариев, Шушмабаштан Шәрифулла Сәгъдуллин — Социалистик Хезмәт Геройлары. Казаннан килеп Яңа Кенәрдә яшәгән укытучы Стелла Габдрахманованың биографиясенә күз салсак, бу профессиядә сирәк очрый торган Социалистик Хезмәт Герое дәрәҗәсенә лаек булган Стелланың да

---

[1] Мәгълүмат 1980 нче еллар уртасына карый.

ата-анасы Әтнә ягы Кышлау авылыннан икән... Әле күптән түгел генә Казанбаш егете Мирбат Хәстиевкә дә Социалистик Хезмәт Герое исеме бирелде.

Дөбъяз ягына, Балтач төбәгенә мин кермим, геройлар саны артачак, Казан арты булмаган башка яклар үпкәли калырлар.

Казан арты — шагыйрь бишеге әнә шундый...

Тукайның бу якта тууы очраклымы? Һәм ике гасыр ялгамында тууы очраклымы? Юк, очраклы түгел, тарихи вакыйгалар, сыйнфый көрәш белән кысылган тар Казан арты үз фикерен әйтү өчен бер шәхесне тудырмый кала алмый иде. Ул шәхес әлеге фикерне әйтү өчен шагыйрь булып туарга тиеш иде һәм нәкъ шул чорда — заман алмашынган чорда туарга тиеш иде. Заманның бер этаптан икенче этапка күчкәндә җиргә үз улын биреп калдырып, тарихи миссиясен үтәп китүе булган инде ул. Тукайның шагыйрь булып тууы да табигый иде: кысылган халык күңеленең, җыр-бәет, «Кыйссаи Йосыфы» белән, «Таһир-Зөһрә» белән тәрбияләнгән халыкның йөз еллар эчендә бер кисәк ахак бирми калуы мөмкин түгел иде.

Тукай әнә шундый — заман ихтыяҗларын үзенә миссия итеп алган тарихи шәхес буларак, шул бишектә дөньяга килде.

ЯХЪЯ БИНЕ СӘФӘРГАЛИ (1758—1838) ИҖАТЫ

XVIII гасырның соңгы чирегендә әдәбият мәйданына чыгучылар арасында Яхъя хәзрәт буларак шөһрәт казанган зат та мәгълүм. Аның исеме риваятьләргә уралып яшәгән һәм бу риваятьләрнең бер өлеше безнең көннәргә кадәр килеп җиткән.

Яхъя хәзрәт бине Сәфәргали бине Арслан әл-Бәрәзәви 1758 елда хәзерге Татарстан җөмһүрияте Әтнә төбәгенең Олы Бәрәзә авылында игенче гаиләсендә туган. Аның Оренбург ягындагы Каргалы авылында укуы хакында хәбәрләр калган. Яхъя хәзрәт исемен татар тарихына башлап кайтаручы шәхес — Шиһабетдин Мәрҗани. Аның Казан өлкәсе



Борынгы болгар кабер ташы. Иске Ашыт.
Древнебулгарская эпитафия. Старый Ашит.



XVI гасыр кабер ташы. Иске Иябаш.
Эпитафия XVI в. Старый Яваш.

Шиһабетдин Мәрҗани (1818—1889).
Шигабутдин Марджани (1818—1889).

Мәчет. Кышкар.
Мечеть. Кшкар.

Габдулла Тукай (1886—1913).
Габдулла Тукай (1886—1913).

Мәчет. Казиле.
Мечеть. Казылино.



Иске зират урыны. XVII—XVIII гасырлар. Ташкичү.
Старое кладбище. XVII—XVIII вв. Ташкичу.

Кәче иленең XVII гасырда куелган каберташ саклана торган зираты.
Кладбище села Качелино, где сохранилась эпитафия XVII века.

XIX гасыр кабер ташы. Яңа Ашыт.
Эпитафия XIX в. Новый Ашит.

XIX гасыр кабер ташы. Яңа Кенәр.
Эпитафия XIX в. Новый Кинер.

XIX гасыр ахырында куелган кабер ташы. Яңа Кенәр.
Эпитафия конца XIX в. Новый Кинер.

XIX гасыр кабер ташы. Мәмсә.
Эпитафия XIX в. Мамся.

тарихына багышланган хезмәтендә Яхъя хәзрәткә багышланган берничә сәхифә бар[1].

Ул — Кышкарда алтын әйберләр ясау белән шөгыльләнгән Сәгыйд хәзрәт (...— 1813), Кушәрдән Габбас Яушев (1763—1853), Сәрдәдән Госман хажи, Уфа өязеннән музыкант Җәгъфәр ишанның (...—1831) замандашы булган.

Яхъя хәзрәт турында «ул җеннәр белән кайнаша» дигән риваять тарала. Шиһабетдин Мәрҗани аның үзенә күрә бер фәлсәфә галиме булуын фараз итәрлек күп кенә мәгълүматлар теркәп калдырган. Яхъя хәзрәт, сакланып калган язмаларга караганда, иске татар һәм фарсы телләрендә касыйдәләр (шигырьләр) язган. Язганнары арасында Аллаһуны тану үзенчәлекләре турындагы фикерләре күренә. Ул шулай ук гипноз һәм табибчылык белән шөгыльләнгән. Яхъя хәзрәт 1838 елда Шекә авылында үлгән. Аның кабере, ташындагы язулары мәгълүм. Археографик экспедицияләр вакытында аның кулы белән язылган китапларның күп булуы, ул аларны «җеннәр, кунаклар тарафыннан күчерүе» хакында күп сүзләр сакланганлыгы ачыкланды.

Тик әлегә Яхъя хәзрәт кулы белән язылган зур бер китап кына мәгълүм. Ул китап Татарстан Фәннәр академиясендәге мирасханәдә, 39 кол., 54 эш шифры белән саклана. Кульязмадагы кайбер мәгълүматлар аның 1798 елда язылуын раслыйлар. Анда Яхъя хәзрәтнең «Васыятьнамә» исемле зур гына көйле әсәре бәян ителә.

«Васыятьнамә» иске татар телендә укыту-методика мәсьәләләренә багышланып язылган. Анда, XVIII гасыр ахырында татар мәгърифәтчеләрен борчыган проблемалар тасфирлана. Пугачев хәрәкәте тәэсирендә XVIII гасырның соңгы чирегендә татарларга карата Русия империясе уздырып килгән милли-дини изү сәясәтен йомшарта. Татарлар үз мәгариф системаларын үстерү өчен элек булмаган автономия алалар. Көн тәртибенә шул мәгариф системасын аякка бастыру мәсьәләсе килеп баса.

Яхъя хәзрәт белем нурын «кешенең тәмләткече» дип бәяли:

---

[1] Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.— Казан, 1900.— 243—250 б.

Хәрдәлидер безгә бөс гыйлем гыйрфан,
Дәхи сыйххәт ула әгъмалү икән.
(Тәм бирүчедер безгә гыйлем, белем,
Сәламәт ясаучыдыр гамәлне анык белү.)

Шагыйрь бу дәвердә галимнәрнең һәр төрле фәннәрдә бик аптырауларын, алдашып кына катлаулы ситуацияләрдән чыгуларын яза:

Замана ичрә галимнәр чугалды,
Фәнун мөшкиләт һәм шаигъ улды.
(Галимнәр бу заманда буталып беттеләр,
Фәннең кыенлыгы һәркемгә мәгълүм булды.)
Мөдәрисләр гаҗәиб тәдрис идәрләр,
Шәригать гыйльмене тәлбис идәрләр.
(Мөдәррисләр гаҗәп рәвештә укытырлар,
Шәригать гыйлемен хәйлә һәм алдау итәрләр.)

Мәдрәсә җитәкчеләренең бу халәттә бер дә белемнәрен тирәнәйтергә теләкләре юклыгы күренә:

Аһәм белмешләр анлар мөшкиләти,
Мәгариф гыйльмидә юк илтифати
Бу халь илә кичеп гомер газизи
Мәгарифдә боларның юк тәмизи.
Бу мөшкиләти халә калмакта болар,
Мәгарифдән кире калмакта болар.
(Иң әһәмиятлесе, алар авырлыкны белделәр.
Мәгариф гыйлемендә игътибарлары юк.
Шушы хәлдә гомерләрен уздырдылар,
Мәгарифтә боларның пакьлеге юк.
Шушы наданлык хәлендә калдылар болар,
Мәгарифтә артта калдылар булар.)

Яхъя хәзрәт укымышлыларны, мөдәррисләрне мәгарифтәге торгынлык, канәгатьлек белән яшәүләрен гаепли:

Мәгарифтә канәгать әйләмешләр,
Балигатьне сәнагать әйләмешләр.

Яки:

Җәһаләтләрни вә гыйрфан санарлар,
Дәхи шикләрни икан санарлар.
(Наданлыкларны фән санарлар,
Тагын шикле әйберне исбатланган санарлар.)
Гакыйдә гыйльмени белмәс тәгаен,
Дәлаилдән табалмас аңа тимәкен
(Иман гыйлемен ачык белмәс,
Аңа адекват җавапны дәлил тапмый.)

Яхъя хәзрәт мәгарифне үз дәверенең иң мөһим мәсьәләсе итеп исәпли:

Мәгарифдер гыйлемдән асыл максат.
Мәгариф юк, голүм күбдер ничек сад.
(Галимлекнең асыл максаты мәгариф,
Мәгариф юк икән, барлык фәннәр дә
«Сад» хәрефе кебек каты булырлар.)

Яхъя бине Сәфәргали «Васыйятьнамә»сендә уку-укыту мәсьәләләре бик тәфсилләп бәян итеплә. Аның фикерләре — XVIII—XIX гасырлар чигендәге алдынгы татар иҗтимагый фикерләренең бер чагылышы. Ул үзенең карашларын заманының традициясе буенча, назым белән язган. Аның әсәрләрен укыгач, XVIII гасыр ахырында да татар халкында, хәзерге чордагы кебек үк, милли укыту системасын камилләштерүнең иң актуаль мәсьәлә булуына төшенәсең.

Яхъя бине Сәфәргали мирасы Габдерәхим Утыз Имәни, Кол Мөхәммәд, Габденнасыйр Курсави, Әбелмәныйх Каргалыйлар дәверенең бер кыйммәтле-әһәмиятле истәлеген тәшкил итә.

ГАБДЕННАСЫЙР КУРСАВИ
(1776—1812)

XVIII гасырның соңгы чиреге — татар халкының рухи үсеше тарихында мөһим дәвер. Моның сәбәпләре нидән гыйбарәт соң? Барыннан да бигрәк татарларның 1552 елдан бирле дәвам иткән милли-азатлык хәрәкәте нәтиҗәсендә халкыбыз үзенең этник бөтенлеген, телен, динен, әдәбиятын, сәнгатен, яшәү рәвешен, тарихи территориягә хокукын саклап калды.

Рухи-мәдәни күтәрелешнең яңа этабы 1775 елдан соң башлана. Язучылар, шагыйрьләр, галимнәр исәбе ишәя. Без XVIII гасыр ахырында иҗат мәйданында мәгълүм булган Габдерәхим Утыз-Имәни, Таҗетдин Ялчыгол, Ишнияз бине Ширнияз, Яхъя бине Сәфәргали, Кол Мөхәммәд, Рәхимкол Әбүбәкер улы, Вәлид Каргалый һәм башка шәхесләрнең исемнәрен беләбез. Алар үзләренең әсәрләрендә яңа иҗтимагый һәм фәлсәфи фикерләр күтәрделәр. Соңгылары нигезендә тәрбияләнгән татар укымышлылары арасында

XIX гасыр башында Габденнасыйр Курсави эшчәнлеге аерым урын алып тора.

XVIII гасыр ахыры — XIX гасыр башында үскән татар иҗтимагый фикере нинди мәсьәләләр тирәсендә төенләнә соң? Бу барыннан да бигрәк ике йөз елдан артыкка сузылган рухи инкыйраз шартларында мөселман мәдәниятеннән, мәгърифәттән, фәннән артта калу нәтиҗәсендә туган надан-лык фәлсәфәсе белән көрәш мәсьәләләре иде. Шул мәсьәләләрнең татар өчен иң мөһимен — кешенең дөньяны танып белүгә хокукы барлыгын исбатлаган шәхес — Габденнасыйр Курсави булды. Тәүге мәртәбә аның тормыш юлын өйрәнеп, документлар нигезендә мәшһүр галим Шиһабетдин Мәрҗани бәян итте[1]. Ш. Мәрҗанидән соң аның тормышы татар галиме Ризаэтдин бине Фәхретдиннең атаклы «Асәр» китабында тасвирлана.[2]

Габденнасыйр Курсавиның тормышы һәм фәнни эшчәнлеге бүгенге татар галимнәрен дә кызыксындыра. Бу хакта фәлсәфә фәннәре докторы Я. Г. Абдуллинның һәм башкаларның мәкаләләре мәгълүм.[3]

Галимнең тулы исеме — Әбүннасыйр-Габденнасыйр бине Ибраһим бине Йармөхәммәд бине Иштирәк әл-Курсави. Ул 1776 елда хәзерге Татарстанның Арча төбәгенә караган Курса авылында сәүдәгәр гаиләсендә дөньяга килгән. Аның әнисе Миһербан бинте (кызы) Әмин бине Мансур, Максабаш авылында туган. Бу уңайдан күңелгә кызыклы сорау килә: Габденнасыйр Курсавиның ерак бабасы Иштирәк — Максабашта 1681 елда вафат булган Имәй суфыйның улы Иштирәк хафиз түгелме? Иштирәк хафиз тарафыннан әтисе каберенә куелган таш безнең көннәргә кадәр сакланган.

Габденнасыйрның әтисе Ибраһим 1205 (1791) елда вафат. Димәк, улы дөньяга килгәндә ул шактый ук өлкән яшьтәге кеше булган. Габденнасыйрның кыз карендәше Мәрхабә Мәчкәрә авылына — Габдулла бине Габдессәлам әл-Мәчкәрәвигә тормышка чыккан.

---

[1] Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.— Казан, 1900.— 168—175 б.

[2] Ризаэтдин бине Фәхретдин. Асәр.— Оренбург, 1903.— 3 җөзьә.— 195—230 б.

[3] Абдуллин Я. Алдынгы фикер иясе // Социалистик Татарстан, 1976, 11 ноябрь; Хәйруллин Ә. Мәгърифәтче галим Габденнасыйр Курсави // Совет мәктәбе.— 1976.— № 11.— 58—60 б.

Булачак галим башлангыч белемне Мәчкәрәдәге (Кукмара төбәге) Мөхәммәдрәхим ахуннан ала. Соңыннан Бохарага барып Ниязколый әт-Төрекмәни мәдрәсәсендә укый. Аннан кайткач Мәчкәрәдәге җизнәсе һәм аның уллары Гобәйдулла, Муса һәм Мөхәммәджан ярдәмендә зур мәдрәсә салдырып, анда укыта башлый; шул ук вакытта Курсада имам, хатыйб вазифаларын да башкара.

1808 елда Габденнасыйр Курсави кабат Бохарага бара һәм анда үзенең исламга карата булган реформаторлык карашларын тарата башлый. Аның фикерләре консерватив Бохара руханиларының ярсулы каршылыгына очрый, ләкин соңгылары иман һәм шәригать мәсьәләләре буенча барган ачык бәхәсләрдә җиңеләләр. Җиңелүләренә карамастан алар Курсавины эзәрлекләүдән туктамыйлар, хәтта Бохара әмиренә мөрәҗәгать итәләр. Уңны-сулны аермаган әмир татар галименнән карашларыннан баш тартуны таләп итә, киресенчә булганда үлем җәзасы белән яный. Габденнасыйр хәзрәт дусларының киңәше буенча «ваз кичтем» дип, үлемнән котылып, ватанына кайтып китә. Ләкин анда да ул үз карашларын таратуны дәвам итә. Бохара әмире бу хакта ишетеп, үлгәнче Габденнасыйрны җәзалап үтермәгәненә үкенеп яшәгән дигән хәбәрләр бар.

Габденнасыйр Курсавиның яңача фикерләве вакытында күпчелеге наданлык эчендә кайнаган имамнарга ошамый, алар аның туры сүзеннән, тирән белеменнән куркалар. Габденнасыйр булган мәҗлесләргә барырга муллаларның кыюлыгы җитми. Шундый шартларда галимне ватанында да эзәрлекләү башлана.

1812 елда ул хаҗ сәфәренә кузгала, Истанбул шәһәрендә ваба чире (холера) белән авырып үлә һәм аның гәүдәсе Истанбулның Өскедар зиратына җирләнә.

Габденнасыйр Курсавиның хезмәтләре татар иҗтимагый фикеренең рационалистик юнәлештә үсеп китүенә зур ярдәм итте. Югыйсә, Бохара мәдрәсәләре Урта Азияне әле тагын йөз ел дәвамында схоластик торгынлыкта тоткан кебек, татарлар да шул иске карашлар белән генә яшәрләр иде.

Галимнең шәкертләре арасыннан да күп кенә күренекле шәхесләр чыккан. Аларның кайберләренә тукталып үтик.

Мөхәммәдәмин бине Сәйфулла әл-Наласави — шагыйрь

һәм хокук белгече. Соңыннан Каһирәдәге әл-Әзһар университетында фарсы теле укытучыларының берсе, 1833 елда Каһирә шәһәрендә вафат була.

Ногман бине Әмир әс-Симәни. Ул, Габденнасыйр хәзрәт киткәч, Курсада мәдрәсәнең мөдәррисе булып кала һәм остазы башлаган «Коръән тәфсире»н эшләп бетерә. Татар дөньясында бу тәфсир «Ногмани тәфсире» буларак мәшһүр. Аларның автор кулъязмалары Мәчкәрә авылында сакланып, соңыннан Ханкирмәнгә (Касыйм шәһәре) барып эләгәләр, ә аннан Казанга, Татарстанның дәүләт музеена кайтарылалар.

Габденнасыйр Курсавиның шәкертләреннән шагыйрь Җамалетдин бине Шәмсетдин әс-Сабави (1780—1866), Ниґъмәтулла бине Биктимер әл-Эстәрли (Тукаев, атаклы Эстәрлебаш мәдрәсәсе мөдәррисе), Хәбибулла бине Рәфыйкъ әл-Нәдери, Фәхертдин бине Хәбибулла әл-Хаҗи Тархани (шагыйрь-акын), Әхмәд бине Сәгыйдь әш-Шырдани, Надир бине Исхак әл-Кошмани, Таиб бине Зәедкол әл-Верхурали, Зәйнулла бине Үлмәс әл-Калкани, Габдулла бине Әмирхан әл-Верхурали, Габдел-мөэмин бине Фәиз әл-Мшләви, Әхтәм бине Бикмөхәммәт әл-Йармунчави, Тимербәк бине Вилдан әл-Куганакый, Габделгафур бине Габделмәҗид әл-Уфава һәм башкалар була. Бу шәкертләрнең чыгыш географиясе генә дә Габденнасыйр Курсавиның галим буларак карашларының тиз арада Казан ягыннан Верхеуральск, Әстерханнан Уфага кадәр таралган, танылган булуын күрсәтә. Аның һәр шәкерте татарның мәгърифәтен күтәрүгә, аннан Шиһабетдин Мәрҗани, Каюм Насыйри, Хөсәен Фәезханов кебек фикер ияләре үсүгә җирлек хәзерләгән.

Бөек галимебездән калган каләм мирасы да зур булган, ләкин аларның күбесе басылмыйча калган. Хезмәтләренең күбесе, бөтен мөселман дөньясына төбәлгәнлектән, гарәп телендә язылган.

Басылып чыккан хезмәтләреннән фәлсәфи темага караган «Әл-иршад лил гыйбад» («Надан кешеләрне изге юлга күндерү») мәгълүм. Ул әсәрдә суфыйчылыкның асылы аңлатыла. Бу китапта кешенең таныш белүгә дәгъвасы барлыгы исбатлана.

Нәшер ителмәгән хезмәтләреннән «Китабел-ләваих» («Белдерүләр бәян иткән китап»), «Шәрхелганаиде Нәсифия кадим» («Борынгыча Нәфиси инануын аңлату»), «Шәрхелгакаид эн-Нәсифия җәдид» («Яңача Нәсифи инануын аңлату»), «Рисаләи исбател-сыйфат» («Сыйфатларны исбатлау әсәре»), «Китабел-нәсаих» («Нәсыйхәтләр китабы»), «Шәрхе мохтасарелмәнар» («Кыскартылган юл күрсәткеч аңлатма-

сы»), төрки телендә «Һәфтияк шәриф тәфсире» булганлыгы мәгълүм. Моннан тыш Габденнасыйр Курсави язган кечерәк әсәрләр, хатлар сакланган. Аның тормыш юлын һәм иҗат мирасын яңадан, җентекләп өйрәнү таләп ителә.

ШИҺАБЕТДИН МӘРҖАНИ — ЯКТАШЫБЫЗ

Һәр халыкның мәдәни-иҗтимагый үсешенә көчле этәргеч биргән, аның үткәнендә тирән эз калдырган эшлеклеләре — шәхесләре була. Шундый шәхесләрнең берсе — Шиһабетдин Мәрҗани. Татар халкы тарихында аның эшчәнлеге аерым урын алып тора. Галимнең мирасына беренчеләрдән булып Мифтахетдин Акмулла игътибар итте. Ул 1892 елда Казанда дөнья күргән «Дамелла Шиһабетдин хәзрәтнең мәрсиясе» әсәрендә горурланып: «Хәмде миллаһ, бу дийардә бездән чыкты Мәрҗани Шиһабетдин ахунд хәзрәт»,— дип язды.

Шиһабетдин Мәрҗани эшчәнлеге атаклы татар галиме Ризаэтдин бине Фәхретдин хезмәтләрендә дә чагылыш тапты.

1915 елда татар зыялылары галимнең тууына йөз ел тулуга багышланган күләмле (639 бит) «Мәрҗани» җыентыгын (китабын) дөньяга чыгаралар. Әлеге китапта Газиз Гобәйдуллин (1887—1938), Шәһер Шәрәф (1879—1938), Таһир Ильяси (1881—1933), Галимҗан Баруди (1857—1921), Габдулла Гыйсмәти (1883—1938), Борһанетдин Шәбкәви, Ризаэтдин бине Фәхретдин (1859—1936), Йосыф Акчура (1876—1935), Габдерахман Гомәри (1867—1933), Буа Нургали Хәсәнов (1852—1919), Габдерәшит Ибраһимов (1857—1944), Әхмәтзәки Вәлиди (1890—1970), Морад Рәмзи (1855—1934), Әхмәтһади Максуди (1868—1941), Һади Атласи (1876—1937), Хәсәнгата Габәши (1863—1936), Борһан Шәрәф (1883—1943), Борһанетдин Мәрҗани һәм башка галимнәр үзләренең мәкаләләре белән катнашалар.

Соңгы елларда Шиһабетдин Мәрҗанинең гыйльми мирасы мәсьәләләре белән әдәбиятчы-галим Хәй Хисмәтуллин, тарихчылардан академик Миркасыйм Госманов, Мөнир Йосыпов, фәлсәфә галиме Айдар Юзеев һәм башкалар шөгыльләнәләр.

Галимнең бай мирасы белән бүгенге татар укучылары җитәрлек дәрәҗәдә таныш түгел. Аның хезмәтләре киң даирәгә бик кечкенә күләмдә генә җиткерелгән, Урта Идел буйлары тарихына багышлап язылган ике томлык зур кита-

бы гаять дәрәҗәдә кыскартылып, структурасы үзгәртелеп нәшер ителде[1].

Шиһабетдин Баһаветдин улы Мәрҗани 1818 елның 3 (15) гыйнваренда Ябынчы авылында мулла гаиләсендә дөньяга килә. Яшьтән үк бик зирәк, үзенчәлекле фикерләүче бала булып үсә. Аның бабалары чыгышлары буенча Әтнә төбәгендәге Мәрҗан, Комыргуҗа авыллары белән бәйләнгәннәр. Мәрҗаниләр нәселендә китап күчерүчеләр, шәкертләр тәрбияләүче укымышлылар, зыялылар күп булган. Шиһабетдин Мәрҗанинең нәсел шәҗәрәсе түбәндәгечә: әтисе Баһаветдин (1784—1856), бабасы Сөбхан (1747—1834) бине Габделкәрим (1694—1791) бине Габделтәвваб бине Габделгани бине Габделкотдус әл-Мәрҗани бине Йадәш бине Йадкарь бине Гомәргуҗа[2]. Бу нәселдән Сөбхан баба Җәке авылыннан хәзерге Арча төбәгендәге Кысна авылына килеп имам булган, кабере Кыснада. Галимнең әтисе Баһаветдин Ябынчы авылыннан Ташкичү авылына имам булып килгән.

Баһаветдин хәзрәт Ташкичүдә зур мәдрәсә тоткан. Аның Шиһабетдин, Гыймадетдин, Гафифә әл-Кобра, Гафифә әс-Согра, Фатыйма, Садретдин, Саҗидә, Кыйваметдин, Дәрданә, Сәйдә, Галәэтдин исемле балалары булуы мәгълүм. Шиһабетдин һәм аның ир туганнары Ташкичүдәге әтиләре мәдрәсәсендә белем алганнар. Садретдин — 1912—1918 елларда Казанда чыгып килгән «Кояш» газетасының мөхәррире Зәкәрия Садретдиновның әтисе. Зәкәрия Садретдинов 1930 елның 9 декабрендә Казанда вафат. Галәэтдин — күренекле татар язучысы Мәхмүт Галәүнең (1886—1938) әтисе.

Ташкичү мәдрәсәсен тәмамлаганнан соң, 1838 елда Шиһабетдин Бохарага килеп укый башлый. Бохарадан соң ул укуын Сәмәрканд шәһәрендә дәвам итә. Урта Азия шәһәрләрендәге мәдрәсәләр, бай китапханәләр, андагы галимнәр белән очрашулар, ул якларда укучы татар шәкертләре белән әңгәмәләр Мәрҗанигә көчле тәэсир ясыйлар, аның дөньяга карашы киңәюдә, тарихчы-галим булып җитешүенә этәргеч бирәләр. Ул Урта Азиядә 1849 елга кадәр яши. Анда күргәннәре хакындагы язмалары, белемнәре соныннан галимнең энциклопедик характердагы алты томлык «Вафиятел-әсляф...» китабында файдаланылган. Шиһабетдин Мәрҗани Урта Азиядә гарәп сәяхәтчесе Ибн Фазлан (ул 921/922 елларда Урта Идел буйларында булып киткән) язмаларын табып укыган.

---

[1] Мәрҗани Шиһабетдин. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар.— Казан, 1989.— 412 б.

[2] Әхмәтҗанов М., Ильясова Н. Шиһабетдин Мәрҗани шәҗәрәсе // Казан утлары.— 1989.— № 7.— 177 б.

Ватанына кайткач Мәрҗанине Казанның беренче мәхәлләсенә имам итеп билгеләгәннәр. Атаклы сәүдәгәр Ибраһим Юнусов даими рәвештә мәчеткә матди ярдәм күрсәткән.

Шиһабетдин хәзрәт горур, көчле гәүдәле, тирән белемле, туры сүзле шәхес булган. Ул университет галимнәре белән аралашкан. Аның баш бирмәүчән характеры Ибраһим Юнусовка, консерватор карашлы дин әһелләренә ошамаган. Аны «кяфер» эшләрдә гаепләп, 1860 елда указын алганнар. Мәрҗани үзенең бар көчен яшь буынны тәрбияләүгә, белем бирүгә тоткан, шәкерте Хөсәен Фәезхановның татар укыту системасына реформа ясау турындагы ниятләрен хуплаган. 1876 елда Казанда ачылган Татар укытучылары мәктәбендә Ислам дине тарихы буенча лекцияләр укыган. Галим 1877 елда Казанда уздырылган Тарих, археология һәм этнография җәмгыятенең IV Бөтенроссия съездында Идел буеның борынгы тарихына карата үзе туплаган чыганакларга таянып язылган зур доклад белән чыгыш ясаган. Аның докладьı рус галимнәрен дә бик кызыксындырган, тәрҗемә ителеп рус телендә бастырылган. Шиһабетдин Мәрҗанинең Болгар һәм Казан патшалыклары турындагы докладын съездда академик В. В. Радлов рус телендә укыган. Шиһабетдин хәзрәтнең Иосиф Готвальд белән дус булуы хакында да мәгълүматлар бар.

Шиһабетдин Мәрҗанинең үзе исән чагында ук галим буларак даны еракларга таралган. 1874 елда Англия энциклопедисты Ш. Мәрҗанигә махсус хат язып, аннан биографиясен, рәсемен, хезмәтләре турында мәгълүмат сораган.

1880 елда Шиһабетдин хәзрәт хаҗ сәфәренә юлга кузгалган, Түбән Новгород, Мәскәү, Одесса аркылы Истанбулга килгән. Анда ул атаклы төрек галимнәре белән аралашкан. Аның хаҗга бару юлында күргәннәре турында язган көндәлеген Ризаэтдин бине Фәхретдин «Рихләтел-Мәрҗани» исеме белән аерым китап итеп бастырган. Галим 1889 елда Казанда вафат була. Казан шәһәрендә аның торган йорты, укыткан мәдрәсәсе, хезмәт иткән мәчете бинаалары, Яңа Бистә зиратында кабере саклана.

Шиһабетдин Мәрҗани үз гомерендә бик күп шәкертләр тәрбияләп чыгарган. Алар арасында татарның күренекле шәхесләренең, галимнәренең исемнәрен дә күрәбез: Габделхәбир бине Габделваһаб әл-Мөслими (Казагыстанның Кызылҗар шәһәрендә казак балаларына белем биргән), Хафизетдин бине Насретдин әл-Бәрәнгеви (тарих һәм башка темаларга китаплар язган), Хөсәен Фәезханов (зур галиммәгърифәтче), Җамалетдин бине Габделлатыйф әл-Тинчәле

(тарихчы), Борһанетдин әл-Шәбкәви (Ш. Мәрҗанинең тормыш юлын язучы, аның китапларын күчергән шәхес), Габделгаләм бине Фәезхан (күренекле татар язучысы, мәгърифәтче), Мостафа бине Дауд Чутаи (шагыйрь), Шакирҗан бине Әхмәтҗан Таһири (атаклы педагог, дәреслекләр авторы), Насретдин бине Кәлимулла (китаплар авторы) Хәбибелнаҗар бине Мөхәмммәткяфи Эстәрли (тарих китаплары авторы, Зәки Вәлидинең остазы), Габдерахман Гомәри (журналист, дәреслекләр авторы, нәшир, Әстерхан шәһәреннән) һ. б. Шиһабетдин хәзрәтнең шәкертләре Вятка өлкәсеннән алып Әстерхангача, Пенза якларыннан Кызылҗаргача (Петропавловск, Казагыстанда) җирләрдән җыелып, укып, ватаннарына кайтып аның алдынгы, реформаторлык фикерләрен таратканнар, татар халкының 1905 елдан соңгы чордагы мәдәни-сәяси күтәрелешен әзерләүгә өлеш керткәннәр.

Шиһабетдин Мәрҗанинең татар укучысына яхшырак таныш хезмәте — ике томлык «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар». Аның беренче томы татарларның Россия бәйлелегенә кадәрге тарихына мөнәсәбәтле чыганаклардан, икенче том исә XVII—XIX гасыр чыганакларыннан гыйбарәт. Әлеге ике томлык хезмәт гарәп телендә язылган чыганаклардан, рус елъязмаларыннан, төрки-татар тарихчыларының язмаларыннан, төрле документлардан, шәҗәрәләрдән, каберташ язмаларыннан, риваятьләрдән алынган мәгълүматлардан тора.

«Вафиятел-әслаф...» — галимнең алты томлык хезмәте. Ул борынгы мөселман, төрки, европалы галимнәрнең биографияләрен үз эченә алган.

Шиһабетдин Мәрҗанинең энциклопедик характердагы хезмәтләре урта гасыр мөселман галимнәре әсәрләре үрнәгендә язылган. Югарыда искә алынган әсәрләрдән тыш галимнең Урта Азиянең X—XII гасырлардагы тарихына караган «Горфәт әл-хавакин ли-арфат әл-хавакин», «Гилаләт әз-заман фи тарихи Болгар вә Казан», «Мөнтахиб әл-вафият» һәм дин, шәригать мәсьәләләренә багышланган «Назурәт әл-хак...», «Әл-фаваид әл-мөхәммә», «Ханел-мәгърифә вә хөснел-идрак» һәм башка исемнәрдә утызлап хезмәт язганлыгы мәгълүм.

Мәрҗанинең әсәрләре милләт буларак оешкан татар халкының өлгереп җиткән рухи ихтыяҗларына җавап рәвешендә язылган. Ләкин халкыбыз галимне беренче чиратта тарихчы буларак кабул иткән. Аның китапларында Арча төбәгенә кергән Иске Ашыт, Ташкичү, Кысна, Курса, Кышкар, Түбән Оры авыллары, алардагы мәчетләр, мәдрәсәләр, нәсел шәҗәрәләре тарихларына караган мәгълүматлар туп-

ланган. Шулай ук тарихлары махсус язылмаган авыллардагы күренекле шәхесләрнең тормыш юллары тасвирланган. Мәсәлән, Арча ягындагы Түбән Оры авылыннан чыккан татар математигы Юныс бине Иванай әл-Оруви әл-Казаниның (1636—1689/90) тәрҗемәи хәле һәм аның иҗаты, сакланган әсәрләре хакында бәян ителә. Арчага терәлеп торган Бирәзә авылларының берсеннән чыккан математик һәм астроном мелла Хәмзә бине Мөхәммәд бине Хәсән бине Җиһанмөхәммәд әл-Казани әл-Бирәзәви (1826 елда вафат) турында белү кызыклы. Кышкарда яшәп, 1796 елда җир шары турында китап язган мелла Сәгыйд бине Ибраһим бине Габдулла әл-Барыши исемле мөдәрриснең эшчәнлеге дә игътибарга лаек. Кышкар мәдрәсәсе галимнәре арасында гомере буе башка металлардан алтын ясарга юллар эзләгән спиритизим (ягъни үлгән кешеләрнең җаннары белән элемтәгә керү) белән шөгыльләнгән шәхесләр дә булган. Алар хакында Шиһабетдин Мәрҗани китапларында мәгълүматлар бар.

Галимнең йортында татар тарихына бәйле кешеләрнең шәхси әйберләреннән, борынгы предметлардан, кием-салымнан, кульязма китаплардан тупланган гаҗәеп бай коллекцияләр булган. Кызганычка каршы, большевиклар диктатурасының мәдәният истәлекләрен җимерү сәясәте монда да гамәлдән читтә калмаган. Мәрҗани коллекцияләре таркалып юкка чыгарылган.

Шиһабетдин Мәрҗанинең каләм мирасы — бөтен татар милләтенең, шул исәптән Арча төбәге халкының горурлыгы.

МӘГЪРИФӘТЧЕ ШӘМСЕТДИН КҮЛТӘСИ ХАКЫНДА ЯҢА МӘГЪЛҮМАТЛАР

Арча ягыннан чыккан күренекле шәхесләрдән Күлтәсиләр аерым урын алып тора. Халыкка моңарчы Күлтәсиләрнең берсе генә — философ һәм астроном Шәмсетдин Күлтәси генә мәгълүм иде. Хәлбуки бу галимнең башка ир туганнары да булып, алар да мәдәниятебез тарихында якты эз калдырдылар. Шәмсетдин Күлтәсинең тулы исеме — Шәмсетдин-Мөхәммәд, бине Нурмөхәммәд бине Таһир. Ул 1932 елда хәзерге Арча районына караган Күлтәс авылында 75 яшендә вафат булган.

1978 елның 24 июлендә Арча эшчеләр поселогында безгә Шәмсетдин Күлтәсинең улы, озак еллар совет оешмаларында эшләгән Ибрагим ага Таһиров белән очрашып сөйләшер-

гә туры килде. Ул чакта Ибрагим ага әтисе, туганнары турында кызыклы истәлекләр сөйләде, үзләренең нәсел шәҗәрәләрен тасвирлады. Ул шәҗәрә түбәндәгедән гыйбарәт:

ТАҺИР
(хәзерге Мамадыш районына кергән Максим авылында яшәгән)

НУРМӨХӘММӘД

ШӘМСЕТДИН-МӨХӘММӘД (1857—1932)

МӨХӘММӘД-ФАТЫЙХ (Гурьев, Троицк шәһәрләрендә яшәгән)

МӨХӘММӘД-ХАФИЗ (Төркестанда һәм Үзбәкстанда яшәгән, Мерв шәһәрендә тәрҗемәче булып эшләгән)

МӨХӘММӘД-ЗАКИР (1864—1912; Казанда яшәгән, пыяла заводы управляющие булып хезмәт иткән)

САЛИХ

МӘРЗИЯ

СӘГЪДЕЛИСЛАМ (1886—1942)

ФӘРИДӘ (1888—...)

НУХ (1895—1943)

ИБРАҺИМ (1904—...)

РӘЙХАНА (1907—1977); Арча районының Бәхтияр авылында укытучы булып эшләгән)

ТӘЛГАТ ӘХМЕРОВ (1917—1989); Арча районының Яңа Иябаш авылында яшәде)

«1911—1912 елларда Ишми доносы белән, полиция безнең өйгә тентү ясарга килгәләде.

Бер килгәндә әтине башта старостага чакырдылар. Әти чалма-чапаннарын киеп старостага барды. Анда аны исправник чакырткан була. Исправник чакырткан була. Исправник әтигә: «Менә безгә шундый-шундый китаплар кирәк, алар синдә бар, аны синдә күргән шаһитлар бар. Безгә

шул китапларны бирегез, алар безгә кирәк, алып китәрбез»,—ди. Әти: «Бездә андый китаплар юк»,—ди. Шуннан соң исправник безнең өйне тентергә ике стражник белән килә. Алар килгәннең әүвәлге төнендә әти безгә кунакка кайткан энесе Фатих һәм туганнары Нух, Закир белән берлектә ниндидер китапларны бакчадагы ябык беседканың идән астына казып күмгәннәр иде. Фатих абыйлар шул беседкада яшәделәр.

Тентү кергәч бездәге барлык китапларны карап чыктылар. Аларның һәрберсенә цензура рөхсәт бар дип басылган иде. Тентү вакытында әтине төрле сораулар белән аптыратып бетерделәр. Әти русчага оста иде, һәрберсенә җавап биреп торды.

Безгә Нәҗип Түнтәри еш килә иде, ул әтинең дусларыннан булды. Галимҗан Ибраһимовның да безнең өйдә әти белән очрашканы бар. 1925 елда әти янына тарихчы Газиз Гобәйдуллин килеп китте. Ул чакларны Арчада кантон укытучылары хәзерләү курслары эшләде. Газиз Гобәйдуллин шул курсларда укытты. Әти кушуы буенча мин аны Арчадан Күлтәскә ат белән барып алдым. Ул бездә ике көн торды. Моннан тыш әти янына укытучы (һәм шагыйрь) Кыям Юлдашев килеп йөрде. Татарстан хөкүмәте наркомы булып эшләгән Каюм Мәһдиев тә әти белән аралашты. Каюм Мәһдиев ул чагында мәгариф шөгъбәсендә укытучы булып эшли иде, соңыннан репрессиягә дучар булды. Әти янына килеп йөрүчеләрдән, Арча педучилищесы укытучысы Ибраһим Якуповны хәтерлим. Әтинең бик зур китапханәсе бар иде, таралып бетте. Әтинең энесе Закир Таһиров РСДРП членнары белән бәйләнештә булды. Аның йортында большевикларның листовкалары, револьверлары саклан-ган. Аны Сәгъделислам абый сөйләде. Сәгъделислам Мулланур Вахитов белән аралашкан, аларда фатирда торган. Бервакытны, Сәгъделислам Закир абыйсында кунган кичне, аларга полиция тентү белән килә. Закир хатынының әнисе ах-вах итеп озаклап ишек ачканда коралларны һәм листовкаларны бәдрәфкә ташлыйлар. Шунда бер төргәк листовка онытылып калган була. Әби аны итәк астына тиз генә алып кыстырды да, эчем авырта дип сыкранып йөрде. Полиция әбине тентемәде, йорттан берни дә табалмыйча китте.

Закир абый Казанда авырып вафат булды»[1].

---

[1] Казан зиратында Габдулла Тукай кабереннән бик еракта түгел Закир Таһировның кабере бар. Аның ташында «Закир бине мулла Нурмөхәммәд Таһиров әл-Күлтәси 48 яшендә 1912 елның 3 декабрендә вафат булды» дип язылган.—*М. Ә.*

Ибраһим ага Таһиров миңа ул чакта әтисенең фоторәсеме дә бар дигән иде. Ләкин ул вакытта таба алмады, каядыр куйган иде. Шуннан соң аның белән янәдән дә 1989 елның июнь урталарында гына очрашырга туры килде. Мин, Шәмсетдин Күлтәсинең фоторәсеме табылмадымы икән дип гел истә тотып йөргәнгә, Ибраһим ага Таһировка кердем. Ул инде тагы да олайган, ялгыз калган иде. Шулай да ул мине онытмаган булып чыкты, өенә алып керде, әтисенең фоторәсемен табып күрсәтте. Сурәт 1926 ел чамасында алынган. Анда алгы рәттә унда Шәмсетдин Күлтәси, сулда дусты Нәҗип Түнтәри, артта исә Ш. Күлтәсинең энесе Хафиз төшкәннәр. Ибраһим аганың рөхсәте белән Арча районы газетасы редакциясе хезмәткәрләре ярдәмендә сурәттән фотокүчермә алдык.

Тәлгать Әхмеров истәлекләре: Шәмсетдин Күлтәсинең сеңлесенең улы Тәлгать Әхмеров (1917—1989) белән 1983 елның 11 июлендә Арча районы Яңа Иябаш авылында очрашкан идек. Истәлек шул вакытта язып алынды.

«Күлтәс авылы янында гына Казан бае Габдрахман Ишморатовның җирләре бар иде. Аның җирләре хәзер «Үрнәк» совхозы карамагында. Җирбиләүче Габдерахман Ишморатов Шәмсетдин Күлтәси өстеннән гел жалоба йөрткән. Аның жалобасы буенча Шәмсетдин Күлтәси йортында бер җәйдә полиция 28 мәртәбә тентү уздыра. Аны революционерларга ярдәм иткәне өчен эзәрлеклиләр.

Шәмсетдин Күлтәсинең улы Сәгъделислам — революционер була. Ул Мулланур Вахитовның дусты булган һәм аларда фатирда торган. Бу вакытларда ул В. М. Молотов белән дә таныш була. М. Вахитов аның белән бергә Күлтәскә кунакка кайтып йөргән. Минем Сәгъделислам, Мулланур Вахитов, Нәҗип Түнтәри бергә төшкән рәсемне күргәнем бар Ибраһим Таһировта. Казанда Шәмсетдин Күлтәсинең улы Нухның кызы Дания апада бу һәм башка фоторәсемнәр саклана.

Сәгъделислам Таһиров (Күлтәси) 1931 елда Казандагы 40 нчы завод директоры булып торды. 1931 елда аны гаепләп партиядән, эштән чыгаралар. Сәгъделислам шуннан соң Мәскәүгә, Үзәк Комитетка В. М. Молотовка хат яза. Хатның тәэсире булып, аны партия әгъзалыгына кайтаралар. Ул Казандагы Мамык фабрикасы директоры булып эшли башлый. Аның гомеренең соңгы көннәре авыр була. Ул 1941 елда Казанда психбольницада үлде. Сәгъделислам Таһировның орден-медальләре дә бар иде. Шул ук елда аның хатыны Гәрифә дә үлде. Гәрифә телче (филолог — *М. Ә.*) Мөхәммәтхан Фазлуллинның сеңлесе иде.

1941 елда Шәмсетдин Күлтәсинең кызы Зәйнәп, улы Нух

Күлтәси вафат булдылар.

Шәмсетдин Күлтәсинең сеңлесе Гафифә Түбән Оры авылының (хәзерге Арча районы) Самигулла хәзрәт хатыны иде.

Шәмсетдиннең энесе Хафиз Күлтәси — бер китап язган кеше. Ул Үзбәкстанның Мерв шәһәрендә яшәде һәм шунда үлгән булса кирәк.

Энесе, Фатих Күлтәсинең улы Салих, 1913 елда туган. Кызы Мәрзия 1915 елда туган. Салих рухи авырлыкларга чыдый алмый. 1932 елда сәламәтлеген төзәтә алмаслык рәвештә югалта.

Шәмсетдин Күлтәсинең кабере Күлтәстә, кабер ташы бар. Минем беренче укытучым ул иде».

1994 елның 21 июлендә Күлтәс авылының үзенә барып чыгу да насыйп булды. Максатыбыз — анда Шәмсетдин Күлтәсинең истәлеге ни дәрәҗәдә саклануын ачыклау иде. Күлтәс кешеләре белән танышу барышында Шәмсетдин Күлтәси мәдрәсәсендә укыган Фәйзи Габдерахманов (1910 елда туган) белән сөйләштек. Ул безгә үзенең беренче остазы турында түбәндәге хәбәрләрне җиткерде:

«Мин мулла абзыйда укыдым. Ул бик оста укыта иде. Бар фәннәрне дә белде. 1930 елда мулла абзыйны өеннән куып чыгарып, аны кечкенә генә бер мунчага керттеләр.

Мулла абзыйның Сәгъделвәккас (Сәгъделислам — *М. Ә.*) исемле улы заманында Казанда В. М. Молотов белән бергә укыган була. Ул тиз генә Мәскәүгә барып, Молотов белән күрешә, аңа атасын эзәрлекләүләре турында хәбәр итә. Шуннан соң хәзрәт хакында Молотовтан хәбәр килеп, аны бик тиз өенә кайтаралар. Аннан талап алган әйберләрне дә китереп бирүчеләр була. Шуннан соң хәзрәт бу авырлыкларга чыдый алмады, озак та тормый үлде. Аны атасы кабере янына күмделәр. Кабере өстендә ташы юк. Хәзрәтне өеннән куган чакта бер җиңел акыллырак кеше аның бөтен китапларын кырга алып чыгып яндырды. Аннан китаплар калмады».

Фәйзи агай һәм тагын берничә кешеләр Күлтәс авылында безгә Шәмсетдин хәзрәтнең йорт урынын да күрсәттеләр. Галимнең хуҗалыгыннан бер бина да калмаган. Ләкин анда бер истәлек тактасы язып кую яхшы булыр иде.

Кешеләр белән очрашканнан соң Күлтәснең Рөстәм исемле егете озатуында зиратны карарга киттем. Зиратны «актарып» карап чыктык, ләкин Шәмсетдин Күлтәси кабере өстенә куелган язулы ташны тапмадык.

Зиратта Шәмсетдин Күлтәсинең әти-әниләренең каберләре өстенә куелган таш саклана. Өч кырлы ташның бер

кырына аның 63 яшьлек әтисенең 1884 елның маенда үлгәнлеге язылган. Таштагы язуга карагända Шәмсетдин Күлтәсинең әнисе Сабира Ибраһим кызының 1900 ел, 5 октябрьдә 71 яшендә үлгәнлеге аңлашыла.

Югарыда без Шәмсетдин Күлтәсинең әтисе Нурмөхәммәт Таһир улының Мамадыш ягындагы Максим (Мәкчим) авылыннан килгән булуын күрсәткән идек. Әлеге авыл бүгенге Мамадыш районындагы торак пунктлар исемлегендә юк. Мамадыш төбәгендә археографик экспедиция белән йөргән чакта Максим авылының хәзер «Ямаш» исеме йөрткән татар авылы икәнлеген ачыклаган идек. Ямаш авылы XVII гасыр башларында Кара бәк нәселеннән булган Ямаш морза тарафыннан нигезләнгән. Шуннан чыгып Шәмсетдин Күлтәсинең дә Кара бәк нәселеннән килгәнлеге фараз кылына. Шәмсетдин Күлтәсинең нәсел риваятьләренә караганда, галимнең бабалары «көньяк илләреннән килгән» дип исәпләнгән. Кара бәк Кырык һәм Кара диңгез якларыннан килгән олыс бие булган.

ИСТОРИЯ АРСКОГО КРАЯ

I. Голоса седой истории

ИСТОРИЯ АРСКОГО КРАЯ

Об основании и названии Арска

Волго-Вятское междуречье — один из многонациональных районов нашей страны. Здесь живут представители трех крупных языковых групп: финно-угорской, тюркской, славянской, границы расселения и этнический состав которых менялись на протяжении длительного исторического периода. Это было связано с развитием производительных сил и производственных отношений, миграционными процессами, с образованием крупных государственных объединений, способствующих установлению экономических и культурных связей между народами. Появление этих народов и освоение ими края происходило в исторически определенные сроки.

Начиная с III—IV веков н. э., вплоть до конца 1 тыс., в Камско-Вятское междуречье неоднократно проникали большие группы тюркоязычных племен. В конце IX — начале X веков на этой территории возникает первое государственное образование — Волжская Булгария, которая в дальнейшем все дальше и дальше расширяла свои границы на северо-восток и северо-запад.

На основе анализа археологических и нумизматических находок таких селищ, как Чурилинское, Бужинское, Средне-сердинское, Сосновкинское и Уньбинское, Р. Г. Фахрутдинов и А. Х. Халиков делают вывод, что в XII—XIII веках бассейн реки Казанки уже был прочно освоен булгарами[1].

Самое первое упоминание об Арске мы находим в русских летописях — «Летописце последней четверти XVII века» и в «Книге степенной царского родословия»[2]. В них

---

[1] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория.— Казань, 1975.— С. 48; Халиков А. Х. О времени, месте возникновения и названии города Казани // Из истории культуры и быта татарского народа и его предков — Казань, 1976.— С. 3—9.

[2] Полное собрание русских летописей (далее — ПСРЛ): Т. 31 — М.: Наука, 1968.— С. 79; Т. 21 — СПб., 1908.— С. 309.

сообщается о том, что ордынский хан в «лета от создания миру 6804-го» это 1296 год от Рождества Христова) выдал за князя Смоленского и Ярославского Федора Чермного свою дочь с приданым в 36 городов Восточной Европы, среди которых назван и Арск.

Наряду с этим существует несколько упоминаний об «арской земле». В частности, в сообщении арабского путешественника середины XII века Абу Хамид аль-Гарнати мы читаем: «Болгары простирают свое владычество на некоторые области, которые ему платят дань... Одна из областей называется Вису (Йсу), другая Арв. В этой области охотятся за бобрами, горностаем, белкой»[1]. Археолог А. Л. Монгайт считает эту область Арв ничем иным как «Арской землей» русских летописей[2].

Существует ряд мнений об истории возникновения названия и основателях Арска. Одни исследователи склонны считать, что Арск основали ары (так татары назвали удмуртов — своих северо-восточных соседей). По их мнению, на месте Арска могла быть небольшая удмуртская (арская) деревня, называемая булгарами «Арча» — это прибавлением к татарскому наименованию удмуртов «ар» аффикса -ча, выражающего неполноту, ослабленность признака и предмета[3].

Другие исследователи считают, что в основе происхождения топонима «Арча» лежит древнее булгаро-татарское слово «ур»[4], которое в разное время на языке разных тюркских народов применялось также для обозначения: 1. глубокого рва, глубокого сухого оврага, оврага; 2. рва с укреплением, вала; 3. укрепления крепости. Если обратим свое внимание на местность Арской крепости, то можно отметить определенное соответствие ее данным определениям. В частности, краевед В. Л. Борисов в статье «Древняя башня в г. Арске Казанской губернии», опубликованной в 1900 г. в «Известиях Общества археологии, истории, этнографии» пишет, что «Арская крепость занимала превосходное стратегическое положение, будучи расположенной в треугольнике, образуемом горным (правым) берегом р. Казан-

[1] Монгайт А. Л. Абу Хамид аль-Гарнати и его путешествие в Русские земли 1150—1153 гг. // История СССР.—1959.—№ 1.—С. 171.

[2] См.: ПСРЛ: Т. 8—СПб, 1859.—С. 3; Т. 25.—М.—Л., 1949.—С. 201; Т. 24.—Пг., 1921.—С. 143; Т. 18.—СПб, 1913.—С. 129; Т. 15.—М., 1965.—С. 138; Т. 11.—М., 1965.—С. 45.

[3] Кельмаков В. К. Происхождение и первые упоминания этнонима «ар» // Этнонимы.—М.: Наука, 1970.

[4] Саттаров Г. Ф. Арча атамасының килеп чыгышы // Совет мәктәбе.—Казан, 1984.—№ 1.—21—24 б.

ки и оврагом, прорезывающим этот берег на пространстве нескольких десятков саженей; с третьей стороны она отделялась валом и рвом, довольно хорошо сохранившимися»[1].

По мнению третьих исследователей, около Арска росло очень много можжевельника (на татарском языке — артыш, а в переводе на тюркский язык — «арча»): «Булгары, уважая и полюбив священное дерево арчу, Арской крепости якобы дали название «Арча», ибо названия многих объектов, оставшихся от булгар и их потомков, названы согласно природным особенностям местности»[2].

Четвертая версия о возникновении названия «Арча» базируется на его образовании от черемисского слова «арча», что означает «ларчик, шкатулка»[3]. Возможно, черемисы близлежащих мест окрестили данный населенный пункт *арчой* (Арча) из-за схожести его со шкатулкой, ларчиком (или это слово в XII—XV веках у черемисов имело и другие значения).

По пятой версии, название «Арча» могло возникнуть от сочетания слов «аргы як». В отделе редких рукописных книг Научной библиотеки им. Лобачевского за ед. хр. 3256т имеется летопись деревни Березн, что лежит недалеко от Арска. Летописец постоянно при обозначении Арской стороны пользуется сочетанием «аргы як». Употребление этого сочетания слов характерно и для других мест, порой в одной и той же деревне более окраинную часть называют «аргы як». Это словосочетание могло со временем трансформироваться в слово «Арча».

О времени построения Арска также существует несколько точек зрения. Отдельные исследователи, утверждающие, что первоначально на месте этого населенного пункта когда-то была удмуртская (арская) деревня считают, что по времени это могло быть до образования Волжской Булгарии, ибо с появлением последней Арск как пограничный форпост должен был стать булгарским.

Другие исследователи построение Арска относят к татаро-монгольскому периоду.

---

[1] См.: Борисов В. Л. Древняя башня в г. Арске Казанской губернии // ИОАИЭ.— Казань, 1900.— Т. 16.— Вып. 3.— С. 295.

[2] См.: Гәрәй Йосыф. Сүз җыярга килегез // Казан утлары.—1969.— № 10.—150—161 б; Фахретдинов Р. Г. Ташлар моңы / Археолог язмалары.— Казан, 1978.—163—169 б; Сафин Ш. К истории Арска // К коммунизму (Арск).—1984.— № 84.

[3] Троицкий В. П. Черемисско-русский словарь // ИОАИЭ.— Казань, 1893.— Т. 11.— Вып. 2.— С. 1—24.

По мнению третьих, Арск построен после взятия Казани войсками Ивана Грозного.

Четвертая точка зрения — Арск построен при Петре I. Последняя никаких оснований не имеет. Во-первых, потому что не было необходимости (у Петра дела были поважнее Арска). Во-вторых, это явно противоречит сохранившимся историческим документам, о которых речь пойдет дальше.

Вероятнее всего, Арск возник как пограничная крепость булгар в начале XIII века. В 1205 году Казань в устье Казанки подверглась разгрому и население вынуждено было уйти выше по реке Казанка и осесть на месте Иски Казани, где до этого, по-видимому, находился пограничный острог. С переносом столицы княжества на новое место появляется необходимость дополнительного укрепления северо-восточных границ. Так возникает укрепленный острог Арск, рельеф местности которой очень схож с рельефом местности Иски Казани.

Арское княжество — часть Казанского ханства

После более чем 200-летнего существования Золотая Орда приходит к распаду. Это внесло существенные изменения и в жизнь населения Арского края. Феодальные усобицы и набеги ордынских и иных князей окончательно дезорганизовали развитие производительных сил в районах прежней булгарской культуры (Булгар, Сувар, Джукетау, Биляр). Происходит дальнейшее перемещение населения преимущественно в предкамские районы.

В начале XV века на этих землях, на вновь созданной к тому времени экономической базе возрождается местная государственность, разрозненные феодальные княжества объединяются в более сильный политический организм — Казанское ханство. Основные земли его располагались, главным образом, в предкамских районах современного Татарстана, где было много богатых феодальных владений. Политическим и экономическим центром явилась Казань.

В военно-административном отношении Казанское ханство делилось на даруги: Галицкую, Алатскую, Арскую, Зюрейскую и Ногайскую. Каждая даруга в свою очередь делилась на «сотни» — служилые и ясачные. Это традиционное деление на даруги сохранилось вплоть до XVIII века включительно[1]. Административным центром Арской дару-

---

[1] История Татарской АССР.— Казань, 1968.— С. 84—85; см. также: Очерки истории Марийской АССР.— Йошкар-Ола, 1965.— С. 65.

ги явился город Арск. С момента возникновения Казанского ханства Арская даруга входит в его состав и в продолжении всей последующей истории их судьбы складывались во взаимосвязи. Это с отчетливой ясностью прослеживается в событиях, связанных с борьбой Московского государства и Казани. Арск является то сборным местом отдельных армий, всегда готовых идти в обход русским, обыкновенно приходившим к Казани с Московской стороны, что в Арске скрывались разбитые казанцы и собирались там с новыми силами.

Территория и население. Арское княжество занимало северо-восточную часть Казанского ханства. Восточная граница доходила почти до реки Вятки. Северная была весьма неопределенной. Жившие на этих окраинах марийцы и удмурты в южных районах своего поселения подчинялись Казанскому ханству, а в северных — Руси. Из летописных известий того периода видно, что в состав Арской даруги входили также земли по Ашиту, Илети, Уржумке[1]. А это в основном марийские районы. Таким образом, в Арское княжество входили различные народы: удмурты (ары), марийцы, значительное место занимали казанские татары. В целом надо отметить, что даруга, не имея строго очерченной границы, делилась на улусы и сотни во главе с татарскими или местными феодалами.

Хозяйственный строй. Хотя и произошли большие изменения в политической жизни народов Поволжья, но хозяйственный уклад не был нарушен. Основным видом хозяйственной деятельности населения оставалось достаточно развитое для своего времени земледелие, рассчитанное в основном на производство хлеба — зерна. Трудовое население постепенно осваивает новые земли, расчищает леса, создает свое хозяйство. Если раньше в закамских землях Булгарии преобладало степное земледелие на черноземах, то здесь развивалось земледелие на лесных подзолистых почвах.

Сохранялась освоенная еще булгарами сельскохозяйственная техника — для грубой вспашки применялся тяжелый сабан с металлическим лемехом, на более легких землях — двудубые сохи. От периода Булгарии было унаследовано трехполье и основные земледельческие культуры — пшеница, ячмень, рожь, полба, гречиха, просо, горох и чечевица. Железные серпы и косы, служившие для уборки урожая, не отличаются от булгарских.

---

[1] См.: Очерки истории Марийской АССР.— Йошкар-Ола, 1965.— С. 87.

Скотоводство было в основном стойловым. Необходимое для стойлового содержания скота сено заготовлялось в большом объеме. Разводились лошади, крупный и мелкий рогатый скот, домашняя птица (гуси и куры). Важным подспорьем для крестьянина являлись подсобные сельские промыслы — бортничество, охота и рыболовство. Последнее было развито слабее из-за мелководности здешних рек.

В XV — первой половине XVI века получает дальнейшие развитие и ремесленное производство. Сельское население поставляло ремесленникам сырье и продукты питания, в свою очередь получая от них орудия труда, предметы быта и прочие продукты ремесленного производства. Появление большого количества ремесленников в этом районе связано с перемещением их из-за Камы, начиная уже со второй половины XIII века. Пополнение основных кадров ремесленников шло и из среды сельских жителей. Ведущее место занимали металлурги, добывавшие чугун, варившие железо и изготовлявшие все основные орудия труда и оружие. Дальнейшее развитие получают прикладные ремесла. Ювелиры, развивая булгарские традиции в обработке драгоценных металлов, изготовляли многочисленные украшения, орнаментированные путем применения сложнейших ювелирных приемов. Традиционным было также и кожевенное ремесло. Широкой известностью не только в ханстве, но и далеко за его пределами пользовалась кожаная обувь, искусно украшенная аппликацией и узорной расшивкой. И ныне продукция Арского производственного объединения национальной обуви пользуется заслуженным спросом.

Продукты ремесленного производства и сельского хозяйства реализовывались через внутренний и внешний рынок. Крупнейшим торговым центром не только ханства, но, пожалуй, и всего Поволжья и Прикамья была Казань, где проживали купцы из разных стран. Арские ремесленники благодаря близкому положению с Казанью могли часто пользоваться этим международным торжищем. Наряду с этим в самом Арске, как и в других городах ханства, возникает рынок (базар)[1].

Общественный строй. Ш. Ф. Мухамедьяров, исследовав земельные правоотношения в Казанском ханстве, пришел к выводу, что «старинная земледельческая культура была базой развития феодальных отношений на территории Ка-

---

[1] См.: Артемьев А. Арск // Казанские губернские ведомости.—1847.— № 9.— С. 122; Очерки истории Марийской АССР.— Йошкар-Ола, 1965.— С. 76.

занского ханства задолго до его основания»[1]. Ко времени возникновения Казанского ханства (30—40 гг. XV века) феодальный строй в Среднем Поволжье был уже вполне развитым. Феодалы делились на следующие группы: ханы, эмиры, мурзы, уланы, казаки, духовенство.

Арское княжество составляло одну часть государства с тем же общественным строем. Здесь верхушку феодальной знати составляли эмиры (беки, князья). Они были военачальниками ополчения своей округи, которую получали в управление или кормление.

Следующую, наиболее многочисленную феодальную группу составляли мурзы — дворяне. Эмиры и мурзы были основными землевладельцами как в ханстве, так и непосредственно в Арском княжестве, которое выступало главным районом феодального землевладения[2].

Служилыми феодалами — военачальниками — были огланы (угланы). Низшей группой феодалов являлись казаки, составлявшие постоянное ядро ханского войска. Ш. Ф. Мухамедьяров отмечает, что за военную или иную службу эти служилые люди получали в виде вознаграждения во временное владение обрабатываемые крестьянами участки государственной земли. Таким образом, он приходит к выводу, что государственная земля была не только источником взимания ханом ренты, но и объектом ленного пожалования, т. е. говорит о наличии сойюргальной системы.

Особую группу внутри класса феодалов составляло мусульманское духовенство.

Политические события конца XV — первой половины XVI вв. В 1487 году Казань оказывается под протекторатом Русского государства. На престол возводится угодный Москве хан — Мухаммед-Эмин. Первые десять лет протекали мирно. Но в середине 90-х годов восточная группировка изменила хану и пригласила на престол Сибирского царевича Мамука. Мамук стал казанским ханом, но он был типичным авантюристом, преследовал исключительно своекорыстные цели, сажал в тюрьмы знатных казанских людей, «гостей и земских людей всех пограбил»[3]. Своим безудерж-

---

[1] Мухамедьяров Ш. Ф. Земельные правоотношения в Казанском ханстве.— Казань, 1958.— С. 3.

[2] См.: История Татарской АССР.— Казань, 1968.— С. 81; История Татарии в материалах и документах.— М., 1937.— С. 129.

[3] См.: ПСРЛ: т. 6.— СПб., 1853.— С. 41; т. 8.— СПб., 1859.— С. 231—232; т. 20, ч. 2.— СПб., 1914.— С. 364; т. 24.— Пг, 1921.— С. 242, т. 28.— М.— Л.: Наука, 1963.— С. 328; т. 33.— Л.: Наука, 1977.— С. 131.

ным грабежом, насилием и бесчинством он скоро вызвал ненависть населения ханства. Через несколько месяцев против его власти восстали арские люди. Мамук отправился на их усмирение «и прииде ... ратью под Арский городок». Арские князья городок свой защищают упорно, крепко бьются с ханом. И в это время казанские князья, прибывшие с Мамуком, отъехали от него, ушли обратно в Казань, укрепили город. «И царя Мамука в град не пустиша, а измену на него возложиша, что их князей имал, а гостей и земских людей грабил». Мамук после этого «пойде от Казани восвояси и на пути умре».

В начале XVI века в Казани стала все более усиливаться антимосковская группировка. Это проявилось в событиях 1505 года, когда был арестован русский посол Михаил Кляпин. Казанцы захватили огромные богатства. 60-тысячное казанское войско, в т. ч. 20 тысяч ногайцев, подступило к Нижнему Новгороду, но было отбито.

В ответ русское правительство вскоре мобилизовало 100-тысячную армию. В 1505 году русские войска под предводительством князя Дмитрия Ивановича, брата великого князя Василия, явились под Казань. В это время казанцы «не ведущи и праздник творящи на великом поле Арском»[1]. Во время праздника внезапно напали русские и одержали победу. Казанцы едва успели скрыться в город, в ближайшие леса и в Арск. Русские, обрадованные легкой победой, торжествовали, теперь они устроили праздник. Так прошло три дня. В это время казанцы сумели вооружиться и напали на полусонных русских. «...И покрылося лицо земли трупьем человеческим, поле Арское и Царев луг кровью черленившеся... И от 100000 осталася 7000 русских вои...» — читаем мы в летописи.

Вологодско-Пермская летопись сообщает, что в 1530 году послал «великий князь воевод своих к Казани на безбожного царя Сафа-Гирея Казанского за его неисправление и измену»[2]. Подошло большое русское войско к Казани и «взяша острог за Булаком..., царь выбежал из Казани к Арскому городку». Князь Оболенский с одной частью войска погнался за царем к Арскому городку, а князья И. Ф. Бельский, М. В. Горбатый и М. Л. Глинский остались под Казанью. «В те поры пришла черемиса казанская» убили Оболенского и некоторых других князей. Разозлился

---

[1] ПСРЛ.— Т. 19.— СПб., 1903.— Гл. IX.— Столб. 26.

[2] ПСРЛ.— Т. 26.— М.— Л.: Наука, 1959.— С. 314.

на это Бельский и «начаша по граду Казани приступати и по граду начаша бити и во граде много людей побиша». Казанцы не стерпели и били челом воеводам московским. Как только Бельский снял осаду, пришли послы казанские к великому князю Василию Ивановичу, просили царем Шах-Али, бывшего прежде у них царем. При этом послы говорили, что на такое избрание нового царя согласны не только казанцы, но и князья Арские и «вся черемиса».

С февраля 1548 года Русское государство предпринимает ряд походов на Казань, закончившихся в 1552 году взятием последней. Во время этих походов разорялись деревни, приходила в упадок экономика ханства. Арское княжество, будучи составной частью Казанского ханства, принимает активное участие в борьбе с Москвой. Оно предоставляет Казани военную силу, имущество и с осложнением обстановки, летом 1552 года, организует военные действия во главе с князьями Япанчи и Явуш, неоднократно беспокоящих лагеря русских у стен Казани[1]. Русские войска вынуждены были даже строить туры на Арском поле, чтобы не дать арчанам возможность пройти на площадь с лесной стороны. 30 августа 1552 года противник сумел заманить войска Япанчи и Явуша в засаду и «побили татар..., и 15 верст гнаша и биша их». Но и после этого вылазка войск Арского княжества в тыл русских не прекращалась. И 6 сентября «пустил государь на Арское место и на острог воевод своих на три полка».

В ходе этой операции выясняется, что в Заказанье было немало укрепленных острогов. «И пошли воеводы, напредъ полкы пошли у воевод пеши стрельцы и казаки, и как пришли на высокую гору к острогу, а острогъ бе их рубленъ городнями и землею насыпанъ, а в иномъ месте многими засеками засечено, а сделанъ промежъ непроходимыхъ болотъ...».

Здесь было большое сражение, крепость защищалась упорно. Одновременно А. Б. Горбатый и З. П. Яковля пошли другим путем и пришли к острогу. И здесь на их удивление: «великие крепости у них поделаны и в лесу чашча великая». Этот острог тоже не покорился сразу, пока его брали «татар многое множество побили». Р. Г. Фахрутдинов этот острог отождествляет с Иске-Казанью, располо-

---

[1] См.: ПСРЛ: т. 13.—М.: Наука, 1965.—С. 206—211, т. 20, ч. 2.—СПб., 1914.—С. 520—523, т. 29.—М.: Наука, 1965.—С. 99, 101—102, 196—197.

женной между Высокой Горой и Арском[1]. Кроме этих укреплений, были еще несколько крепостей. Очевидно, острог был и напротив села Троицкого. «Старинное земляное укрепление, с двух сторон сделанное наподобие земляного вала» — так зафиксировано в Актах генерального межевания[2].

Далее русские войска «пошли, воюющи и села жгучи к Арскому городищу; и пришедше на Арское городище, бояре и воеводы послали головы царева полку, а сами на городище стояли два дни и пошли другою дорогою к Казани».

Один из сподвижников Ивана IV и очевидец грозных событий 1552 года А. Курбский пишет в своих воспоминаниях, что русские князья с войсками дошли «до Арского города, который лежит от Казани двенадцать миль великих. Егда же придоша ко оной стене, сопряшася бусурманы и начаша бронитися крепце, аки на две годины бьющиеся; потом ... одолеша их наши, яко огненною стрельбою, так ручною, и побегоша бусурманы, наши жъ гонили ихъ»[3].

А вот что писал о взятии русскими Арска неизвестный русский автор в 1565—1566 гг.:

«Взято множество всякой рухляди,
И скота взято много домашнего.
Не имели потерь наши воины,
Даже малых при взятии крепостей:
Отворяли им ворота жители
И впускали к себе победителей,
Не пустив в них стрелы ни единые,
Даже камни не бросивши малого
У острога они только первого
Трое суток стояли осадою,
Но убитых и тут у них не было.
Этот первый острог Арским звавшийся,
Был подобен во всем граду твердому,
Имел башни и стены с бойницами,
И людей проживало в нем множество.
И его берегли так старательно,

---

[1] Фахрутдинов Р. Г. Археологические памятники Волжско-Камской Булгарии и ее территория.— Казань, 1975.— С. 81.

[2] Порфирьев С. Древности Казанского края в Актах генерального межевания // ИОАИЭ.— Казань, 1904.— Т. 20.— Вып. 1—6.

